ISSN 2618-9623

Туган җир

Родной край

Төбәк тарихы буенча журнал

Краеведческий журнал

3*2018

Төзелеп килүче Искер мәчете

Бөтендөнья татар конгрессы
Татарстан Республикасы татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте

ТУГАН ҖИР

Төбәк тарихы буенча журнал

3*2018

Казан – 2018

Всемирный конгресс татар
Общество татарских краеведов Республики Татарстан

РОДНОЙ КРАЙ

Краеведческий журнал

3*2018

Казань – 2018

УДК 908
ББК 26.89 (2Рос.Тат)
Т 70

Баш мөхәррир:
Дамир Мәүләви улы Исхаков,
тарих фәннәре докторы

Баш мөхәррир урынбасары:
Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы,
тарих фәннәре кандидаты

Редакцион коллегия:
Аблязов Камил
Акчурин Мәгъсум
Бәйрәмова Фәүзия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гыйләҗев Искәндәр
Габдрафиков Илдар
Закиров Ренат
Измайлов Искәндәр
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зәйтүнә
Шәйдуллин Рафаил

Редакцион-нәшер итү төркеме
Җаваплы сәркәтип:
Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы
Чыгарылыш өчен җаваплы
Дәүләтшина Гөлнара Фарикъ кызы

Главный редактор:
Дамир Мавлявеевич Исхаков,
доктор исторических наук

Заместитель главного редактора:
Бурханов Альберт Ахметжанович,
кандидат исторических наук

Редколлегия:
Аблязов Камил
Акчурин Магъсум
Байрамова Фаузия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гилязов Искандер
Габдрафиков Ильдар
Закиров Ренат
Измайлов Искандер
Ситдиков Айрат
Сафин Фаил
Тычинских Зайтуна
Шайдуллин Рафаиль

Редакционно-издательская группа
Ответственный секретарь:
Сагидуллина Мунира Халимовна
Ответственный за выпуск
Давлетшина Гульнара Фариковна

Басманың адресы:
Казан шәһәре, Карл Маркс ур., 38/5
e-mail: Monitoring_vkt@mail.ru
Татар төбәк тарихы буенча кварталлык журнал
Татар һәм рус телләрендә

Адрес издания:
г. Казань, ул. Карла Маркса, 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
Ежеквартальный журнал по татарскому краеведению
На татарском и русском языках

ISSN 2618-9623

Туган җир: Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край:Краеведческий журнал]. №3.Казан: Бөтендөнья татар конгрессы. 2018.

Эчтәлек

II Бөтенроссия татар тарихын өйрәнүчеләр җыены резолюциясе. 10

Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары

Д.М. Исхаков.

Халкыбызның эпик әсәрләрендә яшеренгән милли тарихыбыз: Беренче язма: «Түләк һәм Сусылу» дастанында тарих..14

Л.А. Йосыпова (Хәлилова).

Дәүләт кемнеке, тел дә шуныкы. 28

Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр

А.А. Борһанов.

Иске-Казан тарихи-мәдәни һәм табигый комплексы һәйкәлләре. 41

Н.Г. Гариф.

Үткәннәргә сәяхәт. 56

А.И. Бугарчев, О.В. Степанов.

Татарстанның Лаеш районы Карташиха авылы тирәсеннән табылган XV гасыр тәңкәләре. 61

О.Р. Хисамов, И.Г. Закирова.

Новосибирск өлкәсе татар авыллары. 65

З. Ә. Тычинских, Д.М. Исхаков.

Күчем хан. Соңгы битләр. 78

Фәнни популяр язмаларда төбәк тарихы

Г.Ф. Шәйхиева.

Төркиядә татар эзләре. 85

З.М. Нәҗметдинов.

Метрикаларда халкым язмышы, авылым тарихы. 95

Р.С. Кутумова, С.З. Хисмәтуллин.

Милли мәгариф бишеге. 103

Е.Ш. Сафиуллина.

Зур террор дәвере. 112

Р.И. Фәтхиев.

Шүлгән алтыны кайда? 119

Ф.Г. Галимов.

Аккүл авылы тарихыннан. Аксакал хәтирәләре. 129

Д.Н. Таҗиев.
Кыям Җәгъфәров: автобиографик истәлекләр (дәвамы)......................139

Р.З. Салиев.
Яла ягылган имам-хатыйб. 149

Ф.К. Дәминова.
Мәрҗани шәкерте Баруди. 157

Р.Р. Яушев.
Ясәви: «Халык дошманы»..165

Р. Нотфуллина.
Олы Нырсы авылы тарихы «Изгеләр»дән башлана. 170

Мәктәптә төбәк тарихын куллану

К.Ә. Габбасова, Д.И. Исхаков, А.Д. Хәйруллина, Ф.Ф. Харисов.
Казанның Киров районы «15 номерлы татар гимназиясе» муниципаль белем бирү учреждениесендә Бишбалта бистәсендә татар халкының тормышы һәм Казан Адмиралтействосы тарихы музеен төзү буенча методик тәкъдимнәр. 179

Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы.

Ф.Р. Яхин.
«Мәликә китабы» тарихы (дәвамы). 189

Төбәк тарихына караган тарихи чыганаклар

Оренбург шәһәре һәм өязенең Өфе буенча исемлек китабының алфавитында узган генераль ревизия буенча ирләр саны....................201

Көнъяк Урал буенда йомышлы татарларның 1 ревизиядәге саннары. 203

Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар.
Хатлар һәм кайтавазлар
Вакыйгалар хроникасы.

Ф.Ә. Бәйрәмова.
Курган җирендә күргәннәр. Курган татарлары тарихы.........................210

Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат.
Рецензияләр

Котыптан килгән гыйлем нуры..219

Яңа китап: Рахимҗанов Б.Р. Мәскәү Русе һәм XV–XVI гасырларда татар ханлыклары. 224

Р.Ф. Мөхәмәтдиновның «Дөнья мәдәниятендә төркиләр» исемле яңа китабы турында...226

Татар рухы

Р. В. Айсин.
Гаяз Исхаки: революционер, язучы һәм татар футурологы. 227

Р. Р. Минһаҗев.
Миллилекне ничек сакларга?..231

Юбилярлар турында сүз

Ветераннар һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләр хәрәкәте активисты. 238

Хушлашу

Тынгы белмәс төбәк тарихын өйрәнүче истәлегенә. 243

Авторлар буенча белешмә. 246

Содержание

Резолюция II Всероссийского форума татарских краеведов. 10

Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения.

Д.М. Исхаков.
Наша национальная история, запрятанная в эпческих произведениях народа: Первая публикация. История в дастане «Туляк и Сусылу» 14

Л.А. Юсупова (Халилова).
Кому принадлежит государство, тому принадлежит и язык..................28

Научные публикации по краеведению

А.А. Бурханов.
Памятники Иске-Казанского историко-культурного и природного комплекса. 41

Н.Г. Гариф.
Путешествие в прошлое. 56

А.И. Бугарчев, О.В. Степанов.
Монеты XV в. из окрестностей села Карташиха Лаишевского района Татарстана..61

О.Р. Хисамов, И.Г. Закирова.
Татарские села Новосибирской области. 65

З.А. Тычинских, Д.М. Исхаков.
Хан Кучум. Последние страницы. 78

Краеведение в научно-популярных публикациях.

Г.Ф. Шайхиева.
Татары в Турции...85

З.М. Назметдинов.
История сел, судьба татарского народа в метриках. 95

Р.С. Кутумова, С.З. Хисматуллин.
Колыбель национального просвещения...103

Е.Ш. Сафиуллина.
Эпоха большого террора. 112

Р.И. Фатхиев.
Где же золото Шульгана? 119

Ф.Г. Галимов.
Из истории поселка Аккуль. Воспоминания старожила. 129

Д.Н. Тазиев
Киям Жафаров: автобиографические воспоминания (продолжение)..139

Р.З. Салиев.
Оклеветанный имам-хатыб. 149

Ф.К. Даминова.
Баруди, ученик Марджани. 157

Р.Р. Яушев.
Ясави: «Враг народа». 165

Р. Нотфуллина.
История села Б. Нырсы начинается со «Святых». 170

Применение краеведения в школах.

К.А. Габбасова, Д.М. Исхаков, А.Д. Хайруллина, Ф.Ф. Харисов.
Методические рекомендации по созданию Музея истории Казанского Адмиралтейства и жизни татарского населения Адмиралтейской слободы Муниципального общеобразовательного учреждения «Татарская гимназия № 15» Кировского района г. Казани. 179

Наше историко-краеведческое наследие.

Ф.Р. Яхин.
История «Книги Малики» (продолжение)..189

Исторические источники по краеведению.

Алфабет Уфимской из именной книги города Оренбурга с уездом, сколько по минувшей генеральной ревизии мужского пола душ.........201

Численность служило-татарского населения Южного Приуралья по 1 ревизии...203

Краеведческие конференции и встречи.
Письма и отклики.
Хроника событий.

Ф.А. Байрамова.
Об увиденном на Курганской земле. История курганских татар. 210

Информация о краеведческих трудах. Рецензии.

Луч света с Севера. 219

Новая книга: Рахимзянов Б.Р. Московская Русь и татарские ханства в XV–XVI вв. 224

О новой книге Р.Ф. Мухаметдинова «Тюрки в истории мировой цивилизации». 226

Татарский дух.

Р. В. Айсин.
Гаяз Исхаки: революционер, писатель и татарский футуролог. 227

Р. Р. Мингазов.
Как сохранить национальную идентичность? 231

Слово о юбилярах.

Активист ветеранского и краеведческого движения. 238

Некрологи

Памяти неутомимого краеведа..243

Сведения об авторах. 246

РЕЗОЛЮЦИЯ II ВСЕРОССИЙСКОГО ФОРУМА ТАТАРСКИХ КРАЕВЕДОВ

г. Казань 4 апреля 2018 г.

Участники состоявшегося 3–5 апреля 2018 г. в г. Казани II Всероссийского форума татарских краеведов, организованного в рамках подготовки к 100-летию Татарской АССР по инициативе известных ученых-историков, краеведов и общественных деятелей при поддержке Всемирного конгресса татар, Региональной общественной организации «Общество татарских краеведов Республики Татарстан» и «Всетатарского общества краеведов», отмечают, что данное мероприятие является значимым событием в деле дальнейшего изучения, сохранения и использования объектов историко-культурного наследия в Татарстане и регионах компактного проживания татар, подчеркивают необходимость продолжения исследования археологических, эпиграфических и историко-культурных памятников, архивных и фольклорных материалов, истории населенных пунктов, жизни и деятельности выдающихся земляков и содействия развитию музейного и историко-краеведческого дела.

Целью настоящего Форума является объединение усилий известных ученых и специалистов, краеведов и общественных деятелей, а также представителей органов власти, средств массовой информации и всех заинтересованных сторон в деле практической деятельности по решению проблем, связанных с изучением, сохранением и использованием объектов природно-географического, архитектурно-промышленного и историко-культурного наследия татарского народа, написанию истории всех населенных пунктов Татарстана и татарских сел в пределах Волго-Уралья, Сибири, Крыма и других территорий Евразии, определению стратегических задач и перспектив развития татарских сел и деревень, сохранению и приумножению национальных традиций, обычаев и духовности, укреплению национального самосознания.

В работе Форума татарских краеведов участвовали более 380 представителей татарского и других народов, представляющих краеведов 35 республик и областей Российской Федерации и всех районов и городов Республики Татарстан.

В ходе Пленарного заседания и «Круглого стола» с участием представителей научной, краеведческой, педагогической и религиозной общественности, представителей государственных структур и средств массовой информации, были заслушаны более 60 докладов и сообщений по обсуждаемым проблемам и вопросам, предложенным участникам Форума.

Участники Форума отмечают, что современное татарское краеведение имеет глубокие исторические корни. Однако, всплеск научного интереса к краеведению, национальной истории и культуре татар и других народов в прошлом произошел лишь на рубеже XIX–XX вв. В 1923 г. на базе Академического центра при Наркомате просвещения Татарской АССР было создано «Общество татароведения». Но дальнейшее развитие краеведения было приостановлено в результате известных событий 1930-х гг. В 1960–70 гг. и в начале XXI в. возникли условия для создания нескольких краеведческих объединений на базе вузов и академических центров. В последние несколько лет краеведческое движение в Татарстане и регионах компактного проживания татар в Евразийском пространстве стало активно развиваться. Ученые, краеведы и общественные деятели при поддержке местных властей и спонсоров проводят исследовательские работы по изучению объектов историко-культурного наследия в полевых условиях, по введению в научный оборот архивных и музейных материалов, проведению региональных и международных конференций по проблемам истории регионов и населенных пунктов, публикации научных и популярных краеведческих книг и учебных пособий по истории Родного края. В сельских школах и районах открываются новые краеведческие музеи, устанавливаются памятные обелиски по увековечиванию памятных дат и памяти земляков, снимаются фильмы и передачи по местной истории. Все это постепенно привело к началу объединения ученых и любителей истории в краеведческие общества и клубы в Татарстане, Башкортостане и других регионах страны. Этому процессу активно содействовали представители научной, педагогической, музейной, религиозной общественности и Всемирный конгресс татар.

В Казани, Уфе и в других городах и регионах были проведены региональные и зональные конференции и съезды. В итоге было создано Всетатарское общество краеведов. Официально оно было оформлено в ходе I съезда 24–25 марта 2017 г. в Казани. Настоящее собрание является II Всероссийским форумом татарских краеведов. Отметим, что к началу Форума был официально зарегистрирован Устав Региональной общественной организации «Общество татарских краеведов» Республики Татарстан (председатель – А. А. Бурханов), зарегистрирован и издан первый номер ежеквартального краеведческого журнала «Туган жир/Родной край» (гл. редактор – Д. М. Исхаков). Идет работа по регистрации Устава Всетатарского общества краеведов.

В целях дальнейшего изучения, сохранения, использования и распространения историко-культурного наследия в рамках написания истории татарских сел и определения перспективных направлений развития на-

циональных традиций, обычаев и духовной культуры в Татарстане и на остальной территории РФ, участники II Всероссийского форума татарских краеведов, основываясь на основных положениях и предложениях, высказанных в докладах и сообщениях, в ходе Пленарного заседания и Круглого стола, предлагают:

1. Признать завершенным организационный этап развития краеведческого движения в Республики Татарстан. Одобрить регистрацию Устава Региональной общественной организации «Общество татарских краеведов» РТ. Совету РООТК РТ ввести изменения в состав Совета с учетом реальных изменений в структуре и продолжить работу по организации новых краеведческих подразделений в районах и городах республики.

2. Завершить подготовительную работу по регистрации Устава «Всетатарского общества краеведов» и усилить деятельность по оформлению ее региональных отделений.

3. Просить руководство Всемирного конгресса татар рассмотреть вопрос о выделении штатных единиц для активизации и расширения деятельности Региональной организации татарских краеведов РТ.

4. Просить Правительство Республики Татарстан о выделении целевого гранта на ежегодное проведение конкурса на лучшую краеведческую работу (в нескольких номинациях) с обеспечением издания лучших работ.

5. Обратиться в Академию наук РТ и Министерство образования и науки РТ с предложением о написании (с участием ученых и краеведов) и издании многотомной истории татарских сел Татарстана и Российской Федерации.

6. Изучить вопросы о создании специального фонда по содействию деятельности краеведов, занимающихся изучением истории татарских сел.

7. Подготовить и принять программу деятельности Региональной организации татарских краеведов РТ на 2019–24 гг.

8. Организовать официальный сайт РОО «Общества татарских краеведов» РТ и продолжать работу по размещению материалов о деятельности краеведов на сайте ВКТ.

9. Наладить сотрудничество и объединить усилия по совместной деятельности краеведческих структур с научными центрами, вузами, музеями, архивами, школами, общественными организациями и благотворительными, государственными фондами.

10. Обратиться к руководству ТРК «Новый век» с предложением об организации специальной краеведческой программы на татарском и русском языках.

11. Обратиться к правительству РТ, руководству ВКТ, Академии наук РТ и Министерству образования и науки с предложением о проведении ежегодных Всероссийских научно-практических конференций по проблемам региональной истории и краеведению (с 2019 г.).

12. Рекомендовать руководству районов РТ и татарских национально-культурных центров и автономий в регионах РФ продолжить традицию проведения региональных и всероссийских научно-практических конференций с целью фундаментального изучения и широкого распространения историко-культурных знаний по истории татарского народа и татарских населенных пунктов и регионов.

13. Обратиться к государственным органам и региональным органам власти РТ и РФ, общественным организациям, органам культуры и образования, научной общественности с предложением объединить силы для совместной работы по изучению, сохранению и использованию природно-географических и историко-культурных объектов, истории населенных пунктов и исчезнувших сел, жизни и деятельности выдающихся земляков, а также использованию памятников прошлого для развития регионального и международного туризма, воспитания молодежи в духе патриотизма и любви к родному краю.

14. Участники Форума и краеведы выражают благодарность членам Оргкомитета, руководству и сотрудникам структур Всемирного конгресса татар за активную работу по подготовке и проведению данного мероприятия, а также участников форума – ученых, краеведов, общественных деятелей, представителей СМИ и государственных структур – за выступления с докладами и сообщениями, организацию выставок, семинаров, презентаций и культурной программы.

Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары

Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения.

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЯШЕРЕНГӘН МИЛЛИ ТАРИХЫБЫЗ

Д.М. Исхаков

Татар халкының тарихы бик тирән һәм күп катламлы, шуңа күрә дә аның инде язылган һәм басылган вариантлары ахыргача җиткерелгән дип уйласак, бу фикер ялгыш булыр.

Тарихыбызның яңадан яңа битләрен ачу, аларны киң катлам укучыларыбызга җиткерү бурычы бу дәвердә әле дә тора һәм алга таба да торачак. Дөрес, берничә буын татар тарихчыларының хезмәте нәтиҗәсендә милли тарихыбызның төп юнәлеше инде билгеләнде, фактик мәгълүматлар да җыелды һәм анализланды. Ләкин күп тарихи мәсьәләләр өйрәнелеп бетмәгән килеш кала бирә, чөнки чыганаклар җитәрлек түгел, булганнары да бик берьяклы – күбесе урыс чыганаклары. Ә аларны объктив дип булмый.

Шуңа күрә дә яңа тарихи чыганакларны табу, аларны фәнни әйләнешкә кертү галимнәребезнең төп бурычы. Бу өлкәдә дә уңышлар юк түгел. Мәсәлән, соңгы вакытларда гына Казанда Үтәмеш-хаҗиның «Кара таварих» (XVI йөз) әсәре (элекке версиясененең атамасы – «Чыңгыз-намә» иде), Габделгаффар Кырыминың «Умдәт әл-әхбәр» (XVIII йөз) исемле хезмәте басылды. Шулай ук күләмле дини-фәлсәфи трактат та дөнья күрде – сүз Әбү Бәкер Каландар Руми тарфыннан Кырымда XIV йөздә иҗат ителгән «Каландар-намә» әсәре турында бара. Әмма, бу чыганаклар гына гаять киң булган урта гасыр тарихыбызны яктыртып бетерә алмыйлар, киресенчә, аларны укыган вакытта күпсанлы җавабы булмаган яңа сораулар барлыкка киләләр. Димәк, өстәмә тарихи чыганакларсыз булмый. Кай җирдән алырга соң аларны?

Чыганаклар табу кыен бер эш булганлыктан, тарихыбызның мәгълүмати кырын киңәйтүнең тагы бер юнәлешен күрсәтү кирәк – ул да булса, инде билгеле тарихи чыганакларга яңа анализ ясау аркылы (ә моның өчен аларга хәзерге фән дәрәҗәсеннән караучы методологик нигез таләп

ителә) элек безнең күзебезгә «күренмәгән» нәрсәләрне «өстерәп чыгаруга» ирешү юлы. Мондый ысул мөмкин генә түгел, ә фәндә киң кулланыш тапкан юл, әмма ләкин безнең милли тарихчыларыбыз арасында түгел, күбрәк Көнбатыш галимнәре арарсында. Бу очракта сүз беренче чиратта инде күп тапкырлар кулланылган традицион тарихи чыганаклар турында түгел – гадәттә, алар инде нык «тапталган» булалар – ә тарихи тикшерүләр өчен бераз ятрак булган турыдан-туры тарих өлкәсенә карамаган чыганаклар турында бара.

Шулар арасында без фольклор әсәрләрен, бигрәк тә эпос/дастаннарны, тарихи риваять/легендаларны атар идек. Мондый чыганакларга тарихи анализ ясап булганлыгын (хәлбүки, күп кенә тарихчы галимнәр моны инкарь итсәләр дә) исбат итүче хезмәтләр дөньяда бар. Мисал итеп без инглиз телендә басылган америка тарихчысы Девин Де Виз (Devin De Weese) хезмәтен китерер идек [De Weese, Devin: 1994]. Күрсәтелгән юнәлештә эш башлауның кирәклеге турында без инде язган идек [Исхаков: 2017]. Ләкин хәзер татарда сакланган фольклор әсәрләренә, иң башлап, дастаннарыбызга, конкрет анализ ясау турында бара сүз.

Моның өчен без өч дастанны сайлап алдык – «Түләк һәм Сусылу», «Идегәй» һәм «Чура батыр» эпосларын. Безнең алдагы төп бурычыбыз, шушы әсәрләргә тарихи анализ ясап, алар эчендә моңарчы күзгә ташланмыйча калган тарихи әһәмияте булган мәгълүматны туплау, күрсәтү. Нәтиҗәдә, татар фольклорының тарихи чыганак буларак куллану мөмкинлеге, аның тарихи потенциалы ачылачак. Һәрхәлдә, без моңа өмет итәбез. Әгәр бу эш уңышлы булып чыкса, фәнни әйләнешкә яңа бер комплекс чыганаклар һәм мәгълүмат базасы кереп китәчәк. Соңгысы, чыганаклары чикләнгән милли тарихыбыз өчен гаять әһәмиятле булыр дип уйлыйбыз.

Беренче язма: «Түләк һәм Сусылу» дастанында тарих.

Татарлар һәм башкротлар арарында таралган «Түләк һәм Сусылу» дастаны XIX йөздән башлап фәнни әйләнешкә кергән һәм фольклор әсәре буларак шактый өйрәнелгән эпик әсәр (тулырак карагыз – [Фахрутдинова: 2011]). Бу дастанның шушы ике халык арасында таралганлыгы турында әйтелгән вакытта, без искәртеп китәргә тиешбез – аның иң борынгы һәм тулы версиясе язма рәвештә (кульъязмасы XVI йөзгә карый) татарларда гына сакланган (әсәр турында аналитик мәгълүматны түбәндәге хезмәттә укый аласыз – [Госманов: 1994, 225–300 бб.]), башкортларда исә ул кыскарак формаларда халык аваз иҗаты әсәре буларак телдә генә яшәп килгән. Бу очракта безнең бурычка шушы дастанны язып алу, аның язма һәм телдә сакланган төрле версияләрен җыю, аларны фольклор әсәре буларак өйрәнү тарихы керми. Ул турыда сез М. М. Госманов һәм А. Р. Фархетдинова (Фахрутдинова) хезмәтләреннән кирәкле мәгълүматны ала аласыз. Безнең

төп бурыч, инде әйтелгәнчә, дастаннан милли тарихыбызга караган информацияне табып, аны тарих фәне кысаларында анализлау.

Алга таба фикерләү өчен башта «Түләк һәм Сусылу» дастанының төп сюжет линиясе турында әйтеп китү кирәк. Түләк атлы шәхес (ул затлы нәселдән булып, аның кемлеген алга таба ачыкларбыз) үзенең иптәшләре (яисә «туганнары») белән конфликтка кереп, Җайык суы җирлегеннән ерак булган төбәккә качып барганда күл янында су пәрие Чачдар ханның кызы булган Сусылу белән таныша һәм ахыр чиктә аның белән кавышып, су астында яши башлый. Ләкин анда берникадәр вакыт торгач, ватанын сагынып, Чачдар хан рөхсәте белән, могҗизалы юл аркылы, сихри бүләкләр алып, Сусылу белән бергә туган иленә кайтарыла. Ул шунда бер дәвер хан булып торганнан соң үлгәч, ике ел аның улы – Габдулла ханлык итә. Дастан болай бетә: *«...Түләкнең угылы дөнйадин үткәннән соң, Балкан тау, алтын тәхет, пулат сарай, бал дәрйасы, дүрт тарафдин акган су дәйрәсы, бергә килгән халкы, милке – барчасы бер кичәдә гаиб булып, юк булды. Һәм адәм кайда киткәнен белмәделәр»* [Госманов: 1994, 261–262 бб.].

Кем соң ул, дастанның төп герое булган Түләк (тагы бер исеме – Заятүләк)? Бер карашка гади генә булган шушы сорауга җавап бирү чынлыкта җиңел түгел, чөнки сүз бит эпик шәхес турында бара һәм аның кемлеге мәсьәләсе дастанда тиз генә ачып салынмый, дөресрәге, ул яшерелгән. Бер яктан, Түләк үзенең этисе дип Мирказый бине атый (исеменең язылыш вариантлары: Мыркас/Миркас/Миркасык/Сары-Мыркас), ләкин, икенче яктан, аның атасы дип легендар Бачман хан да күрсәтелә. Әмма, дастанның төрле вариантларын ныклап өйрәнү шуны күрсәтте: чынлыкта Бачман мөстәкыйль фигура, нindидер башка бер ханның атасы. Шуңа күрә, ул кайбер очракта эпоста Түләкнең «атасы» дип аталса да, мантыйкка каршы килеп шул ук вакытта Түләкнең атасы буларак Мирказый би (бай) искә алына. Бу каршылыктан чыгу өчен дастанның иң борынгы язма версиясендә (XVI йөз) мондый сүзләр әйтелә: *«...Бачман хан дигән бер хан угылы ирде... Алтмыш йегет хезмәтче-нүкәре бар иде... Алтмыш беренчесе Миркасык би угылы Түләк атлы иде. Түләкне хан үз катына алды. Түләк бер йалгыз угыл иде»*. Димәк, Түләк алынган яисә ханга хезмәткә килгән би баласы булып чыга.

Эш әле моның белән генә бетми, чөнки башкортлар арасында сакланган дастан версияләрендә Түләкнең атасы булып тагы берничә шәхес күрсәтелә: Албыр йолкыш, Миңнехуҗа карт, Сәмәр хан. Бу очракта телдә сакланган дастан вариантларында сюжетлар нык кысткартылган булу белән бергә аларны сөйләп бирүчеләр эпик әсәргә үзләреннән өстәмәләр дә кертхән булырга мөмкиннәр. Һәлбүки, югарыда китерелгән исемнәрне дә тиз генә алып атарга ярамый, чөнки аларның кайберәүләрендә тирән мәгънә бар, ул турыда алда әле сүз булыр.

Ә гомумән алганда, «Түләк һәм Сусылу» дастанында кайбер вакыт үтү белән бәйле үзгәрешләр күзәтелә, бигрәк тә аның Бичман хан белән бәйле борынгы өлеше турында, аның үзгәртелеп, кыскартылып бирелүен әйтеп китү кирәк. Ничек кенә булмасын, дастаннан без түбәндәге шәҗәрәне китереп чыгара алабыз: Түләк ← Мирказый би ← [?]. Ләкин бу шәҗәрәнең иң әһәмиятле өлеше Түләктән соң килгән буын – ул Түләк үлгәннән соң ике ел ханлык иткән аның улы Габдулла. Димәк, безнең каршыбызда чынлыкта мондый шәҗәрә пәйдә була: Габулла (хан) ←Түләк (хан) ← Мирказый би ← [?].

Ә менә бу шәҗәрә инде чынлап та кызыклы. Ни өченме? Ә менә ни өчен: «Дәфтәре Чынгыз-намә» (XVII йөз ахыры) дип аталган Идел буе татарларында билгеле булган чыганакта Габдулла хан Болгар шәһәрендә Аксак Тимер заманында хөкем итүче буларак билгеле. Шулай ук ул ханның 120 «олуг биге» арасында дүртесе «асыл шаһзадәләр» дип аталып (аналары хан кызлары булган булса кирәк), аларның берсенең исеме «Миркаши бик» дип бирелә [Мирастан: 2011, 60 б.]. Күренә ки, соңгы исем Түләкнең атасының исеменә якын – Миркаш/Мирказый/Мыркас.

Үз чиратында, Түләкнең исеме тарихи чыганаклардан билгеле Мамай тарафыннан 1380-нче елны хан итеп тәхеткә утыртылган Тулукбек (Тюляк) исеме белән тәңгәл. Шулай ук Мамай Урдасында Абдаллах исемле шәхеснең хан булганлыгы да билгеле. Без бу фактка игътибар итәргә тиешбез, чөнки «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дән күренгәнчә, легендар Габдулла ханның «уллары» – Алтын бәк (Алтынбәк) һәм Галим (Алим) бәк, Болгар/Казан вилайәтендә Олуг-Мөхәммәд ханга кадәр хөкем итүчеләр булганнар (бу турыда карый аласыз – [Исхаков: 2013]). Дөрес, эпик Габдулла һәм Түләкнең хан булып утырулары белән тарихи Абдаллах һәм Тулукбек (Тюляк) атлы шәхесләрнең тәхеттә утыру тәртипләре туры килми: Мамай Урдасында Абдаллах, сугылган акчаларыннан күренгәнчә, Тулукбектан алдарак, 1361/62–1369/70-нче еллар арасында хан тәхетен биләгән. Әмма, безнең фикеребезчә, эпик әсәрдә мондый урыннар алышыну мөмкин. Шуның өстенә, югарыда китерелгән исемнәрнең бер үк кешеләр белән бәйле булганлыгын исбатлаучы башка мәгълүматлар да бар.

Алар арасында иң әһәмиятлесе Үтәмеш-хаҗиның «Кара таварих» әсәрендәге мондый юллар: *«[Мөхәммәд хан, ягъни Олуг-Мөхәммәд – Д.И.] ...барган белән барыб Казан вилайетин хәйлә берлә Албай Алтун байдин алыб, анда хан булды...»* [Утемиш-хаджи: 2017, С. 155]. Бу информацияне тулыландыручы икенче чыганак – Габделгаффар Кырыминың «Умдәт әл-әхбәр» әсәре. Анда Олуг-Мөхәммәд турында сөйләнгәндә, әйтелә: *«...ул дахи Казан семтине баруб нәселе Шибандан олан Алтунай солтандан хәйле берлә Казанны олуб...»* [Кырыми: 2014, С. 112]. Күренә

ки, Үтәмеш-хаҗидагы «Албай» һәм «Алтун бай» – икесе ике шәхес. Аның беренчесе – татар чыганакларында билгеле булган Али/Гали бий (бәк). Ул урыс чыганакларында да «Либей», «Али-Баба» буларак күренә. Икенчесе исә Шибан нәселеннән булган Алтынай исемле солтан булып чыга. Димәк, «Дәфтәре Чынгыз-намә» әсәрендәге Габдулла ханның «уллары» буларак күрсәтелгән Алтын бәк һәм Галим бәк – икесе ике шәхес кенә түгел, ә ике статустагы кеше – Алтынай (Алтынбай→Алтынай) ул солтан, хан углы (Габдулла хан нәселеннән), ә Галим (Алим, Али) – бәк, ягъни, кенәз титуллы кеше. Ә кем нәселеннән соң ул соңгы шәхес?

Шушы сорауга җавап бирү өчен безгә күп кенә эзләнүләр үткәрү кирәк булыр, әмма, ул эзләнүләр вакытында без бер әйберне истән чыгармаска тиеш – кайбер рус елъязмаларында ул шәхес «казанский вотчич»дип исемләнә [ПСРЛ. Т. 8: 1859, С. 114]. Ягъни, бу очракта Гали/Галим бәк «Казан кенәзе», нәселдән-нәселгә Казан/Болгар вилайәтендә утыручы хөкемдар буларак билгеләнә. Әмма, ул бу биләмәдә үзе генә утырмый – аннан башка анда Шибан нәселеннән булган солтан да булган. Моның шулай булганлыгын раслаучы факт 1429-нчы елга карый. Рус елъязмаларында шул ел астында татарларның Галич һәм Кострома шәһәрләренә һөҗүме, аларның рус гаскәрләре тарафыннан эзәрлекләнүләре әйтелгәч, мондый җөмлә китерелә: *«... полон отняша, а царевича и князя Али-Бабы не догониша»* [ПСРЛ. Т. 28: 1963, С. 98].

Тарихчылар инде бу татарларның Казан (Болгар) вилайәтеннән икәнлекләре турында язганнар иде. Шуңа өстәп әйтергә кирәк – гаскәрдәге «царевич», ягъни, солтан – Алтынай булса, Али-Баба (дөресрәге – Али бий булса кирәк) бу очракта Галим/Алим бәк булып чыга. Чынлыкта бу ике шәхес Иван IV ногай морзасы Урус белән хәбәрләшүендә дә күренә (1576 ел). Анда түбәндәге фраза бар: *«...и Алибаев, и Алтын б[ае] в [юрт] Болгарской»* [Посольская: 2003, С. 47]. Документка игътибар иткән мәскәүле тарихчы В. В. Трпавлов күрсәткәнчә, бу очракта без Казан ханлыгының бер өлешен анда беренче хөкемдар булып утыручыларның исемнәре аркылы атау белән очрашабыз. Шулай ук ул югарыда күрсәтелгән ике «эпонимны» легендар Габдулла ханның «уллары» белән бәйләп карарга тәкъдим итте [Посольская: 2003, С. 82].

Димәк, берникадәр дәрәҗәдә без Болгар/Казан җирлегенә килеп керәбез. Һәм бу җирлек дастанда чынлыкта бер дә юкка гына барлыкка килми, чөнки «Түләк һәм Сусылу» әсәре безгә мондый нәтиҗә ясау өчен өстәмә дәлилләр бирә. Хәзер без аларны барлап үтик.

Күзгә ташланган беренче мәгълүмат – 1374 елны кайбер рус елъязмаларында Болгар шәһәреннән ерак түгел «Моркваши» топонимы күрсәтелә [ПСРЛ. Т. 15: 2006, С. 106]. Бу топоним «Дәфтәре Чынгыз-намәдә» искә

алынган югарыды аталган Миркаши бәк исеменә генә түгел, ә «Түләк һәм Сусылу» дастаныныда Мирказый/Миркасык/Мыркас исеменә дә бик якын. «Дәфтәре Чынгыз-намәдә», инде әйтелгәнчә, Миркаши бәк 4 шаһзадәнең берсе буларак атала һәм ул Габдулла хан хөкем иткән, үзәге Болгар шәһәрендә булган, биләмәдә яшәгән. Күренә ки, монда Алтын Урданың Болгар вилайәте күз алдында тотыла.

Тагы бер деталь. Башкортларда сакланган «Түләк һәм Сусылу» дастанының кайбер вариантларында ике агай-эне искә алына һәм алар анда, ахырысы, Түләкнең (Заятүләкнең) абыйлары буларак аталалар. Бу ике шәхеснең берсенең исеме –Алтын бай, икенчесенең – Етем (Ете) бай. Шулай итеп, беренче исем Болгарда хөкем иткән хан белән бәйлелеген билгеләмичә генә Үтәмеш-хаҗида һәм Габделгаффар Кырымида Болгар/Казан биләмәсендә күрсәтелгән Алтун бай/Алтунай солтанның исеме белән туры килә.

Бу уңайдан, безгә кайбер татар шәҗәрәләрендә булган бер шәхескә дә игътибар итәргә кирәк. Чөнки ул шәҗәрәдәге шәхес «шәһри Болгар» белән бәйле рәвештә атала һәм, иң әһәмиятлесе, шушы шәҗәрәнең кайбер версиләрендә аларның беренче буыны итеп «Кырымнан чыккан» Габдулла хан күрсәтелә [Әхмәтҗанов: 1995, 35 б.]. Бу сюжет әле алга таба анализланыр, ләкин инде әйтелгәне дә Түләкне һәм Габдулланы Болгар/Казан биләмәсе белән бәйләп карарга мөмкинлек бирә.

Шушы фикерне ныгыту өчен безгә «Түләк һәм Сусылу» дастанындагы тагы бер сюжет линиясен карап үтәргә кирәк.

Инде күргәнебезчә, ханлыкка Түләктән соң Габдулла күтәрелә. Аның атасыннан калган могҗизаи әйберләре арасында алтын тәхет тә була. Ул тәхет эпоста түбәндәгечә барлыкка килә: Түләк, Чачдар хан биләмәсендәге Сусылуның сараенда яшәгәндә, туган җирен сагына башлаган һәм шул вакытта сарай каршында кинәттән генә алтын тәхет пәйда була. Менә аның тасвирламасы: *«...алтын тәхет сарайның алдында корылмыш, сәкез кырыны, дүрт тарафыны тимер берлә коршаган [бер таг] тәхетдин йукары калкып сайә (ышык – Д.И.) кылып торыр. Ул тагны алтын берлә коршаган, башыны ак мәрвәр (энҗе) берлә йапкан. Турт йаны агач үскән...»* [Гоманов: 1994, 250 б.]. Тәхетне күреп, аның өстенә менеп утырган Түләк, болай ди:

Алтын тәхет урнаткан,
Көмешдин айак йараткан,
Тәхет – бәхет түрәткән...

Менә шушы алтын тәхет – ә ул гади генә тәхет булмаган, без моны алга таба аңларбыз – Түләк Тәңрегә үзен һәм Сусылуны туган иленә

күчерүне сорагач (исегезгә төшерәм, алар су асты патшасы Чачдар хан биләмәсендә яшиләр), алар белән бергә «олуг шәһәр» янына ул басып торган Балкан тау белән бергә күчерелә (шундый исемдәге тау Башкоростанда, Давлекан районында урнашкан Асылы күл дип аталган зур күл янында хәзәр дә бар). Легендар мәгълүматлар буенча, Түләк һәм Сусылу шул тауның өстендә күмелгән булганнар һәм анда Түләк исеме язылган кабер ташы да булган. Түләк, Чачдар ханның су астындагы биләмәсенә килгәч, үзенең «җире һәм суы» турындагы сорауга, әйтә: «Туган җирем – Балкантау, эчкән суым – Дим. Башка күп җир-су Дим белән Балканга буйсынган». Ләкин чынлыкта Түләк ханлык иткән урын башка җирдә була.

Чынлап та, дастаннан күренгәнчә, озак вакыттан соң Түләк «атам йорты» дип исемләнгән «олуг шәһәрле» биләмәгә кире кайткач – нәкъ ул кайтуга анда элекке падишах/хан үлгән була – андагы халык һәм олуг биләр, вәзирләр һәм бөекләр (әкәбирлар) аны «солтан улы», – дип танып, ханлыкка күтәрәләр. Бу вакытта ул биләмәдә Түләкнең атасы да, анасы да әле исән була, ләкин аның атасы, Миркас би, хатынына тегесе бу хан булып күтәрелгән шәхеснең *«гаиб булган* (югалган – Д. И.) *угылымызга охшар»*, – дип әйтүенә карамастан, аңа бу мөмкин түгел ди: *«Әй, хатын, гаиб булган угылымызга мондагъ ханлык кайда булыр?»*, – дип белдерә ул. Шулай булуга да карамастан, Түләк хан булып шушы биләмәдә өч ел утыра һәм еш кына Балкан тауга чыгып, алтын тәхетенә менеп, халыкны җыеп, думбрада уйнап, бөтен кешене дә сыйлап, күңелен ачып хөкем итә.

Әмма бер сорау туа: ни өчен монда «алтын тәхет» дип исемләнгән корылма бар һәм аның Түләкнең атасы-анасы яшәгән биләмәгә ни катнашы булган? Ул сорауга җавап эзләгәндә без тагы да бу биләмәнең Болгар вилайәте булырга мөмкин икәнлеген чамалый алабыз. Моның өчен безгә халкыбызда сакланган «Фи бейан-и тарих» исемле чыганакка мөрәҗәгать итәргә кирәк булыр.

Бу чыганакта, Габдулла хан «улларының», инде безгә таныш булган Алтынбәк һәм Галим бәкнең, Болгардан Иске Казанга күчүен тасвирлаган эпизодта (ул турыда кайбер башка чыганакларда да искә алына), мондый җөмлә әйтелә: *«...Алтын тәхетдин чыкып, Иске Казанга килделәр. Алтын тәхет дип шәһре Богарны әйтер ирмеш»* [Мустакимов: 2008, С. 155].

Шулай итеп, «алтын тәхет» торган «олуг шәһәр» Болгар вилайәте белән бәйле булып чыга. Ә «олуг шәһәр» термины үзе монголлар яулап алу алдыннан рус елъязмаларында «Великий город» дип исемләнүче Биләр шәһәре атамасына туры килә (Би – «бөек», «олуг» мәгънәсенә ия булган дип уйлыйбыз). Яъгни, дастанда сүз монголларга кадәрге Идел Болгарстаны һәм Алтын Урданың Болгар вилайәте турында бара дигән нәтиҗә ясау мөмкин бу очракта. Ә ул нәтиҗәне әле тагы кайбер башка

мәгълүматлар белән дә ныгытып була. Ләкин моның өчен безгә Түләкнең һәм аның атасының, Мирказый бинең, оныгы саналган Габдулланың нәселе турында тулырак тикшерү уздырырга кирәк. Чынлыкта, дастанда һәм кайбер башка чыганакларда сакланган информация безгә мондый мөмкинлекне бирә.

Беренче «эз» Түләкнең «кошы» аркылы килеп чыга. Дастаннан күренгәнчә, урта гасырларда ау өчен кулланган кошлар рәтеннән Түләкнең ике төр кошы булганлыгы турында әйтелә: бер версиядә ул – «ак шонкар», икенчесендә – «ак йапалак» дип билгеләнә. Бу мәсьәләне тикшергәндә шул ачыкланды: Түләкнең чын кошы шонкар/ак шонкар булып, дастанда аның икенче кошы – ябалак (ә ул кош фәкать тик башкортларда язып алынган телдә генә яшәгән эпос вариантларында күренә), аның абыйларының бер кош баласын ул ак ябалак баласы дип энеләренә яшертен рәвештә китереп куюю нәтиҗәсендә барлыкка килә. Чынлыкта исә ул үскәч ак шонкар баласы булып чыга. Дастандагы бу кош ау кошы буларак тасвирланса да, аның башка бер ягын да чамаларга була – иске төрки – монгол традициясе буенча кошлар кабилә-ыру атрибутлары рәтенә кергәннәр һәм *онгон/сүлде* – кабилә рухы буларак, әһәмиятле идеологик роль уйнаганнар (үлгән кешеләрнең рухларын күккә күтәргәннәр дип уйлаганлыктан). Моның шулай икәнлеген түбәндәге дастанда китерелгән урын раслый: Түләк югарыда күрсәтелгән тауга бәйле алтын тәхет куелган тагы (бу төшенчәне «тәхет куелган урын» дип аңларга кирәк) белән «олуг шәһәр» янына күчерелгәндә, Балкан тау өстендә ак шонкар очып йөргәнлеге турында әйтелеп, аны «миңезлик кош» дип исемли дастан. Безнең фикер буенча, ул сүзнең мәгънәсе – «шушы кошка (шонкарга) охшаган» дигәнне аңлатып, аның ак шонкар икәнлегенә ишарә ясала. Шуның өстенә, бу онгон (сүлде) ролен башкарган ак шонкарның дастаннан тагы бер функциясе дә күренә – татарларда диалекталь сүз буларак «меңге» төшенчәсе «акча, тәңкә» мәгънәсендә дә кулланылган. Алай булса, ак шонкарның акчага да мөнәсәбәте булганлыгы ачыла. Шул уңайдан, безнең хәтергә Үзбәк һәм Җанибәк ханнар дәверендә акчаларга ике башлы кош рәсеме урнаштырылуны искә төшерик. Нинди төр кош булган соң ул?

«Дәфтәре Чыңгыз-намәдән» һәм кайбер монгол чыганакларыннан күргәнчә, шонкар, төгәлрәге, ак шонкар, кыйат кабиләсенең кошы, сүлде/онгоны булган. Ә бу кабилә Чыңгызхан нәселенең шәхси кабиләсе булганлыктан (ул нәсел кыйат – бурджигин ыруыннан), шул ук кош Чыңгызыйлар нәселенең кошы да булып чыга. Һәм без өйрәнгән монгол чыганакларында («Яшерен тарих», «Алтан Тобчи») ул факт ачык чагыла – ак шонкар кыйат кабиләсенең саклаучысы, рухы буларак күрсәтелә аларда [Исхаков: 2011, С. 121]. Дөрес, «Дәфтәре Чыңгыз-намәдә» Чыңгыз ханның кошы *«ике*

баш[лы] кара кош», дип атала. Моның үз сәбәпләре бар һәм без аларны башка бер эшебездә тикшердек [Исхаков: 2007]. Монда шуны гына әйтеп китик: символик кошның ике башлы булуы һәм исеме үзгәрүе Чыңгыз хан нәселенең башка кабиләләр өстеннән күтәрелүе белән бәйле булса кирәк. Ләкин, бу очракта безгә бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бар – иң башта, борыңгы заманнарда, ак шонкар кыйат кабиләсенең кошы булган. Ә ул кабилә Алтын Урда дәүләтендә аерым бер социаль берәмлек – кабилә булып яшәгән һәм анда югары урын тоткан [Исхаков, Измайлов: 2007, С. 150–151].

Шулай итеп, Түләкнең, аның нәселенең, кыйат кабиләсе белән бәйлелеге килеп чыга. Менә мондый нәтиҗә безгә Түләкнең һәм Габдулланың, шулай ук Мирказыйның, реаль социаль статусын ыру-кабилә бүленеше аркылы билгеләнүне дә таләп итә.

Чынлап та, бу мәсьәлә буенча дастан безгә каршылыклы мәгълүматлар бирә. Бер яктан, инде әйтелгәнчә, Түләкнең атасы Мирказыйның титулы би/бий дип билгеләнә. Билгеле, Түләк бий угылы буларак, үзе дә шул статуста булырга тиеш. Әмма, эпоста күрсәтелгәнчә, ул туган иленә («олуг шәһәргә») кайткач, аны «солтан угълы» буларак каршы алалар һәм тәхеткә хан итеп күтәрәләр. Шуның өстенә, дастанда Түләкнең Бачман ханга бәйлелеге дә күрсәтелә, хәлбүки, тотрылы рәвештә түгел. Дөрес, өч ел ханлык иткәч, аның кем икәнлеге, чын нәселе ачыла, бий нәселеннән икәнлеге дә беленә, чөнки аның кемлеге турындагы сорауга, Түләк үзе дә дастанда түбәндәгечә җавап бирә: *«Мәнем атым Түләк торыр. Атам аты Миркас би... Мән сезнең үз нәселеңездән, мән йәнә үз угылызызмән»*.

Шундый ук күренеш телдә сакланган һәм башкортларда таралган дастан версияләрендә дә күзәтелә. Бер очракта Түләкнең атасы «хан» дип билгеләнә, ул үзе «хан угълы» яисә «шах» дип атала. Икенче очракта аның затлы нәселдән булуы инкаръ ителеп, атасы «йолкыш», «карт» дип кенә атала. Әмма, дастанның бөтен вариантларын да карап чыккач, шул ачыла: ахрысы, эпоста Бачман хан дип исемләнгән элекке бер төрки йортның хөкемдарының титулы Түләкнең атасы булган Мирказый биның титулы белән буташтырыла. Инде әйтелгәнчә, мондый үзгәрешне борынгы кулъязмада сакланган «Түләк һәм Сусылу» дастаны текстыннан да күреп була – анда Түләк башта «Бачман ханның угълы» дип игълан ителә, аннан соң ул «Мирказый бий» (төгәлрәк – «би» булган булса кирәк – Д. И.) угълы Түләк ирде», дип атала, аның ялгыз бала буларак ханга хезмәткә (яисә тәрбиягә) алынуы турында әйтелә.

Кызык кына нәтиҗә килеп чыга: Түләк, би нәселеннән,ягъни, кенәз статуслы кеше гаиләсеннән булса да, шактый үзенчәлекле шартларда (элекке хан үлгән, хан урынына варис эзләгәндә, Түләкнең үзен танымаганнар, аны «олуг шәһәрдә» солтан дип уйлаганнар) тәхеткә хан итеп

күтәрелә, күтәрелә генә түгел, ул, бу тәхетне, аның чын йөзе ачылгач та, улына калдыра ала.

Мондый вакыйгалар агымы Алтын Урдада ханны тәхеткә утыру принципларына каршы килә түгелме соң? Әйе, каршы килә, чөнки анда тәхетне Чыңгызхан нәселеннән булучылар гына били алган. Менә шушы дастанның эчтәлегеннән килеп чыккан каршылыкның бер чишелеше булырга тиеш. Һәм ул чыннан да бар, әмма бу мәсьәләне чишкәнче безгә эпик геройларның – Түләк һәм аның улы Габдулланың, тарихи элгәрләре булган Мамай Урдасында хан итеп күтәрелгән Тулукбек һәм Абдаллахның ханлыкка килүләренең кайбер үзенчәлекләрен барлап чыгрырга кирәк (ул турыда бөтен нечкәлекләре белән безнең элегерәк басылган хезмәтләрдән карарга мөмкин – [Исхаков: 2009; 2013]).

Билгеле булганча, Мамай төмән башлыгы һәм кыйат кабиләсенең бәге булу белән бергә (аның төп биләмәсе – Кырым) Алтын Урда да «бөек чулаышлар» заманы килер алдыннан хан тәхетендә утырган Бирдебәкнең (1357–1359) кияүе дә булган (элекке монгол традициясе буенча, ул «гурген» дип исемләнеп, югары статуска ия булган). Менә шушы Бирдебәк хан 1357-нче елны властька килер алдыннан үзенең 12 ир туганын үтерә (алар барысы да Үзбәк хан нәселеннән булганнар). Шуңа күрә дә Бирдебәктән соң кыска гына вакытта Алтын Урда тәхетендә утырган Кульна (Кульпа) һәм Нәврүз исемле шәхесләрнең төгәл шәҗәрәләре билгеле түгел. Тагы бер тәхеттә утырган хан – Килдебәк турында да чыганакларда каршылыклы фикерләр әйтелә, аны хәтта «ялган Килдебәк» дип тә атыйлар (бусы аның мәрхүм Җәнибәк ханның улы булган икән дигән карашка каршы әйтелә). Менә шушы билгесез нәселдән булган шәхесләр Сарай тәхетендә утырып алганнан соң Алтын Урдада хөкем итү өчен узара зур низаглар башлангач, Мамай үзенең гурген статусыннан файдаланып үз биләмәсендә (вакытвакыт ул Сарай шәһәренә дә керә) Абдаллахны 1361/62-нче елны тәхеткә күтәрә (аны кайбер гарәп чыганакларында Үзбәк хан нәселеннән булган дип тә күрсәтәләр, әмма моның өчен бернинди конкрет дәлил дә юк). Ул анда хан булып 1369/70-нче елга кадәр утыра. Аннан соң Мамай Урдасында 1370-нче елны Мамат солтан (Мухаммад-Бүләк) хан була (тәхеттә 1375/76-нчы елга кадәр утыра). Ә инде 1377-нче елның мартыннан 1380-нче елга кадәр Мамай Урдасында хан тәхетендә Тулукбек (Тюляк) утыра. Шуны да әйтеп китәргә кирәк – 1370–1377-нче еллар арасында (бәлки, башка елларда да, ләкин ул турыда төгәл информация юк) Болгар вилайәте дә Мамай биләмәсенә карый. Безгә бу фактларны истә тотарга кирәк.

Алга таба тагы бер әһәмиятле нюанс: 1380-нче елны Тулукбек үзенең ярлыгында Мамайны үзенең агасы дип таный. Ә бит Мамай, затлы нәселдән чыккан шәхес булса да, Чыңгызый түгел, кыйат кабиләсенең бәге

генә. Ә менә без Тулукбек (Тюляк) белән эпик Түләкне тәңгәлләштерсәк, каршыбызда берничә буын кыйат кабиләсеннән чыккан һәм бәкләр нәселеннән булсалар да, таралып барган Алтын Урданың бер кисәге булган Мамай Урдасы тәхетендә утырган шәхесләр килеп чыга. Иң кызыгы шунда – ул «тәхет урыны» чынлыкта Болгарда булган дип уйларга урын бар. Дөрес, күчмә тормышта яшәүче татарлар чынлыкта Урда кайда була, шунда күчеп йөргәннәр. Ә сарай әһелләре, бигрәк тә Сарай шәһәре Мамайның көндәшләре кулына күчкәндә, Болгар шәһәрендә яшәгән булырга да мөмкиннәр.

Чыңгызхан нәселеннән турыдан-туры чыкмасалар да, Түләкнең нәселе шул ук Бөек Монгол империясенә нигез салучының үз кабиләсенән чыгучылар арасында булган. Бәлки, Чыңгызхан белән аларның борынгы туганлыгы да булгандыр. Билгеле, Түләкне һәм Габдулланы «бөек шәһәр» тәхетенә утырту гадәттән тыш шартларда башкарылган – Бирдебәктән соң Чыңгызыйларны күпләп үтерү нәтиҗәсендә турыдан-туры бу затлы нәселдән булган шәхесләр «дефициткa» әйләнгән булырга мөмкин. Чынлыкта, алга таба – Туктамыш хан дәвереннән – сарай тәхетенә Чыңгызхан нәселеннән башка тармак вәкилләре утыра башлый.

Менә шушы гипотезаны ныгыту өчен тагы бер дәлил китерик. Әйтик, инде югарыда каралган «Фи бейан-тарих» исемле чыганакта, Алтынбәкнең тамгасы аталышы (әвернә) һәм рәсеме буенча (×) «Дәфтәре Чыңгыз-намәдә» искә алынучы кыйат кабиләсеннән булган Буданжар бәкнеке белән туры килә. Әгәр дә без ул кабилә билгеләрен гомумән Габдулла хан нәселенеке дип карасак, тагы бер чыганак әйтелгән фикерне раслый ала. Инде күрсәтелгән «шәһри Болгардан» чыккан «Олыс бие, Чыңгызхан биләреннән» булган шәхеснең шәҗәрәсе, кайбер варианларында, «Кырымнан чыккан Габдулла ханнан» башланып кына калмый, ике кабилә билгесе аркылы – тамгасы һәм агачы (карагай) буенча, кыйат кабиләсенекенә туры килә (кошы туры килми – ул «күчәгән» дип атала; бу очракта, бәлки, шәҗәрәгә хатын ягы кабиләсенең атрибутлары килеп кергәндер).

Менә хәзер безгә яңадан «Түләк һәм Сусылу» дастанына әйләнеп кайтып, аның эченә яшерелгән милли тарихыбызның моңарчы билгеле булмаган якларын торгызуны башкарып чыгу кирәк.

Нәрсә соң ул дастанда күренеп киткән «алтын тәхет»? Мәсьәләне ныклап өйрәнү шуны күрсәтте – ул Чыңгызхан замныннан, бәлки аңа кадәрге дәвердән үк килүче, власть символы. Алтын Урдада андый тәхет булган, әмма «алтын» дип билгеләнүе чыганакларда сакланмаган. Ләкин, Ибн Баттута язмаларыннан «алтын чатыр» эчендә торган алтынланган көмеш белән капланган тәхет билгеле. Гарәп сәяхәтчесе, аның аякларының көмештән ясалганлыгын күрсәтеп, өске ягының кыйммәтле ташлар

белән бизәлгәнлеген әйтә [Золотая Орда. Т. 1: 2003, С. 132–133]. Үз чиратында, шундый ук алтын чатыр һәм алтын белән капланган тәхет Бөек Монгол империясендә дә булган [Исхаков: 2014, С. 185–186]. Әгәр дә Ибн Баттута язмасындагы тәхет тасвирламасын дастандагы тасвирлама белән чагыштырсаң (аяклары көмеш, тәхетнең – тагның өске ягы мәрвәр/энҗедән), аларның тәңгәллегенә шак катасың! Ахрысы, «Түләк белән Сусылу» дастаны авторы (авторлары) ул тәхетне күргән булганнар.

Икенче бер әһәмиятле элемент: «Дәфтәре Чыңгыз-намәдә» Болгарда (чынлыкта, таркала башлаган Алтын Урданың Мамай контроле астындагы бер өлешендә) хан булган Габдулла янында дүрт «олуг бәк/шахзадә» булганлыгы турында әйтелә. Ә «Түләк белән Сусылу» дастаныннан күргәнчә, Түләк янында да «олуг биләр» була, халык аны тәхеткә күтәрүдә катнашса да, ул мәсьәләне хәл иткәндә башта «шәһәрнең олуглары» җыелып сөйләшәләр, аннан соң Түләкнең сарае янына «олуг вәзирләр һәм әкябирләр (бөекләр)» барып, аның белән күрешәләр һәм нәкъ шулар аңа тәхет тәкъдим итәләр дә. Чынлыкта соңгы очракта Алтын Урдадагы традицион хан күтәрү механизмы ачылып бетмәсә дә – тәхеткә бу дәүләттә ханны 4 карачы бәк күтәргән – дастан шул турыда ук сөйли. Аны дастандагы түбәндәге юллар да раслый: шәһәрнең «бөекләре» әйтүе буенча, «ханнарыннан угыл-кыз калмау» сәбәпле, карар кылына – әгәр дә *«таңдагы көн төш вакытына тигрү һәркем килсә, ханлыкга күтәргәймез тидек... [,] имде сәне тәхеткә күтәрәле»*, – дип әйтелә. Монда «тәхеткә күтәрү» дигән сүзләр нәкъ традицион гадәт турында сөйли – Алтын Урдада ханны чынлап та 4 карачы бәк ак киезгә утыртып тәхеткә меңгергәннәр.

Ә инде дастанда сөйләнгән Түләкнең алтын тәхеткә утырып халыкка бәйрәмнәр оештыруы аның чын хөкемдар булганлыгын раслый торган бер әһәмиятле күрсәткеч. Түләктән соң ике ел хан булып утырган Габдулла *«дөнйадан үткәч»* аның алтын тәхетенең юкка чыгуы да бу дәүләтнең таркала башлаганлыгы турында безгә бер ишарә бирә.

Һәм соңгы бер күзәтү. Түләк «олуг шәһәр» белән бәйле рәвештә ханлыкка күтәрелсә дә, кайвакытта Балкан тауга чыгып, барча халык белән бергә күңел ача. Бу табигатькә чыгып, анда җырлап-биеп ашау-эчүләр, корбан чалулар күчмә тормыш элементлары булса кирәк. Ягъни, Түләкнең халкы, малы әле җәйләүгә чыга торган булган. Алтын Урданың XIV йөзнең икенче яртысы – XV йөзнең башларындагы яшәеш формаларын мондый рәвештә тасвирлау чынлап та дөреслеккә туры килә.

Иң ахырдан әйтеләсе нәрсә шул: Болгар вилайәте җирлегендә хөкемдар булып торган кыйат кабиләсе вәкилләре (аларның ким дигәндә өч буыны чамалана: Мирказый бий – Түләк хан – Габдулла хан) турында алга таба әле тагы бер зур сөйләшү кирәк булыр. Чөнки Габдулла белән

бәйле легендар Алтынай (Алтынбай) солтан һәм Галим бәк (соңгысы – «Казан вотчичы» буларак), инде әйтелгәнчә, икесе ике шәхес булып, бәлки турыдан-туры үзара туган булмаганнардыр, ләкин алар арасында бер бәйлелек, чынлыкта, бар. Аны ачып бирү өчен башка бер зур язма таләп итәлә һәм ул бу сериядә булмас, ә аерым бер сакланып калган тарихи риваятьләрне һәм язма чыганакларны анализлау аркылы башкарылыр.

(Дәвамы бар)

Әдәбият

1. Госманов М. Г. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.
2. Золотая Орда в источниках. Том первый. Арабские и персидские сочинения. Сб. материалов, относящихся к истории Золотой Орды, в переводах В. Г. Тизенгаузена. Ч. I–II. Сост., ввод. ст. и комм. Р. П. Храпчаевского. М., 2003.
3. Исхаков Д. М. Между Булгаром и Казанью: этнополитические процессы в Булгарском/Казанском вилайяте в 60–70-х гг. XIV–40-х гг. XV вв. Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2013.
4. Исхаков Д. М. Булгарский вилайат накануне образования Казанского ханства: новый взгляд на известные проблемы//Гасырлар авазы. Эхо веков. 2009. № 9. С. 123–138.
5. Исхаков Д. М. Об отражении некоторых золотоордынских реалий в татарско-башкирском дастане «Туляк и Сусылу»//Золотоордынская цивилизация. Сб. статей. Вып. 4. Казань: ООО «Фолиант», Институт истории АН РТ, 2011. С. 119–127.
6. Исхаков Д. М. «Дом Чингиз-хана» (Алтын Урук): Клановая принадлежность и ее атрибуты//Этнополитические исследования в Татарстане. Вып. I. Материалы итоговой конференции Института истории АН РТ, 2007. С. 18–27.
7. Исхаков Д. М., Измайлов И. Л. Этнополитическая история татар (III–середина XIV вв.). Казань: РИЦ «Школа», 2007.
8. Исхаков Д. М. Золотоордынская этнология татар: 1. Эпический и исторический «золотой трон» («алтын тәхет») // Золотоордынское обозрение. Golden Horde Review. 2014. № 3(5). С. 175–190.
9. Исхаков Д. М. Милли дастаннарыбызда, тарихи риваятьләребездә төбәк тарихы//Туган җир: Төбәк тарихы буенча басма [Родной край: Краеведческое издание]. Вып. 1. Казан: ТРФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. 34–38 бб.
10. Кырыми Абдулгаффар. Умдет ал-ахбар. Книга 1: Транскрипция, факсимиле. / Транскр. Дерья Дерин Пашаоглу; отв. ред. И. М. Миргале-

ев./Серия «Язма Мирас. Письменное Наследие. Textual Heritage». Вып. 4. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017.

11. Мустакимов И. А. Термин «Золотой престол» в Поволжье по данным арабографических источников (к вопросу о статусе г. Булгара на ордынском и постордынском пространстве) // Гасырлар авазы. Эхо веков. 2008. № 1. С. 142–157.

12. Мирастан биш сәхифә. XVII–XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре/[транскр. эшләүче, хәзерге татар әдәби теленә күчерүче, иск. һәм сүзл. төз., кереш мәкаләләр авт. С. Гыйлаҗетдинов]. Казан: Татар кит. нәшр., 2011.

13. ПСРЛ. Т. 8. Продолжение летописи по Воскресенскому списку. Ч. VII. СПб., 1859.

14. ПСРЛ. Т. 28. Летописный свод 1497 г. Летописный свод 1518 г. (Уваровская летопись). М., Л.: Наука, 1963.

15. ПСРЛ. Т. 15. Рогожский летописец. Тверской сборник. М., 2006.

16. Посольская книга по связям России с Ногайской Ордой (1576 г.). М., 2003.

Поверхность поселения в целом ровная, слегка поката к речке, имеет небольшие ложбины. С восточной и западной сторон резко выраженных естественных границ нет. Но в южной стороне, у деревни, проходят с

4 В литературе этот памятник встречается под названием Урматское (Русско-Урматское) селище (селение) и иногда городище [см.: Калинин, Халиков: 1954, С. 99; Фахрутдинов: 1984 а, С. 131–134; Кокорина: 1993, С. 55–61].

5 Эта же территория закреплена как охранная зона ИКГМЗ.

запада на восток три почти параллельных оврага, напоминающие своими прямолинейными очертаниями искусственные фортификационные сооружения. Длина оврагов более 60 м, а глубина до 7 м. Вся линия предполагаемых оборонительных сооружений в южной части достигает ширины 200 м. Кроме того, правый берег Урматки – крутой (до 13 м) и, возможно, имел также оборонительное значение. В северной части (вблизи от железной дороги) также имеется глубокий, но более короткий овраг. По мнению Н.Ф. Калинина, если учесть, что все указанные естественные препятствия были усилены еще стенами и башнями, то Урматское поселение было типичным средневековым городом. Исходя из этого, исследователь считал «в археологическом смысле остатки Урматского селения городищем» [Калинин, Халиков: 1954].

Исследования 1997 г. дали новые материалы, подтверждающие, что Урматское поселение – это, скорее всего, городище, а не селище, как традиционно пишется в археологической литературе. Следы предполагаемого вала нами прослежены у правого берега Урматки и на пашне [Бурханов: 2001; 2002 в; 2014].

Археологические работы на поселении проводились несколькими экспедициями. Так, в 1928 г. И.Н. Бороздиным здесь был заложен шурф. Затем крупномасштабные раскопки по изучению объектов поселения проводились Н.Ф. Калининым в 1951, 1956 и 1957 гг. и Р.Г. Фахрутдиновым в 1976, 1977, 1979 и 1983 гг. В 1995 г. раскопки были возобновлены А.А. Бурхановым [Бороздин: 1929, С. 191–200; Калинин, Халиков: 1954, С. 96–104; Фахрутдинов: 1984 а; 1984 б; Бурханов: 1999, С. 52–59; 2001; 2002; 2014].

В ходе раскопок в разные годы было вскрыто более 1500 кв. м площади, выявлены остатки производственных и жилищных комплексов, а также большое количество вещественного материала.

В частности, наши раскопки показали, что строения производственного назначения и жилища ремесленников были в виде полуземлянок, так как строители при их сооружении учитывали фактор рельефных возможностей прибрежной полосы поселения. В отдельных случаях при сооружении полуземлянок использовалась естественная площадка из мелких и средних камней, которые зафиксированы в нижнем горизонте раскопа 1995 г.. Перекрытия крыши и стены были деревянные, что подтверждается находкой остатков обуглившихся бревен и кусочков сохранившегося дерева. Стены сооружений обмазывались глиняным слоем. Полы чаще всего были земляными, но в отдельных местах отмечено покрытие их тонкими и гладкими речными камнями.

Жилища ремесленников чаще всего находились рядом или вместе с мастерскими. Так, в ходе раскопок Н. Ф. Калининым выявлены остат-

ки двух жилищ. Одно из них, судя по планировке и характеру находок, принадлежало бедному ремесленнику и представляло собой небольшую полуземлянку с полом из досок. Второй дом принадлежал более зажиточному горожанину, о чем ясно свидетельствует сама система планировки дома, состоявшей из большой бревенчатой постройки с подпольем и окруженной изгородью, а также найденные здесь ценные находки, среди которых две серебряные монеты хорезмийского и золотоордынского чекана [Калинин, Халиков: 1954; Фахрутдинов: 1984 а, С. 135].

В 1977 г. Р. Г. Фахрутдинов раскопал жилой комплекс. В него входили остатки двух сгоревших жилищ, дополнительной пристройки к основному жилищу и нижней части третьего сооружения. По характеру сохранившихся объектов последнее, вероятно, являлось домом ремесленника. В северо-восточном углу дома сохранилась нижняя часть печи с топкой, где обнаружена интересная находка в виде каменной матрицы для отливки какого-то украшения. На глиняном полу найдена монета 50-х гг. XIV в. Представляют интерес ямы возле жилища, служившие первоначально в качестве летних печей, о чем говорят ниши в ямах, заполненные большим количеством угля и золы, затем они использовались в качестве хозяйственных ям. При этом содержимое ям несколько раз обжигалось и засыпалось глиной, что свидетельствует о соблюдении необходимых санитарных норм [Фахрутдинов: 1984 а, С. 100].

Археологические исследования показывают, что иске-казанские ремесленники владели высоким уровнем мастерства по изготовлению и производству изделий из глины, железа и цветных металлов, стекла, камня, кости и т. д. Возможно значительная часть продукции местных мастеров шла на продажу.

Раскопанные остатки около десятка горнов по обжигу гончарной посуды и массовость высококачественных керамических изделий из выявленных объектов Урматского поселения говорят о местном характере и широком развитии этого вида ремесленного производства. Выявленные горны дают возможность судить об их конструкции и технике сооружения, о технических достоинствах обжига посуды и других изделий. Так, один из двух раскопанных Н. Ф. Калининым горнов, позволил определить его характер и форму [Фахрутдинов: 1984 а, С. 134–135]. Сооружение состояло из двух ярусов: топки и обжигательной камеры в форме свода, упирающейся на выступ стены. Ярусы были разделены между собой перегородкой из кирпича, являющейся одновременно сводом топки; через ее отдушины проникали в обжигательную камеру горячие газы. Ошлакованность боковых и верхних граней маленьких кирпичей, составляющих свод верхнего яруса, позволяет говорить о наличии отдушин и в своде, в

том числе и центральной отдушины, откуда одновременно происходила загрузка вновь изготовленной сырой продукции. Рассматриваемый горн, судя по своей форме и конструктивным данным, очень близок к большинству аналогов из древних и средневековых поселений, в том числе булгарских. Однако он имел и явное отличие, заключающееся в том, что печь находилась полностью в материке, что давала возможность сохранения высокой температуры, не позволяла остывать горну. В топке обычно сжигали уголь (а не дрова), что способствовало бездымному и высококачественному обжигу. Раскопки выявили рядом с обжигательными печами ямы, в которых хранились запасы древесного угля.

Позднее, в 1976 г., Р.Г. Фахрутдиновым были выявлены остатки еще 5 горнов, вделанных в крутой берег Урматки [Фахрутдинов: 1984 а, С. 147]. Один из них, больших размеров, предназначался для обжига поливной посуды. В ходе раскопок обнаружены потеки поливы и зафиксированы остатки обжигательной камеры с оригинальным воронкообразным основанием. Такая форма основания позволяла ослаблять силу поступающей из топки горячей массы газов.

В другом раскопе были выявлены остатки горнов для производства простой гончарной посуды. Сохранились топочные части горнов с хорошо выраженными печами, которые были сложены из небольших удлиненных кирпичей (9×10×6,5 и 10×12×7 см). Один из горнов имел топку с котлообразным дном с глиняной стенкой. Топка другого имеет цилиндрическую форму и вся ее стенка, сложенная из кирпича-квадрата (12,5×7, 13×13×7 см), сильно ошлакована в связи с длительным функционированием. Днища топки и печи покрыты мощным слоем копоти и золы. В топке найдены керамические остатки и производственный брак, а также несколько целых сосудов. Для подпорки печей с двух сторон горнов поставлены ручные жернова. Поблизости зафиксированы остатки двух жилищ с глинобитными печами, связанных с гончарным производством.

Наши раскопки в 1995 г., в одном из ремесленных участков в правобережной части поселения, выявили почти сохранившуюся камеру обжигательного горна и недалеко еще остатки двух печей, связанных также с производственным процессом. Камера котлообразной формы, с диаметром 160 см, сохранилась на высоту до 65 см. Ее основание глубоко врезалось в материковый слой. Глинобитная стенка сильно закопчена и ошлакована. Внутри печи и рядом много горелого слоя и золы. В левобережной части поселения зафиксированы остатки еще одной печи (диаметр – 1,80 м), которая разрушается в связи с постоянным омыванием берега речкой.

Самыми многочисленными и разнообразными изделиями, найденными в прибрежной части и выявленными в ходе раскопок производственных

и жилых комплексов Урматского поселения, является керамическая посуда. Она позволяет сделать заключение о степени обжига и технике гончарного производства, о разнообразии форм изделий, а также дает основание для исследования многих элементов материальной культуры населения[6].

Основная часть найденной посуды носит фрагментарный характер, целых сосудов – единицы. По технологии изготовления керамика делится на две группы: гончарную и лепную. При этом преобладает основной тип гончарной посуды (95%) – широко распространенная лощеная, богато орнаментированная керамика красно-коричневого, желто- красного, серого и серо-бурого, изредка желтого и стального цвета. Судя по форме, орнаментации и технологии оформления керамики имеются все аргументы для датировки ее в целом домонгольским временем (XII–серединой XIII вв.), хотя немало фрагментов и золотоордынского периода (середина XIII–середина XV вв.).

По форме, чаще всего, встречаются горшкообразные сосуды и кувшины, а также хумы, корчаги, кружки, кринки, тарелки, чашевидная посуда и миниатюрные сосудики. В частности, среди последних отметим чернильницу. Примитивность изготовления и нахождение ее в ремесленном квартале говорят о грамотности простых людей. Об этом говорят и другие находки, в частности, на плечиках и донцах некоторых сосудов встречаются надписи арабским шрифтом, сделанные мастером до обжига.

Интерес представляет группа сосудов с различной формой ручки. Среди них выделим кувшины с ручкой в виде кнопки-шишки, являющейся имитацией зооморфного изображения. Встречен также сосуд с зооморфной ручкой.

Сосуды украшены самыми разнообразными орнаментами. Это обычно прямые линии, крутая и плавная волна, оттиски гребенчатого штампа, разного типа ямки, насечки в виде ногтевых вдавлений, полумесяца, красивые каннелюры, заштрихованные линии. Часто встречаются сложные узоры в различном сочетании указанных элементов. Большинство стенок сосудов имеет вертикальное и перекрестное лощение. Все основные моменты этой богатой орнаментации имеют ближайшие аналогии в керамике домонгольских памятников основных земель Волжской Булгарии. Встречается поздняя глазурированная керамика тимуридского типа. Найден, к примеру, фрагмент чаши, покрытой зеленой растительной глазурью. Интерес представляет также фрагмент сосуда с белой и темно-синей глазурью. Аналогичные сосуды характерны для поселений Средней Азии и золотоордынских городов XIII–XV вв. [Байпаков: 1998, Федоров-Давыдов: 1994, С. 78–141].

---

6 К сожалению, керамика из объектов Иске-Казанского комплекса пока изучена на недостаточном уровне, однако благодаря некоторым публикациям Н. А. Кокориной, были получены первые установочные данные [Кокорина: 1993, С. 55–61].

Изучение находок из Урматского поселения приводит к безусловному выводу о том, что исследование основных археолого-этнографических групп общеболгарской керамики, ее технологии, форм и декора свидетельствует о прямой преемственности культурных традиций населения этого городского ремесленно-торгового центра Заказанья и формировании булгарско-татарской культуры золотоордынского периода на основе булгарской домонгольского времени.

(Продолжение следует)

Литература

1. Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. (АК ТАССР) – М., 1981.

2. Археологические памятники Татарской АССР (АП ТААСР). – Казань, 1987. 240 с.

3. Байпаков К.М. Средневековые города Казахстана на Великом Шелковом пути. – Алматы. 1998. 216 с.

4. Бороздин И. Из области татарской культуры (научно-исследовательские экспедиции в Татреспублике летом 1928 г.). // Новый Восток. – М., 1929. Кн. 25. С. 191–200.

5. Бурханов А.А. Отчет об итогах археологических исследований в охранной зоне ИКГМЗ в 1995 г. (Рукопись). – Архивы ИА АН РТ и ИКГМЗ. Казань.1995. С. 23–24.

6. Бурханов А.А. Новые исследования в Заказанье. // XIII Уральское археологическое совещание. Тезисы докладов. 4.2. – Уфа, 1996. С. 70.

7. Бурханов А.А. Отчет об итогах археологических исследований в Заказанье в 1996 г.. Часть 1. Археологические исследования в Камаевском городище. Казань, 1997. С. 27–28. (Приложения к отчету: Газимзянов И.Р. Отчет об антропологической экспертизе костных останков с Камаевского городища. 4 с.). Архив ИКГМЗ и ИА АН РТ.

8. Бурханов А.А. Древняя история. // Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. М., 1999 а. С. 9–82.

9. Бурханов А.А. Некоторые итоги изучения памятников эпохи Казанского ханства. // Ученые записки ТГГИ, № 7. – Казань, 1999 б. С. 121–132.

10. Бурханов А.А. Некоторые итоги изучения памятников охранной зоны Иске-Казанского историко-культурного и природного комплекса в Заказанском регионе. // Восток-Запад: диалог культур Евразии. Выпуск 2. Проблемы истории и археологии. – Казань, 2001. С. 354–381.

11. Бурханов А.А. Памятники Иске-Казанского комплекса. – Казань, 2002. 30 с.

12. Бурханов А. А. Древности Иске-Казанского комплекса и Высокогорского Заказанья. Серия «Материалы и исследования по археологии и истории Золотой Орды и постордынских государств Евразии. Выпуск 10. – Казань. 2014. 136 с.

13. Бурханов А. А., Губайдуллин А. М. Археологические работы в охранной зоне ИКГМЗ в 1995 г. (предварительное сообщение). // Заказанье: проблемы истории и культуры. – Казань, 1995. С. 16–17.

14. Бурханов А. А., Касимов Х. М. Памятники Иске-Казанского государственного музея-заповедника (проблемы изучения, сохранения и использования). // Заказанье: проблемы истории и культуры. – Казань, 1995. С. 44–49.

15. Заказанье: проблемы истории и культуры. Под редакцией А. А. Бурханова. – Казань: Заман, 1995. 203 с.

16. Калинин Н. Ф., Халиков А. Х. Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. // Труды КФАН СССР. Серия исторических наук. – Казань, 1954. С. 96–104.

17. Кокорина Н. А. Керамика Биляра и Иске Казани.//Культура, искусство татарского народа. – Казань, 1993. С. 55–61.

18. Отчет «Ландшафтно-экологическое обоснование Иске-Казанского государственного историко-культурного и природного музея-заповедника» (Рукопись). – Казань. 1993. Архив ИКГМЗ.

19. Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. Коллективная монография. – Казань, 1999. 368 с.

20. Фахрутдинов Р. Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. – Казань, 1975. 219 с.

21. Фахрутдинов Р. Г. Скифские зеркала бассейна Казанки // Советская археология. № 1. М., 1983. С. 291–293.

22. Фахрутдинов Р. Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. – М., 1984 а.

23. Фахрутдинов Р. Г. Исследования Старой Казани (итоги раскопок 70-х гг.). // Советская археология. № 4. 1984 б.

24. Фахрутдинов Р. Г. Мелодия камней. – Казань, 1986.

25. Фахрутдинов Р. Г. Волжская Булгария. IX–XV вв. Автореферат на соискание ученой степени доктора исторических наук. М., 1990.

26. Федоров-Давыдов Г. А. Золотоордынские города Поволжья. – М. 1994. 232 с.

ҮТКӘННӘРГӘ СӘЯХӘТ

Нурулла Гариф

Аннотация: *Нами исследованы история возникновения названий деревень в окрестностьях городища Древние Чаллы. Интересными представляются исследования этапов истории развития деревень. Для комплексного изучения истории названий деревень необходимо привлечение и других категорий источников – письменных, фольклорных, этнографических, топонимических. Время возникновения и изменения названий деревень представляется актуальным и перспективным.*

Ключевые слова: *Древние Чаллы, староста, пустошь, деревня, починок.*

Борынгы Чаллы төбәгендә (*Әлеге җирлек бүгенге көндә Балык бистәсе районының көнчыгыш һәм Мамадыш районының көнбатыш җирләре белән аерымлана. Элекке Кызыл Йолдыз районы (1935–59) биләмәсе белән туры килә*) барлыкка килгән авыллар зур һәм борынгы тарихка ия. Борынгы Чаллы шәһәре (1183–1556) үзе дә шушы җирлектәге урнашкан авылларга нигезләнеп барлыкка килгән һәм үсеш кичергән. Шул чорлардан бирле яшәп яткан, яисә вакыт узышында «элекке авыл урыны» буларак халык теленә кереп калган авылларның исәбе бу төбәктә 50 дән артык. Әлеге авыллар җирлегендә «борынгы, иске, изге, кирәмәт, мазарка» атамасында сакланган зират урыннары да билгеле. Алар, сирәк кенә булса да, шул чорларда куелган язма кабер ташлары белән дә билгеләнә. Борынгы Чаллы шәһәре беренче тапкыр чыганакларда 1183 ел [ПСРЛ. Т.IX: 1965. С.10; ПСРЛ. Т.XV: 1965. С.269], соңгы тапкыр 1556 ел белән билгеләнә [ПСРЛ. Т.IX: 1965. С.269; ПСРЛ. Т.XIII: 1965. С.269–270]. Шәһәр тирәсендә урнашкан авылларның тарихына бәйле иң тәүге язма чыганак 1619 елгы җир бүленеше вакыйгасына бәйле искә алына [РГАДА, Ф.1209]. Чыганакта, Чаллы төбәге авылларының борынгы чорлардан килгән атамалары һәм аларда авыл башлыклары ролен үтәгән кешеләрнең («людей-старожильцов») исемнәре санап үтелгән (*фотода аларның исемнәре һәм тамгалары күрсәтелә*). Әлеге чыганак борынгы чорларда барлыкка килгән авылларның атамаларын һәм аларның төбәк яулап алынганнан соң нинди үзгәрешләр кичерүен аңлатучы бердәнбер документ. Беренчел авыл атамаларыннан аермалы буларак, соңрак чордагы документлардагы авыл атамалары, 1619 елгы чыганактагы исемлектә искә алынган ке-

шеләрнең бер өлеше, «староста»лар яисә «выборный» дип аталып, шулар исемендә бирелә.

Мәсәлән, 1619 елгы чыганакта, ташландык (пустошь) буларак билгеләнгән Балхуҗа авылында яшәүчеләрнең җитәкчеләре ***Көчек Мәмәшев*** (*«Кучук Мамышев»*) искә алына.

1678 елгы чыганакта әлеге җирлектә өч авыл: Балхуҗа, Пимәр елгасы кушылдагындагы Мәмеш (Мәмәш авылның атамасы Көчекнең этисе Мәмәш исеменә бәйле. Мәмәш, авылның сайлап куелган кешесе. Мәмәш авылының нигезе Пимәр елгасының уң ягында, хәзерге фермалардан астарак, су башнясы – чишмә янында урнашкан) һәм Балхуҗа-Пимәр авыллары күрсәтелгән [РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. 1678]:

1. *«Деревня Мамышское Бимерское устье тож (Пимәр елгасының түбән өлешендә. Авыл һәм зират урыны билгеле), в ней 16 дворов, людей 16...»*;

2. *Починок Болгозя Бимер (Пимәр авылы, зираты җирле халык телендә «Йортлар өсте» атамасында билгеле), а в ней татары, а в нем 14 двора, 15 человек...».*

3. *«Починок на пустоши Багалзинскою (Балхуҗа – Көчек Чаллысы – Биектау) в ней 34 двора, людей 34...».*

Балхуҗа авылының исеме Көчек Чаллысына әйләнүе дә 1619 елгы документта искә алынган Кучук Мамышевка бәйле. Әле 100 елдан соң да [РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. 1719] Көчек авылының старостасы буларак, Көчек Мәмешевнең (Мөхәммәднең) оныгы Ишманейко (Ишмөхәммәд) Кусюков торганлыгы билгеле. Балхуҗа – Көчек Чаллысы авыллары турында мәгълумат 1715, 1716 [РГА-

ДА. Ф. 350. Оп. 1. 1716] елларга караган чыганакларда да урын алган. 1742 елдан соңгы документларда Балгузино атамасы искә алынмый.

Көчек Чаллысы авылын, атамасы яңгырашына бәйле рәвештә, совет чорында Биектауга үзгәртәләр. Әлеге зур авылның урам атамаларында элекке чордагы авыл атамалары хәзерге чорда да чагылыш таба. Авылның хәзерге «Чутай очы» дигән урыны 1619 елгы документта «Новые Чаллы Нижние, Чютея Косарова» дип искә алына. Авылның зираты да билгеле.

Тирә-якта урнашкан дистәләрчә башка авылларның атамасы үзгәреше дә Балхуҗа-Көчек Чаллысы авылы тарихына охшаш. Без аларны санап кына узабыз.

1. 1619 елгы чыганакта Югары Чаллы авылыннан сайлап куелган авыл башлыгы, Бокаш Шихназимов искә алына. Бүгенге көндә бу авылның исеме Котлы Бөкәш. Авыл ике исемнән тора. Хәзерге авыл белән янәшә Котлыг авылының борынгы нигезе урнашкан.

2. Би-Йорт авылы башлыгы Чураш Шихназимов. Авылның хәзерге атамасын татарлар Чураш дип атап йөртә. Соңрак чоргы урысча язылган чыганакларда атамасы «Бикчураево», «Чурашево» буларак языла.

3. Элекке Түбән Чаллы авылының Тәберде Чаллысы авылы булып китүе дә, 1619 елгы документта, авыл җитәкчесе буларак искә алынган Тереберде Уразлыевка бәйле.

4. Би Йорт-Иске Йорт, кайбер документларда Шихаздә Сатлыганы буларак аталып йөргән бүгенге Сатлыган авылы да XVII гасыр башында яшәгән авыл башы Сатлыган Байгильдеевка бәйле тарихка кереп калган. Төбәктәге Кадряк (Кадрәк мирза), Бирдебәк, Мәшләк[7] [РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Л. 178] кебек авылларның атамасында да кеше исемнәре ята.

Авыллар атамасының үзгрешен соңрак чорга караган документлар буенча да билгеләргә була. Мәсәлән, элекке чорда Чаллы (Исен) авылында тирә-як авылларының йөзбашы Үрәй улы Мансур яшәгән [РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 1208]. Без бу авылны бүгенге көндә крәшен татарлары яшәгән Үри Чаллысы авылы буларак беләбез. Бер риваятьтә бу авыл атамасының килеп чыгышы үр менгәндәге авыл дигәнне аңлата, икенчесендә, имеш, монда Үринә дигән бай хатын яшәгән дип сөйләнә иде. 1678 елга чаклы, Керәшен Казаклары (*XVII гасырдан соң күчерелгән, чукындырылган татар морзалары*) авылыннан башка Чаллы төбәгендә бер генә керәшен авылы да булмаган.

Авыллар атамасындагы үзгәрешләр һәм аларның килеп чыгуына бәйле үзгәрешләр төбәктәге башка авылларга да хас. Тагын бер мисал.

7 Чыганакта: Зур Мәшләк авылында Чаллы төбәге авыллары белән идарә итүче йөзбашы Әлмәш (Әл-Мөхәммәд) торганлыгы хәбәр ителә.

Балык бистәсе районына кергән Балтач авылы документларда күп очракта Юлсубино, халык телендә Балтач атамасында йөртелә. Аның килеп чыгышын да төрлечә сөйлиләр. Имеш, авылга нигез салучылар, аның суын эчеп карагач: «суы тач бал икән» диләр дә, шуннан Балтач исеме алынган. Авылга бәйле 1642–46 елларга караган документның берсендә: «...деревни Елсуби//ны Тлякейко Балтачов», икенчесендә исә: «...деревни Балтачевы // Тлекея Балтачева», дип аңлатып узыла [РГАДА. Ф. 1209. Оп. 2.]. Әмма, авыл атамасының килеп чыгышын ялгыш аңлату бүгенгәчә дәвам итә.

Борынгы Чаллы төбәгендәге бериш авылларның барлыкка килүе аларның кайда, кайчан, нинди җирдә һәм кемнәр урнашуларына бәйле рәвештә дә кушылган. Мәсәлән, Алан-Полян, Ташлык, Зәңгәркүл (Кыерлы, Алан), Чыршылы елга, Яңа авыл, Яңа Сала, Чаллыбашы, Шомыртбашы, Мукшы Чаллысы, Казаклар, Түләк авыллары турында атамалары ачыклык кертә.

Соңрак чорда төбәктә урнашкан урыс авылларның атамаларында да шул бер үк дәвамчылык. Төбәктәге (бүгенге көндә инде өлешчә юкка чыккан авыллар) Степановка, Николаевка, Тукбулат-Иванай кебек авыл атамалары үзләренең беренче нигез салучыларына бәйле кушылган.

Әдәбият

1. ПСРЛ. Т. XV. Летописный сборник, именуемый Тверской летописью. – М.: Наука, 1965. – VIII. – 186 с.; – VII, – 504 с.

2. ПСРЛ. Т. IX. Летописный сборник, именуемый Патриаршею или Никоновскою летописью. – М.: Наука, 1965. – 269 с.

3. ПСРЛ. Т. XIII. Патриаршая или Никоновская летопись. Так называемая Царственная книга по списку Московской синодальной библиотеки № 149. – М.: Наука, 1965. – V. – 532 с.

4. РГАДА. Ф. 1209. Оп. 1, Ч. 1. Кн. 153. Лл. 390–396. 1619 г. Подлинная дозорная книга пустоши, что было Чаллынское городище (по Зюрейской дороге), письма и дозора Григория Кузьминского. Документ белән Гасырлар авазы – Эхо веков журналының 2011 елгы, 3–4 саннарында танышырга була.

5. РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 1102. Лл. 643–644 об. 1678 г. Чыганакта авылларның атамалары, алардагы йортлар, әлеге йортларда яшәүче кешеләр, аларның абыйлары, үз һәм ул-кызлыкка алган үги балалары, туганнары, оныкларының саны китерелә. Әлеге авылның күпме ясак түләргә тиешлеге күрсәтелә.

6. РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 1084. 1719 г. д. Балгузино (Кусюкова Челны тож) ясашные татары, С. 318–319. (Ревизские сказки).

7. РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Д. 153. 1716 г. 962 с. (Ландратские книги).

8. РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Д. 153.

9. РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 1208. Л. 1а.

10. РГАДА. Ф. 1209. Оп. 2. Кн. 6481. Отказные, отдельные, обыскные, межевые и мерные книги поместных, вотчинных и пустых земель Казанского уезда. 1642–1646 гг. Документ тарих фәннәре кандидаты Рәфыйк Насыров тарафыннан табылып, эшкәртелде. Фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелә.

МОНЕТЫ XV В. ИЗ ОКРЕСТНОСТЕЙ СЕЛА КАРТАШИХА ЛАИШЕВСКОГО РАЙОНА ТАТАРСТАНА

А. И. Бугарчёв, О. В. Степанов

Аннотация: *В своей статье авторы публикуют новый нумизматический материал из села Карташиха – монеты XV в. чеканки южных монетных дворов. Всего насчитывается 6 экземпляров. Авторы приводят топографию находок подобных монет в Татарстане и делают вывод о функционировании в регионе двух серебряных монетных номиналов.*

Ключевые слова: *Булгарский вилайет, с. Карташиха, XV в., денежное обращение, дирхам, монетный двор.*

Одной из особенностей денежного обращения в Булгарском вилайете в XV в. было присутствие джучидских серебряных монет, чеканенных на монетных дворах Нижней Волги и южного региона Золотой Орды. Данные монеты встречаются как в составе кладов, так и в подъёмном материале на территории археологических памятников Татарстана.

Почему факт совместного обращения местных и привозных дирхамов XV в. является особенностью регионального денежного обращения? Здесь необходимо сказать о весовом соотношении между данными блоками монет. При правлении хана Шадибека (802–810/1399–1407 гг.) булгарские монеты чеканились с указным весом 0,78 г [Фёдоров-Давыдов: 2003; по материалам изучения Измерского клада было получено значение 0,76±0,02 г; Бугарчёв, Купцов: 2017, С. 124]. Монеты южных дворов выпускали продукцию по другому стандарту – 1,10–1,15 г [Фёдоров-Давыдов: 2003]. Два дирхама южной чеканки приравнивались к трём дирхамам булгарской чеканки. По мере снижения веса монет одного блока пропорционально снижался вес монет другого блока [Фёдоров-Давыдов: 2003]. Такая ситуация прослеживается на протяжении 1400–1430-х гг.

Монеты нижневолжской и южной чеканки выявлены в таких кладах с территории Татарстана, как Рыбнослободский, состоявший из более чем 6000 монет. В кладе находилось около 2000 экземпляров, выпущенных в XIV–XV вв. на монетных дворах городов Хаджи-Тархан, Сарай, Сарай ал-Джадид, Хорезм, Азак, Сарайчук, Крым, Каффа ал-Джадид, а также в Орде и Орде Муазам, Иль-Уй Муазам [Тростьянский: 2005]. Ещё в одном крупном кладе из села Караульная Гора, обнаружена продукция Хаджи-Тархана, Иль-Уй Муазам, Сарая и Сарая ал-Джадид [Мухамадиев: 1983], хотя основная часть – это дирхамы монетного двора Булгар и с

«трёхногой» тамгой. Казанский клад 1893 г. в основном состоял из монет южной чеканки – из 595 монет к булгарской эмиссии относилось всего 6 экземпляров [Фёдоров-Давыдов: 1960, № 195].

Находки единичных экземпляров нижневолжских, южных и крымских монетных дворов опубликованы в статьях о нумизматическом материале с Торецкого поселения [Мухаметшин: 2011], с Иске-Казанского археологического комплекса [Бугарчёв, Степанов: 2016], из окрестностей с. Войкино [Бугарчёв, Емельянов: 2018]. Рядом с Войкино расположено село Кожаевка, где также были обнаружены подобные монеты [Бугарчёв, Степанов: 2011]. Из Лаишевского района известен комплекс у села Рождествено, где среди прочих были выявлены монеты Хаджи-Тархана, Сарая и Сарая ал-Джадид [Гончаров, Тростьянский: 2004].

В данной статье публикуются новые находки южных монет XV в. По собранной авторами информации, несколько экземпляров монет, чеканенных вне Булгарского вилайата, были обнаружены в окрестностях села Карташиха Лаишевского района. Перечень с указанием метрологии приводится в таблице.

Опись джучидских монет из села Карташиха

№	Эмитент	МД	Время чеканки, г.х.	Вес	Примечание
1	Мустафа б. Гийас ад-Дин	Хаджи-Тархан	(840-е)	0,73	
2	Махмуд б. Мухаммад б. Тимур	Орду-Базари	(864-870)	0,67	
3	Махмуд б. Мухаммад б. Тимур	...Мансур..	(864-870)	0,62	
4	Махмуд б. Мухаммад б. Тимур	Хаджи-Тархан	(864-870)	0,64	
5	(Генуэзско-татарская)	(Крым)	(825-838)	Не сохранился	
6	Не прочитан	Не сохранился	(Середина XV в.)	0,59	Сторона А – трёхногая тамга, сторона Б – двуногая тамга

Карташихинский комплекс сравнительно небольшой – 6 монет, однако он расширяет топографию находок монет южной и нижневолжской чеканки в Булгарском вилайате. К археологическим памятникам Торецкое поселение, Иске-Казань, с. Войкино, с. Кожаевка, с. Рождествено теперь добавляется с. Карташиха. Из археологической литературы известно Богишевское селище, находящееся к юго-юго-востоку от села [Свод: 2007, № 1856]. Однако сейчас невозможно утверждать, что монеты происходят с указанного селища, поэтому местом находок монет авторы указывают в целом село Карташиха.



ФОТОТАБЛИЦА

Монеты XV в. из с. Карташиха Номера монет в фототаблице соответствуют номерам в тексте

О таком явлении, как участие серебряных монет не-булгарской чеканки в денежном обращении Среднего Поволжья, писал известный археолог и нумизмат Г. А. Фёдоров-Давыдов: «Продукция денежного двора в Хаджи-Тархане уходила в те районы, где денежное обращение было сохранено... Так, большое количество ... монет южной весовой нормы обнаружено в кладах второй половины XV в. на территории Казанского ханства» [Фёдоров-Давыдов: 2003]. В то же время булгарские монеты XV в. не выходят за территорию Булгарского вилайета – самой южной точкой обнаружения булгарских дирхамов является поселение у села Шиловка Ульяновской обл., где были обнаружены и клад (из 75 экземпляров) и

единичные находки (не менее 23 экземпляров) монетных дворов Булгар и Булгар ал-Джадид.

Таким образом, можно сказать, что в первой половине XV в. в денежном обращении Булгарского вилайета участвовали серебряные монеты как минимум двух номиналов, соотносившихся друг с другом как 2 к 3.

Литература

1. Бугарчёв А.И., Степанов О.В. Джучидские монеты ханов XV в. из находок на территории Иске-Казанского археологического комплекса (Татарстан)//Нумизматика Золотой Орды, №6./Гл. редактор И.М. Миргалеев. – Казань, 2016. С. 98–102.

2. Бугарчев А.И., Емельянов В.П. Золотоордынские монеты XV в. южных монетных дворов из находок на Войкинском городище//Родной край, №1. 2018/Гл. ред. Д.М. Исхаков. – Казань. С. 77–79.

3. Бугарчёв А.И., Купцов А.Е. Клад монет начала XV в. из окрестностей г. Тетюши (Татарстан)//Нумизматические чтения ГИМ 2017 г.. Мат-лы докладов и сообщений. Москва, 23 и 24 ноября 2017 г. – М.: РИА Внешторгиздат, 2017. С. 117–127.

4. Бугарчёв А.И., Степанов О.В. Комплекс монет из деревни Кожаевка (Татарстан)//Нумизматика Золотой Орды. Вып.1. – Казань. 2011. С. 85–88.

5. Гончаров Е.Ю., Тростьянский О.В. Монетный комплекс XV в. из села Рождествено//Двенадцатая Всероссийская нумизматическая конференция. – М., 2004. С. 94–95.

6. Тростьянский О.В. Клад золотоордынских монет XV в. с территории Татарстана//Труды Международных нумизматических конференций/Под ред. П.Н. Петрова. – М.: «Нумизматическая литература», 2005. С. 157–158.

7. Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. – М.: Изд-во «Наука», 1983. 168 с.: XXI табл. ил.

8. Мухаметшин Д.Г. Монеты с Торецкого поселения. К вопросу о денежном обращении в Булгарском Улусе конца XIV–начала XV вв.//Нумизматика Золотой Орды. Вып. 1. – Казань: «Фолиант», 2011. С. 65–81.

9. Свод памятников археологии Республики Татарстан. Том 3./Отв. ред. А.Г. Ситдиков, Ф.Ш. Хузин. – Казань, 2007. 528 с.

10. Фёдоров-Давыдов Г.А. Клады джучидских монет//Нумизматика и эпиграфика. Т. I. 1960. С. 94–192: 5 карт.

11. Фёдоров-Давыдов Г.А. Денежное дело Золотой Орды. – М.: «Палеограф», 2003. 352 с. и 40 с. ил.

НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ ТАТАР АВЫЛЛАРЫ

О. Р. Хисамов, И. Г. Закирова

Новосибирск өлкәсендә яшәүче татарларның рухи мирасын өйрәнү дәвам итә. 1917 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан биредә яшәгән татарларның рухи һәм мәдәни дөньясын өйрәнү максаты белән оештырган комплекслы фәнни экспедиция Новосибирск өлкәсенең Колыван һәм Каргат районнарында эшләде. Бу мәкаләдә сүз шушы ерак җирлектә яшәүче милләттәшләребез, биредәге татар авыллары, халыкның тарихы, көнкүреше, халык иҗаты турында. Новосибирск өлкәсенең бу авыллары турында тулырак мәгълүмат бирү максаты белән Институтның Новосибирск өлкәсенә 1940 һәм 1967 елларда оештырылган фольклор экспедицияләре материалларын да мәкалә әзерләгәндә кулланабыз. Әлеге материаллар Институның архивында саклана һәм укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә.

КОЛЫВАН РАЙОНЫ

Колыван районындагы иң зур татар авылы – Умар авыл. Авылның икенче исеме Йорт-Оры. Бу территориядә төрки-татарлар VIII гасырдан ук яшәгән. Татарларның биредә күп гасырлар яшәгәнлеген авылдан берничә генә километр ераклыктагы борынгы кала урыны да раслап тора.

Умар авылы Обь елгасы янында урнашкан. Авылның исеме дә елга атамасыннан алынган, авыл халкы Обь елгасын хәзер дә татарча «Умар» дип атый. Авылда хәзерге вакытта 120 ләп хуҗалык бар, кайбер йортлар җәйге дачалар гына булып калган. Умар авыл, берара юкка чыгуга йөз тоткан булса да, хәзерге вакытта яңадан җанланып киткән, яңару юлына баскан. Бу күренеш авылда Навил Шәһәбетдинов инициативасы белән һәм аның җитәкчелегендә яңа мәчет төзелү белән дә бәйле. Мәчет төзелешенә бөтен авыл халкы мөмкин кадәр өлеш кертергә тырышкан. Кемдер төзелеш финансына үзеннән өлеш кертергә ашыкса, икенчеләре мәчет төзелешендә эшләгән. Бу эш авыл халкын уятып җибәреп, яңадан берләшергә ярдәм иткән. Алар авылны яшәртү, җанландыру турында киләчәккә матур планнар корып яшиләр. Мәсәлән, нәселле маллар үрчетү, казүрдәк, атлар тоту турындагы планнары әкренләп чынга аша да бара.

Бу авылның тагын бер күркәм эше – күптән түгел монда «Чат татары йорты» этнографик музей комплексы ачылды.

Хәзерге вакытта да Умар авылында татар халкының чат татарлары буларак билгеле этнографик төркеме яши. Алар төрле чорларда Идел буеннан күчеп киткән татарлар белән аралашкан. Авыл халкы татар теленең

әдәби вариантында да, үзара аралашканда чат сөйләшендә дә сөйләшә. Кызганычка каршы, хәзерге вакытта чат татарларының сөйләше әкренләп югала бара, ә яшьләр рус теленә күчә. Тел, һәм телгә бәйле рәвештә халыкның яшәү рәвеше, ата-бабалардан мирас булып күчкән әкиятләр, җырлар, хикәятләр онытыла.

Биредә ярты гасыр гына элек оста әкиятчеләр яшәгән. Умар авылында язып алынган әкиятләр «Татар халык иҗаты» күптомлыгында басылган. Мәсәлән, 1967 елда фольклорчы Хәлидә Гатина биредә әкиятче Кәрим Кусовтан «Патша малае», «Алтын башлы, көмеш беләкле» әкиятләренең вариантларын язып алган булган. Информантларыбыз 1960–70 еллардагы «юмакчы» Рәстәм, Миңнеәхмәт бабайларны искә алдылар. Балалар бөре җыйганда, кызыгып эшләсеннәр өчен, алар әкият сөйләп торалар иде дип сөйлиләр.

2017 елгы экспедиция вакытында күләмле әсәрләр табылмаса да, информантларыбыз Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы, Вәлиева Гөлбәзер Таштимер кызы, Нурисламова Галия Зәйдулла кызы һәм Җиһаншина Рәйхана Гарифулла кызыннан халык иҗаты әсәрләренең матур үрнәкләре теркәлде. Биредә мифологик хикәятләр, кыска җырлар, им-том текстлары, тыюлар, ышанулар язып алынды. Информантлар биргән мәгълүматлардан күренгәнчә, Умар авылында халык бик дус яши. Авылның күркәм традицияләренең берсе буларак һәр гаиләнең елга берничә тапкыр Коръән мәҗлесләре уздыруын күрсәтергә була. Рәйсә апа Сәфәргалиева сөйләве буенча, кайбер гаиләләр елга 7–8 тапкыр өйдә Коръән укыта. Бер үк кеше бары Рамазан аенда гына да өчәр тапкыр авыз ачтыра. Бу авыл халкының бердәм булуын, дус яшәвен күрсәтә ди Райсә апа.

Рәйсә ападан Коръән мәҗлесләрендә укыла торган мөнәҗәтләр, салаватлар, Коръән укыганнан соң укыла торган багышлау текстлары һәм башка дини эчтәлекле фольклор әсәрләре язып алдык.

Умар авылында ислам дине белән параллель рәвештә озак еллар курчак культы да яшәп килгән. Шәһәбетдинова Гөлҗиһан апа курчакларның «Капка өсте» дип аталган тирәклектә тотуларын сөйләде. Информантлар биргән мәгълүмат буенча, курчакларның өйдә торганы да, тирәклектә торганы да булганлыгы аңлашыла. Шуны да әйтергә мөмкин, чат татарлары Томск өлкәсендә дә яши, курчак культы эзләре Омск һәм Томск өлкәләрендә узган экспедиция вакытларында да язып алынды. Мәсәлән, Омск өлкәсендә курчакларны язгы ташу вакытында бозларга куеп җибәрү йоласы булган. Иртешкә агызганда бу курчаклар авыру-хасталарны алып киткәннәр дип ышанганнар. Курчакларга яки коңгырчакларга табыну турында язып алынган материаллардан күренгәнчә, Томск өлкәсенең чат татарлары яшәгән авылларда «курчак уйнату» 1950–60 елларына кадәр

дәвам иткән. Курчакларны чүпрәктән ясаганнар, бәйрәмнәрдә сыйлаганнар. Алар белән сөйләшкәннәр, ярдәм сораганнар.

Курчаклар

Курчаклар ясап тирәкләр янына утыртканнар.Әни сөйли торган иде. Бәйрәм булса, әнә тегендә, Капка өсте дип әйтәләр иде ул җирне, анда тирәкләр булган бик күп. Һәркемнең тирәге булган. Ул тирәктә курчагы булган һәркемнең. Курчакларны күлмәк кидереп алып барып утырта торган булганнар. Бәйрәмнәрдә ашаган әйберне аларга да алып барып утырта торган булганнар. Хәзер андый әйбер юк инде. (Умар, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы, 1928 елгы).

Менә боларның нәселе (фотодан күрсәтеп сөйли) уйнаганнар чердак башында курчаклар белән. Курчаклылар дип әйткәннәр аларны. Менә мин ишеткән идем карт кешеләрдән. Балалар ничек инде уйныйлар курчаклар белән, болар да шулай ашатып,эчертеп, киендереп матур гына итеп утыртып куялар икән (Умар авыл, Нурисламова Галия Зәйдулла кызы, 1941 елгы).

Умар авылында язып алган материаллар арасында төрле йолаларга караган материаллар да шактый. Мәсәлән, язын «Боз озату» йоласын авылда бәйрәм кебек көтеп торганнар. Боз карарга бөтен авыл халкы чыккан. Матур киемнәрен киеп, бәйрәмгә барган кебек барганнар су буена.

Елгаларда боз китү ел фасылларының алышынуын, кышның тәмамлануын белдерә. Боз китү, табигать уяну вакыты, табигатьтәге хаос кеше тормышына да йогынты ясый ала, аның аеруча сизгер һәм көчле вакыты санала. Умар авылында бу йола ислам дине белән керешеп киткән. Боз киткәннән соң һәр гаилә Коръән укыта.

Боз озату

Боз киткәндә балчык алып, баш аша әйләндереп, бозга ташлыйлар. Авырган авырулар булмасын дип ташлыйсың (Умар, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы).

Убтан (Обь) боз кузгалгач Коръән укыталар. Ике-өч көн боз китә иде авылда. Хәзер кайчан киткәнен дә белгән юк. Йома көн китә иде. Ровно бер атнадан,икенче йомганы, әзерләнеп Коръән укыталар иде (Умар авыл, Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы).

«Ташу»

Баштан әйләндереп атасың песок – авыруларны, кайгыларны алып кит, миңа кайгы калдырма, дип ташлыйсың (Умар авыл, Вәлиева Гөлбәзәр Таштимер кызы. 1941 елгы).

Умар авылы апалары шактый гына кыска җырлар да җырлап күрсәттеләр.

Йырйырлавын харам диләр
Мөхәммәт өммәтенә.
Харам булса да йырлыймын
Дусларым хөрмәтенә.

Умар белән Акбалыкның
Алтмыш чакрым арасы.
Ике алтмыш – йөз егерме,
Ниче китеп барасы.

Умар юллары пиала
Ташбулса таймас иде
Минем йөрәккәйем яна
Сез булса янмас иде.

Умар авылында төрле риваятьләргә дә юлыктык. Тарихи вакыйгаларны, гаилә тарихларын бәян иткән риваятьләрне, сөйләкләрне, истәлекләрне һәр гаилә кадерләп саклый, буыннан буынга тапшыра. Шундый риваятьләрнең берсендә бу якларга Бөгелмә ягыннан килгән бертуган егетләр турында сүз бара.

Мәүлетовлар нәселе турында

Бөгелмә яктан, ачлыктан качып, өч егет килгән. Ул якта, Казан якларында, ашарга-эчәргә булмаган бер нәрсә дә, болар килгәннәр Акбалыкка.

Өч егет, өч брат. Биик матур булганнар. Аннары өйләнгәннәр. Аларның гел генә ир балалары туып торган. Шулай нәселләре бик таралган. Ул ир балаларның токымнары менә хәзер таралды. Бер братның бер улы минем әти, ул 1904 елгы иде. Менә минем әтиемнең генә малае тумады. Гел кызлар гына туа. Әтиемнең әтисе Зәйнулла булган. Фамилияләре Мәүлүтов булган. Бик эшчән булганнар бу егетләр, эшләгәннәр бик. Атта бик яхшы чапканнар (Умар авыл, Нурисламова Галия Зәйдулла кызы, 1941 елгы).

Умар авылында язып алынган төрле ышанулар да кеше белән әйләнә-тирә мөхитнең бәйләнешен күрсәтә. Элек заманнарда табигатькә булган сак караш агачлар белән бәйле тыюларда чагыла. Борынгылар һәр җан иясен, шул рәттән, агач-үсемлекләрне дә аяганнар, аларның яшәү теләген хөрмәт иткәннәр. Вакытлы-вакытсыз агач кисү зур гөнаһ саналган. Кеше бу гамәле белән үзенә агачның рәнҗешен алудан курыккан.

Тик торганнан ярамый гөрләп, яшәреп утырган агачларны кисәргә. Утырткан агачы үскән кешенең күңеле яхшы икән дип әйтәләр.(Умар авыл,Нурисламова Галия Зәйдулла кызы).

Элек бабайлар белгән нинди агачны нинди көндә кисәргә яраганын. Агач вакытсыз киселсә, дөрес киселмәсә өй тыныч булмый. Музейдагы өй

дә шулай диләр. Сайра мама өе. Агачны дөрес алмаганнар.Кояш баеганнан соң агач эше эшләргә ярамый. (Умар авыл, Җиһаншина Рәйхана Гарифулла кызы. 1950 елгы. Акбалыкта туган. Соңрак Умарга күчкәннәр).

Акбалык һәм Казанка авыллары. Акбалык авылы – Колыван районындагы икенче зур татар авылы. Авылда 270 кеше яши, урта мәктәп һәм медицина ярдәме күрсәтү пункты бар. Акбалык авылы Өян елгасы буенда урнашкан. Авыл борынгы, аның янында урта гасырларга караган Паш-Тура кала урыны бар. Елга янында урнашкан булу сәбәпле авыл халкының төп шөгыльләренең берсе – балыкчылык. Шулай ук аучылык та озак вакытлар хуҗалык алып баруның бер чыганагы булган. Хәзерге вакытта да авыл халкы терлек тотып, җитешле тормыш белән яши. Һәр хуҗалыкның җиләк-җимеш, яшелчә үстерә торган бакчасы бар.

Биредә дә элегрәк чорларда чат татарлары яшәгән. Тора-бара Казан ягыннан Идел буе татарлары да килеп кушылган. Җирле халык белән Казан яктан килгән татарлар күпмедер вакыт үзара кушылып китә алмыйча яшәсәләр дә, бераздан аралашып китәләр. Хәзерге вакытта һәр гаиләнең ике яктан да килгән тарихы бар. Шул ук вакытта татар теленең чат сөйләше биредә юкка чыгып бара. Авыл халкы әдәби телдә сөйләшә.

Акбалык авылының тарихы турында 1967 елгы экспедиция вакытында Хәмит Ярми шактый мәгълүмат туплаган.

Акбалык авылының тарихына карата

12/VI – 1967

Акбалык авылы Обь елгасының бер ярында, дөресрәге Обьның сул як ярында, бу елгадан 4 км. ераклыкта утыра. Обь елгасына Оян/Өян елгасы кушыла. Акбалык авылына Обь елгасының Батурино пристаненнан Өян елгасы буйлап килеп була. Ул 5–6 чакрым ераклыкта. Без Батуринга төнге 3 сәгатьтә килеп төштек. Сургутка хәтле бара торган «Омск» пароходы иде.

Акбалык авылы Себернең шактый борынгы авылларының берсе. Шушы авыл кешесе Имаметдин Шәмгун угълы Бпһауетдиновның (1901 елда шушы Акбалык авылында туган) әйтүенә караганда бу авылга, аның оешып яши башлавына 1000 еллар булырга тиеш дип уйлана. Бу тирәләрдә Новосибирск галимнәре археологик тикшерү-казынулар (раскопки) үткәргәннәр. Алар бу тирәләрдә бик күп каберлекләрдә бик күп борынгы кешеләр сөякләрен тапканнар. Имаметдин абзый шул материаллар, археологлар сөйләвенә таянып бу авыл бик борынгы авыл ди. Бу авылдан 1 км. җирдә «Баш тора» дигән бер урын бар икән. Шул урында борынгы халыкларның башкаласы, баш шәһәре (Тора – шәһәр) булган. Шул баш кеше торганга ул җирне (яки авылны) Баштора дип атаганнар. (Мин ул урынны үзем барып караячакмын).

Обь елгасына коя торган Өян елгасы Обь елгасы белән янәшә агып килә. Бу Акбалык авылы шул елганың сул як ярына, бик матур бер урынга утырган. Хәзерге көндә бу авылда 124 хуҗалык бар. 1930 елда бу авылда колхоз оеша, ә 1952 елдан монда Новотроицк совхозының бүлекчәсе (3 нче ферма) ачыла.

Бу авылның исеме турында түбәндәге легенда бар:

Борын заманда бер кеше Өян елгасында балыкчылап йөргәндә бер аппак балык тотып ала. Бу хәл шушы авыл турысында була. Шуннан соң бу кеше шушы урынга чыгып авыл корып тора башлый. Шуннан соң бу авылга «Акбалык» исеме бирелә һәм ул шуннан соң Акбалык авылы дип аталып йөртелә.

Имаметдин абзый сөйләвенә караганда бу авыл элекке заманда җиргә бик тә бай булган. Бу авылның җире бер ягы 80 км., икенче ягы 20 км. булган. Бу хәтле зур территория, бу хәтле күп җир каян килеп чыккан? Бу хәтле зур территория, бу хәтле күп җир Акбалык авылы белән Умар/Умар, русча Оры авылы кулында була. Бу ике татар авылы бер волостьта торалар. Волость Умар авылында була. Бу ике авылга шул хәтле күп җир бирелү нидән килгән? Имаметдин абзый сөйләвенә караганда, Ермак Себерне яуларга килгәндә бу ике авыл кешеләре (татарлар) мондагы мәҗүсилектә яшәгән халыкларны патша (Ермак) тәртипләренә буйсындыруда аңа (рус гаскәрләренә) булышканнар. Бу авыл кешеләре рус дәүләте ягыннан торып, мондагы, элек инородецлар дигән халыкларга каршы Ермак ягыннан торып сугышканнар. Себер рус дәүләте кулына кергәч, бу халыкларга, ягъни Акбалык һәм Умар авылы татарларына, бик күп итеп җир биргәннәр. Ул җирне, күпме булуы һәм бу ике авыл татарларына ярдәмнәре турында грамота да язылган иде. Ул грамота зур һәм яхшы кәгазъгә алтын хәрефләр белән язылган иде. 1911 елларга хәтле безнең авыл татарларына бирелгән җир тулысынча халык кулында була. Патша түрәләренең моңа эче поша. Бу җирләрне бүлеп алмакчы булалар. Бу авылга патша түрәләре берсе артыннан берсе килә. Ләкин халык «җирне бирмибез! Ул безгә патша хәзрәтләре тарафыннан бирелгән, менә аның язуы» диләр. Каты тора халык. Түрәләр дә үзләренең басымнарын көчәйтәләр. Көннәрдән бер көнне бу авылга бер исправник (урядник) килеп төшә. Халыкны җыйнап «Сезнең җирегез бик күп, без аның бер өлешен казнага алабыз. Ә сезгә тиешенчә генә калдырабыз» ди. Халык каршы төшә. Гауга кыза. Җир мәсьәләсе бит! Алай да булмый, халык кызып китеп патша түрәсен дөмбәсләп ташлый. Исправник көчкә качып котыла.

Бер-ике айдан соң бу авылга бер рус кешесе килеп, авыл халкы белән бик җылы, бик якын күреп сөйләшә башлый. «Җирне бирми яхшы иткәнсез, исправникны куып җибәреп бик дөрес эшләгәнсез», - ди. Халыкның шул

җир эшләре артыннан йөргән кешеләре бу кешегә үзләренең серләрен сөйләп бирәләр. Теге бик кызыксынып тыңлап тора. Акбалык кешеләре арасыннан берсе «менә мин ул исправникка үзем башлап суктым. Аны кыйнауда фәлән катнашты, фәлән шулай итеп сукты» дип, барысын сөйләп бирә. Болардан сүз алгач, теге кеше өстендәге киемнәрен салып ыргыта. Ул киемнәр астыннан кораллы урәтник килеп чыга. Бу урәтник теге кешеләрнең сөйләве буенча список төзи. Исправникны кыйнауда катнашкан кешеләрне арестовать итеп алып китә. Шуннан соң аларга суд була. Шул вакытларны патша тарафыннан бирелгән җир турындагы алтын белән язылган документларны да тартып алалар. Менә шул вакыттан соң, Акбалык, Умар халыкларының җирләре тартып алына, аларга берникадәр җир калдыралар да, калганын русларга һәм башка переселенецларга бирәләр. Шуннан соң бу җирләргә берничә рус авылы килеп утыра. Акбалык һәм Умар авылларына патша тарафыннан күпме җир бирелүе һәм аның ни өчен бирелүе турындагы документ Облзем отделда, я архивта булырга мөмкин. Мин исә ул җирләрнең бу татарларның нинди батырлыклары, патшага (яки Ермакка) нинди көч бирүләре турында әйтә алмыйм.

Казанка авылына 1926 елда Казан ягыннан, Идел буеннан килгән татарлар нигез сала. Алар үзләренең авылларына, чыгышларын искә төшереп торсын өчен Казан исеме бирәләр. Хәзергә кадәр, гасырга якын вакыт үтүгә карамастан, Казанка халкы үзләренең кайсы яклардан килүләрен, чыгышларын хәтерли. Мәсәлән, Сабирова Фәризә апа халыкның бирегә Идел буендагы 1921 елгы ачлыктан качып килүләрен сөйләде. Аның кайнана-кайнаталары Саба районының Кибәхуҗа авылыннан күчеп килгәннәр. *«Беренче булып монда Минһаҗ бабай килгән. Хәзер аларның нәселенең фамилияләре Минһаҗетдинов. Белмим ничә кеше булганнарын, күпме килгәннәрен. Күп булганнар алар. Безнең әби килгән инде. Килгәндә бик азапланып килгәннәр. Ачлык булган. Әбинең ире үлгән, 4 кызы үлгән ачлыктан. Малае үлгән монда килгәндә. Бик авырлык күреп килгәннәр»* дип сөйли Фәризә апа Шәйхетдинова. Галия апа да әби-бабаларының Казан ягыннан килүләрен сөйләде: *«Казаннан килгән кешеләр монда бөтенесе дә. Кибәхуҗадан килгәннәр. 21 елда. Ачлыктан качып килгәннәр. Башта алты ел Барнаулда торганнар. Анда шундый әйбәт булган Барнаулда. Аннары монда килгәннәр».* Информантларыбыз сөйләгәннәр 1967 елгы экспедиция вакытында Хуҗиәхмәт Мәхмүтов Казанка авылында яшәүче Нургали бабай Мөхәммәтҗановтан авыл турында язып алган мәгълүматлар белән туры килә:

Яңа Казанка авылы

Новосибирск өлкәсенең Колыван районына керүче бу авыл чыннан да яңа әле. Ул 1926 елда гына салынган. Халык Татарстаннан күчеп килгән.

Кибәхуҗа авылы кешеләре бигрәк тә күп. Күчеп килүнең сәбәбе – 1921 елгы ачлык. Алар башта Барнаул янына күчеп киләләр. Анда бер биш ел торгач, бирегә күчәләр. Ул вакытта бу урында урманлык була. Башта землянкалар казып шунда торалар.

Хәзер авылны күрүчеләр биредә кайчандыр кечкенә землянкалар булгандыр дип башларына да китермәсләр иде. Авыл бик төзек. Йортлар барысы да зур, дүртәр бүлмәле, яңа. Авылда барлыгы 120 хуҗалык. Сигезьеллык мәктәп, клуб, медпункт бар.

Халык урманчылык белән шөгыльләнә. Биредә – Колыван лесхозының ширпотреб цехы урнашкан. Эшчеләр урман кисәләр, төзү материаллары хәзерлиләр, шулай ук яңа урманнар утырталар. Моннан тыш бочкалар, яәиклар, чаналар, тәрәзә рамнары ясау цехлары бар. Шулай ук сумала, скипидар, күмер, дегет, лак хәзерләнә.

Административ яктан Яңа Казанка авылы 7 чакырымда урнашкан Акбалык авыл советы карамагына керә.

Авыл халкының төп шөгыле урман белән бәйле булган. Авыл халкы белән аралашкан вакытта күбесе биредә агач эшкәртү цехында эшләп пенсиягә чыгуларын әйтәләр. Халык бердәм-дус яшәгән, бәйрәмнәрне матур итеп, күмәкләп уздырган. Ураза, корбан гаетләрендә азан әйткәннәр. Авылның мәчете булмаса да, һәр гаеттә берәр йортка җыелып намаз укыганнар. Информантлар элегрәк авылның бик матур булганын сөйләделәр. Хәзер, агач эшкәртү цехы ябылган, эш беткән. Шул сәбәпле яшьләр авылда калмый. Элегрәк исә яшьләр тавышыннан авыл гөрләп торган. Яшьләр кичләрен болынга чыгып «Круг» һәм «Наза» уеннары уйнаганнар.

1967 елгы экспедиция вакытында, авылның гөрләп торган вакыты була. Акбалык һәм Казанка авылларында әкиятләр, җырлар, уен һәм йола җырлары язып алына. Шул экспедиция вакытында язып алынган тагын бер җыр «Зиндан моңнары» дип атала. Бу әсәрне Акбалыкта яшәгән 1908 елгы Минневәлиева Өммегөлсем әбинең дәфтәреннән фольклорчы Халидә Гатина табып, аны зур галим, үзе дә Себер тумасы Хәмит Ярми күчереп алган. Хәмит Ярми җырны күчереп алганнан соң түбәндәге искәрмәне язып куйган: *«Эчтәлегенә караганда бу җыр Колчак вакытында чыгарылган булырга тиеш. Гражданнар сугышы чоры. Ул телдән-телгә күчкән, һәм язмага кереп китү аркасында шулай сакланып калган. Бу соңгы дәфтәргә 1950 елларда күчерелгән булырга тиеш (дәфтәре Новосибирскида чыккан)»*. Бу җырга аерым тукталуыбыз очраклы түгел. 2017 елгы экспедиция барышында без бу җырга яңадан юлыктык. Һәм шунысы кызык, ул тагын кульязмада, Казанка авылында яшәүче Солодовникова Хәкимә апада сакланган. Хәкимә апа озак еллар Ташкентта яшәп, ялга чыккач кына кире туган ягына әйләнеп кайткан. Ул гарәп язулы кита-

пларны, кульъязмаларны, нинди язмалар булуын белмәсә дә, һәрвакыт саклап тоткан. Шул китаплар арасында гарәп язуы белән язылган ике битле кульъязма килеп чыкты. Бу язма, Хәкимә апаның сүзенә караганда, аның әтисеннән калган. Әтисен Колчак гаскәре алып киткән, ул шул чорда төрмәләрдә булган кеше. Җырда да шул чор, аның Иркутск төрмәсендә утырган вакыты турында сүз бара диде информантыбыз. Күргәнебезчә, ике язма да бер үк чорга караган вакыйгаларга барып тоташа. Хәмит Ярми бу җырның яңа «Ай былбылым» яки «Вай былбылым» көенә башкарылуын да искәрткән. Акбалык авылында табылган текст белән Казанка авылында табылган ике текст та нигездә туры килә. 2017 елда табылган текст белән сезне дә таныштырабыз:

Зиндан моңнары

Ангараның буйларында
Иркут салган каласын.
Ризык дигән кайда кертми
Без тик адәм баласын.

куш.: Ай былбылым, вай былбылым
Ангараның агышы.
Ике битем тиң саргая
Бар да зиндан сагышы.

Ангараның суы тирән
Агып Байкалдан килгән.
Явыз Колчак шомлыклары
Безнең башларга җиткән.

Ангараны чыккан чакта
Күрәм суда ташларын.
Төрмә саен өстерәлде
Минем газиз башларым.

Иркутск төрмәсендә
Йозагы бүлмә бүлмәсендә.
Без күргәннәр гыйбрәт булсын
Башкаларга күрмәсенгә.(Казанка авылы)

Акбалык һәм Казанка авылларында язып алынган риваятьләрдә, истәлекләрдә авылның төрле еллардагы тормышы, халыкның уй-хыяллары, ышанулары, йола, гореф-гадәтләре чагыла.

Информантлар авыр сугыш елларын искә төшерделәр. Күңелле йола, бәйрәмнәрне барладылар. Мәсәлән, бу авылның үзенең күркәм йоласы

булган. Яз җитүне бөтен авыл белән Өян елгасында көймәләрдә йөреп бәйрәм иткәннәр.

Авыл тарихы

Әби сөйләгән иде. Монда килгәннәр дә, кертмәгәннәр, кире туган җирләренә кайтып киткәннәр. Анда кайткач көлгәннәр инде алардан. Тегендә-монда йөрисез дип. Яңадан килгәннәр. Монда тагын кертмәгәч, елларын белмим мин,монда ерак түгел, Воробьянино дигән авыл, анда барып торганнар. Аннары, кертә башлагач, монда яңадан килгәннәр.

Монда себерәкләр дигәннәр инде борынгылар, торган. Безнең авыл бик төпле-тамырлы авыл булган. Суы-урманы бар. Ачтан үлә торган түгел. Умар белән бер сөйләм монда. Монда килгәннәр беренче урам салганнар. Менә монда, аннары зират ягында тагын бер урам. Ике коренной урам булган. Бу коренной халык авылы булган. Анда аннары Мавлютовлар килгән. Без – килгән халык, килмешәкләр инде. Монда чат татарлары, чатские татары яши.

Авылда мәчет булган. Мәүлетдиннең яңа өе бар бит, шунда булган, урамга чыгып торган ул. Колхоз башланган заманнарга кадәр эшләгән. Беренче мәктәп мәчет бинасында була. Бала-чага күп булгач библиотекада да мәктәп булды. Без анда укый башладык. Тагын бер школа булды сазда. 192 бала булган ул вакытта.

Әбием Рәсәйдән килгән. Бик укыган булган. Мишәрчә ычкындырып куя иде. Мишәр булган әбием.

Халык бездә денен ташламады. Коръән укыталар. Өчен,җидесен укытты һәрвакыт. Коръән мәҗлесендә әбиләр аерым бер бүлмәдә, бабайлар аерым, башка бүлмәдә утыралар иде. Хәзер кеше аз булгач, барысы бергә инде. Мәетләр өчен дип,Ходай ризалыгы өчен,бәйрәм хакы дип сәдәка бирәләр.

Черномысь

Сез кая булган? Черномысьта булганмы, ди. Сез нәрсә күргән? Черномысь йөргән, Черномысь күргән, диләр. Черномысьта йөргән кеше күпне күргән була инде. Черномысьта да татарлар булган. Ул 30 чакрымда. Аларны курчакчылар диләр инде. Килгән халык аларга воле бирмәделәр.

Өян

Обь 2 чакырым авылдан напрямую. Безнең үзебезнең Өян бар. Исеме нәрсә аңлатканын белмибез. Шул биредә яшәгән халыктан калган исем. Өян Обьтан керә, аннары яңадан Обька кушыла. Су чиста иде. Бала-чага шунда коена иде, балык тота иде. Су инәсен күргән юк, сөйлиләр генә. Сөйлиләр иде, суга сикерә дә, суны ярып җибәрә диләр иде.

Без, Акбалык халкы, болай дип җырлыйбыз:

Акбалыкта ак балык,
Без үзебез вак булсак та,
Безне ярата халык.
Көймәләрдә йөрү

Язын карлар бетеп, суда бозлар киткәннән соң су буена чыкканнар. Озын көймәләрдә йөри иделәр, егетләр-кызлар. Бу май аенда була инде. Су арткан вакытта. Гармуннар белән чыкканнар. Егетләр күбесе гармун уйный торган иде. Кайсы тотмасын гармун, бер-ике җыр көен уйнап бирә инде. Шулай көймәләрдә йөри торган булганнар. Һәр көймәдә гармуннар уйнаганнар, җырлашканнар. Бу вакыт бик күңелле булып, гармун, җыр тавышыннан бөтен авыл гөр килеп торган. Җырларны Казаннан килгән пластинкалардан да өйрәнгәнннәр. «Каз канаты»н җырлый идек. Бу Казан яктан килгән җыр. Ата-бабалар китергән җыр инде.

Тәмәке өмәсе

Сугыш заманасында тәмәке өмәсе ясыйлар иде. Акча кирәк булгачтын инде, семьяга яшәргә, бала-чаганы үстерергә кирәк булгач, тәмәке үстерәләр иде бездә, самасат диләр иде үзләренчә. Авыл халкы тәмәке үстерәләр иде. Төпчекләр ясыйлар иде, түгәрчекләр (бүкән). Балта белән ясыйлар иде. Менә шундый төпчекләр, аның уртасы тишегрәк була. Шунда тәмәкене чабалар да, иләк белән илиләр. Специальный иләкләре була торган. Городка алып китәләр иде сатырга. Шуннан инде бала-чаганың өстенә дигәндәй, ризык алып кайталар иде. Сугыш заманасында халык шуның белән заниматься иткән.

Сугыш турында

Авылдан сугышка 40 тан артык кеше китте, төгәле 48 түгелме икән. Шуның 32 ләп кеше кире кайтмады. Шуларның 16 сы өйләнмәгән малайлар иде. Халык сугыш каты сугыш дип уйламады, куркыныч түгел дип уйлады. Аннан алда бит финнар белән сугышып алды. Беркемне дә алмадылар авылдан. Тиз генә җиңеп кайтырлар, бу да шулай булыр дигән идек. Вот шундый гына булыр дип уйладылар да инде. Менә әтием китеп бара, ә олы браты башын гына селкеп калды. Әтием кайтканнан соң сизде инде, нәрсә ни икәнен, икенче киткәндә уже монда кунып, аны озатып куйды.

Сугыш еллары турында

Җәй көне менә су арта торган, су төшкәннән соң юа дигән үлән бар иде. Калын. Шуны җыеп тозлыйлар да иде инде. Аннары каядыр витаминник дип, бочкалар белән алып та китәләр иде. Халык инде шуның

белән дә торган. Сөтле аш ашаганнар. Сыерлар инде бар иде бар кешедә. Һәрберсенеке булган. Сөт белән, бәрәңге белән инде. Бәрәңгенең дә җәйгә хәтле калмаганнары булган. Булган бер төрле киемнәрне чит авылга, рус авылында нигәдер практичныйрак булган халык татар авылына караганда, алып барып бәрәңгегә алыштырып кайта торган булганнар. Аннан инде 50–51 елларда адәм инде аякка баса башлаган иде. Сугыш вакытында авыр булды инде. Булганын хөкүмәткә бирә торган иде. Сауган сөтне сдавать итә идек. Тавык салган күкәйне тоже тапшыра идек. Сарыкка да сөт тапшырырга иде. Андый да бар иде, сарык сөте бирә торган идек, сыер сөтен. Сугыш заманасында бездә, авылда шулай иде. (Акбалык авылы, Зәйнуллин Әбүзәр Абдрахман улы, 1932 елгы. Бабалары Арча ягыннан килгән. Әнисе 1908 елда, бирегә килгәч туган).

Авыл турында

Безнең инәләребез килгәннәр, бабаларыбыз килгәннәр. Без монда туган инде. Әби Яңавылдан, Томск яктан, бабай барып алган. Шәрифә әбиләребез Казаннан килгән булганнар. Безне киштем диләр. Акбалыклар – киштем диләр. Болай Умарларны киштем диләр. Алар монда туган булганнар, элек борынгыдан монда алар. Умарларны кытайлардан калган дип әйтәләр, киштемнәр дип әйтәләр. Алар кара тәнле, күзләре кысык күзле, аерылып торалар. Безнекеләр әйтәләр иде. Безне килгәч бик обижать итәләр, безне «Килгән килмешәкләр» дип сүгәләр, артыбыздан теләсә нәрсә әйтеп калалар. Трубкага самосад тутырып, тәмәке тартып утыралар иде, дип сөйлиләр иде.

Мәүлетовлар нәселе

Бирегә ике кызы һәм биш малае, карчыгы белән Вәли бабай Татариядән килгән. Патша подъемный биргән. Башта кертмәгәннәр ул заманда килгәннәрне. Местныйлар землянкаларда яшәгәннәр, охотник-рыбаклар булган алар. Вәли бабай хәйләкәррәк булган. Или бер кеше өйрәткәнме икән. Бер чиләк аракы алып килгән, сыйлаган халыкны. Шуннан аны керткәннәр. Теге якта тау башында торганнар аннары алар. Шунда бүрәнәдән йорт салганнар алар. Шулардан Мәүлетовлар нәселе киткән. Алар – Хәйрулла, Гайфулла, Миргатулла, Мотыйгулла, Зәйнулла. Бер кызы Хәбби булган. Балалары 1870 елларда туганнар. Атам биредә 1905 елда туган.

Табигать турында

Элекке картлар кайчан нәрсә эшләргә кирәклеген белгәннәр. Алар бервакытта да икра чәчкән вакытта балык тотмый. Рыбнадзор кирәкмәгән иде. Кешеләр үзләре беләләр нәрсә яраганын, нәрсә ярамаганын.

Агачларны, алар йокыга киткәч, ноябрь аенда гына кискәннәр. Ике атна гына кискәннәр. Кедраны кисәргә ярамый. Хәзер круглый год кисәләр (Акбалык авылы, Мәүлетов Рафик Шәфикович, 1938 елгы.Механизатор һәм егерь. Әниләре 1921 ачлыктан качып Алтайга киләләр. Гайни әби белән Минһаҗетдин бабай Саба районы Кибәхуҗа авылыннан булганнар аннан бирегә күченәләр).

Агач цехы

Авыл кырыенда урман. Авыл халкының эше дә агач белән бәйле. Биредә Агач эше, цех бар иде. Мин 1963 тән агач эшендә. Без туктагач, пенсиягә чыккач, яптылар. Яшьләр эшләмәс булды ахырысы анда. Балта сабы ясадык. Шомаклап бирә идек, шоп-шома итеп. Алты тәңкә иде берсе. Агач кирә иде. Аны кисәбез. Аннары аны станокка үткәрәбез. Балта сабына яраклы, әйбәт җирен сайлап алабыз. Аннары икенче станокка барып балта сабы ясыйбыз.

Мин үзем генә түгел, күбәү идек без. Ике смена эшли идек. Эшләгән чаклар сагындырып тора иде.

Цехта дегет тә ясадык. 1966 елда. Ураманда каен карьясы апкайтып бирәләр иде. Аларны казанга тутыра идек. Аның юллары бар иде. Шуннан ага иде. Су белән бергә. Шуннан өстән дегетен генә җыялар инде. Шуннан хозяин бутылкалар китерә иде. Бутылканы үзебез юып, үзебез хәзерли идек. Акчаны дегет кайнаткан өчен генә түләделәр.

Авыл тарихы

Халык монда Казаннан килгән җыелышып бөтен әти-бабайлар. Шуңа Казанка булгандыр инде авыл. Өчәр-дүртәр бала белән килгәннәр. Башта Акбалыкта торганнар. Кайнана-кайнаталар сөйли иде. Дүрт бала белән килгәннәр. Аны сөйлиләр иде алар. Сәетбаттал абый булган, Салихә апай, Һаҗәр апай, тагын кем булгандыр. Алар 1921 елда килгәннәр.

Кайнанә булган Кибәхуҗадан. Бабайлар булган Сабинский районныкы. Әни 1914 елгы иде. Безне өч бала белән үстерде бер үзе. (Казанка авылы, Сабирова Фәризә Габдулхак кызы, 1933 елгы).

Халык бүгенге көнгә кадәр телен, гореф-гадәтләрен саклап яши. Акбалык авылы мәктәп директоры Мәүлетов Вильлюр Рәфыйк улы мәктәптә авыл тарихына караган документларны тупларга омтыла. Яшь буынга авыл тарихына, халыкның үткәненә мәхәббәт тәрбияләргә тырыша. Сүз уңаеннан, озак еллар Акбалык мәктәбе татар мәктәбе булган, ягъни бөтен фәннәр татар телендә укытылган.

(Дәвамы бар)

ХАН КУЧУМ. ПОСЛЕДНИЕ СТРАНИЦЫ

(к 420-летию битвы на р. Ирмень)

З. А. Тычинских, Д. М. Исхаков

Аннотация: *В статье рассматриваются события 90-х гг. XVI столетия, связанные с присоединением Сибирского ханства к Русскому государству, и политика Москвы по отношению к последнему сибирскому правителю – хану Кучуму.*

Ключевые слова: *Сибирское ханство, р. Ирмень, хан Кучум, служилые люди, воевода А. Воейков.*

В 1587 г. в 16 верстах от бывшей столицы Сибирского ханства был основан город Тобольск, ставший вскоре центром Сибири, в котором скапливались значительные военные силы, направляемые из России для удержания завоеванной территории.

Вместе с тем, в 90-е годы XVI в. говорить об окончательном присоединении сибирских территорий к Москве было рано. Хан Кучум, потеряв власть в Искере, по-прежнему представлял серьезную угрозу для новых русских владений, кочуя по степи и совершая время от времени нападения на русские остроги и татарские волости, признавшие власть Москвы. Центральная власть и сибирские воеводы неоднократно предпринимали действия для подчинения Кучума как дипломатическими, так и военными методами. Одним из методов стало стремление склонить хана Кучума признать русское подданство. Но хан Кучум всячески отвергал переговоры. Попытки убедить Кучума перейти на службу Русскому государству предпринимались вплоть до конца 90-х гг. XVI в. Как считают исследователи, Московское государство не оставляло надежду мирным путем решить ситуацию в связи со стремлением избежать крупных людских потерь до окончательной застройки территории острогами и укреплением своей власти в Сибири, а также со стремлением получить хана Кучума в качестве подданного, власть над которым дополнительно повысила бы авторитет России на международной арене [Рябинина: 2011, С. 92]. В связи с этим в документах 1593–1594 годов русским воеводам при строительстве города на реке Тара предписывалось не только опасаться набегов хана Кучума, но и уговаривать его перейти в российское подданство: «…а будет добьет челом и договор станет, и сына царевича даст в заклад, и отпустит ко государю к Москве…» [Миллер: 1999, Т. 1, С. 348]. Однако хан до последнего не оставлял надежды найти помощь, в том числе и

военную, чтобы отвоевать свое ханство. Поэтому, даже потеряв многих близких, он отказывается от лестных предложений русской власти: «не поехал Деи я к Государю, по Государеве грамоте, своею волею, в кое деи пору я был совсем цел, а за саблею деи мне к Государю ехать не по что». Другим методом борьбы с Кучумом было стремление «Кучюма царя истеснить» [Акты исторические: 1841, Т. II, С. 7]. Для этого ясачные волости, платившее дань Кучуму, переводили в полное русское подданство [Миллер: 1999, Т. 1, С. 247–249], а также, действуя методом фронтира, строили на этих землях новые русские остроги.

Для поимки хана Кучума предпринимались значительные усилия, но они не увенчались успехом. В 1591 г. отряд, состоявший из тобольских служилых людей во главе с воеводой Владимиром Кольцовым-Мосальским, настиг войско хана Кучума на Ишиме и нанес ему поражение у озера Чиликула. Хану Кучуму удалось уйти. Однако, это событие значительно уменьшило его дальнейшую военную активность, хан даже начал пытаться восстановить отношения с Москвой – сохранилась грамота хана от 1593–1594 гг., в которой он просил московского царя его пожаловать, передать ему Сибирский юрт как вассальное владение, просил к нему из плена отпустить султана Маметкула [Скрынников: 1982, С. 216]. На самом деле это было, скорее всего, маневром попавшего в безвыходное положение сибирского хана, просившего в 1595–1596 гг. помощи у бухарского хана Абдуллы. Но тот ему ничем помочь не мог, будучи занят борьбой за Хорезм [Скрынников: 1982, С. 216–217]. В 1595 г. войско Кучума потерпело еще одно поражение от отряда во главе с воеводой Борисом Доможировым. Кучум вновь избежал пленения. В 1597 г. отряды Кучума пытались захватить Тару, но безуспешно. Он все еще хотел договориться с русской властью, что видно из его грамоты, отправленной в 1597 г. воеводам г. Тары: «И ныне попытаем миритца… и язъ хочю правдою помиритца». Но одновременно Кучум и пугал русские власти: «…а с Нагаи есьмя в соединенье, и только с обеих сторон встанем, и Княжая казна шатнетца» [Собрание: 1819, ч.2, С. 131]. В послании московского царя Федора, с другой стороны, ему предлагалось стать служилым царем, даже давалось обещание устроить его в Сибирском юрте [Собрание: 1819, Ч. 2, С. 134]. Но Кучум не соглашался, видимо не доверяя московской стороне. Во второй половине 90-х годов XVI в. хан Кучум восстановил свою власть в Барабе, но в 1598 г. против него был организован поход, возглавляемый тарским воеводой А. Воейковым.

В августе 1598 г. объединенный русско-татарский отряд, общей численностью в 400 человек (И. Щеглов называет гораздо большую цифру, а именно, «700 человек русских и 300 татар» [Щеглов: 1883]) под пред-

водительством тарского воеводы Андрея Воейкова вышел из Тары и после долгих поисков и мелких стычек с противником в Барабинской степи обнаружил неподалеку от устья р. Ирмени на Оби главные силы хана Кучума, составлявшие более 500 человек. В ходе длительного и ожесточенного сражения войско Кучума было разбито. Большая часть семьи хана Кучума попала в плен. Из поименной росписи пленных, присланной воеводой А. Воейковым от 4 сентября 1598 г., известно, что в ходе этой битвы были взяты в плен пять сыновей хана (царевичи Асманак, Шаим, Бибадша, Молла, Кумыш), восемь цариц «Кучюмовых жен» и столько же дочерей [Акты исторические: 1841, Т. II, С. 6]. Кроме семьи хана Кучума, среди пленников были названы дочь и две внучки ногайского князя, пять князей и мурз. Плененные Кучумовичи были отправлены в Москву. Из документа также следует, что были убиты 6 князей, 10 мурз, 5 аталыков (также видимо князей), тесть хана с «товарищи». Кроме того, были убиты 150 «служилых людей», пытавшихся вплавь перебраться через Обь, да еще 50 человек, взятых в плен, «побиша», некоторых «перевешали», убили также брата Кучума Илитен султана и сына хана [Исхаков: 2006, С. 193–194].

В «Наказе» от 1598 г. русскому послу Александру Федоровичу Жировому-Засекину, было велено говорить об этих событиях следующее: «...государевы наши люди зашед Кучума царя на поле, побили на голову самого Кучума царя да брата его Илитеня царевича и детей его и племянников и с ним трех царевичей и многих князей, и мурз и всяких людей побили болши шти тысеч человек, а пяти царевичей Кучумовых детей Асманака царевича з братьею, десять цариц Кучюмовых и детей его жон да восмь царевых Кучюмовых дочерей, лутших мурз болши трехсот человек живых взяли и к государю нашему царю и великому князю Борису Федоровичу всея России самодержца привели, а улусы Кучумовы разорили...» [Труды: 1892, Т. 21, С. 50–51]. Хану Кучуму и в этот раз удалось уйти. С ним были его сын Али и некоторые приближенные. Погоня Воейкова за Кучумом не дала результатов, ничего не добились и отправленные на переговоры с ханом послы. На предложение примирения с русским царем, отправленное из Тары с сейидом Тул-Маметом, хан Кучум ответил отказом, заявив, что уходит к ногайцам, а сына [Алия] отправляет в Бухару [Акты исторические: 1841, Т. II, С. 7].

Эта победа стала важным этапом в дальнейшем продвижении русских в Сибирь.

В историографии нет серьезных свидетельств о том, что было с Кучумом после этих событий, сохранились лишь сбивчивые и противоречивые сообщения о том, когда и где он умер. После поражения хан Кучум

бежал к верховьям Иртыша и, по версии С. У. Ремезова, по пути «похитил у калмыков коней многое число». Однако калмыки настигли обидчика, и «многих кучумлян побиша и коней, свои стада отняша». С небольшим числом своих сторонников Кучум направился в Ногайскую землю, где был убит, а его люди «приидоша ко граду Тобольску и приложася ясак платити, овии же крестишася во христианство и поверстаны в службу в новокрещенский список, овии же мурзы и мурзичи, 300 человек поверстаны в службу и оклад им учинен по 15 рублей и по 7-ми. И поставиша русского голову, чиновника» [Ремезов: 1989, С. 567–568]. Г. Ф. Миллер пишет о двух версиях направлений его бегства – «в Казакскую Орду» и к ногайцам (мангытам) [Миллер: 1999, т. 1, С. 293]. В связи с этим точно определить дату и место смерти хана Кучума невозможно, да и имеющиеся источники противоречат друг другу. Так, в грамоте царя Михаила Федоровича называется 1598 г., другие же историки, исходя из того, что сын Кучума Али в 1601 г. стал ханом, определяют дату смерти Кучума 1601 годом. Татарский историк Х. Атласи, вслед за Абуль-Гази считал, что хан Кучум умер в племени мангытов (с которым были связаны правители Бухары). Не исключено, что эти места были родиной Кучума, куда он, потеряв свое ханство, и ушел, скорее всего, умирать. «Он не унизился до того, чтобы свою свободу, которую ценил превыше всего, променять на что-то другое. Как и всякий великий человек, он признавал лишь победу или смерть. Неволе хан предпочел смерть» [Атласи: 2005, С. 81–82]. Думается, в этих словах Х. Атласи отражается реальная оценка Кучума как выдающейся исторической личности, государственного деятеля, который, даже потеряв свой юрт, в течение почти двух десятилетий не переставал сражаться за него, несмотря на все посулы предпочел скитания и борьбу, который, потеряв все – государство, близких, не отступил от своих принципов и позиций. Хотя уже в 1597 г. хан понимал, что проиграл – в его грамоте воеводам г. Тары, сказано: «…а Сибирь не язъ отдалъ, сами есте взяли» [Собрание: 1819, Ч. 2, С. 131]. Историк XIX в. П. И. Небольсин дает аналогичную оценку личности Кучума: «Кучум неуступчиво боролся с Ермаком, в этой борьбе он не унижал ни своего сана, ни своего достоинства, ни падал ниц перед покорителем, мстил ему сообразно духу времени, и тайно, и явно, и, наконец, семнадцать лет скитался по степи. Он в диком величии своем, предпочел лучше пасть под ударами судьбы, но не запятнать себя добровольной передачей перед тем, кого он считал своими притеснителями и врагами…» [Небольсин: 1849, С. 114]. Современные исследователи истории Сибирского ханства также близки к этим позициям: «Хан Кучум в 1585–1594 гг. ценой невероятных усилий сумел возродить Сибирское ханство в новых границах и на новых терри-

ториях. Однако это государственное образование оказалось менее жизнеспособным. Несмотря на это, Кучум, в борьбе с русскими отрядами и с примкнувшими к ним татарами, продержался в этом неравном поединке до 1598 г. И вряд ли в Евразии нашелся бы какой-нибудь другой исторический деятель, который в такой ситуации сделал бы больше» [Матвеев, Татауров: 2012 б, С. 86].

Тем не менее, следует признать, что приведенные выше оценки личности Кучума не вполне типичны для российской историографии и на сегодняшний день в России еще нет объективной характеристики роли хана Кучума. До сих пор в исторической литературе встречаются отголоски средневековых историографических традиций XVII в., исторические стереотипы, направленные исключительно на оправдание колонизации Сибири, на возвеличивание Ермака, для чего идеализировались одни персонажи истории, которые противопоставлялись другим, защищавшим свои родные земли от завоевателей.

Несмотря на некоторые разночтения относительно даты смерти хана Кучума б. Муртазы – около 1599–1600 гг., московская сторона, как это отмечается в статейном списке русского посольства во главе с А.И. Власьевым в Священную Римскую империю, уже считало Сибирское царство своим владением [Трепавлов: 2012, С. 69], а в титулатуре Бориса Годунова появился новый элемент – титул «царь Сибирский» [Успенский: 2000, С. 49–50, 96], внешним выражением которого было наличие у московских государей «Сибирской короны» [Файзрахманов: 2002, С. 102], неизвестно, изготовленной специально или захваченной в Сибирском юрте в ходе его завоевания. В конечном счете, изображение этой короны, как одно из важных символов российского государства, оказалось на «гербе державном», согласно именному указу 1667 г. «О титуле царском и о государственной печати», на котором были изображены «три коруны, знаменующие три великие Казанское, Астраханское и Сибирское славные царства» [Соболева: 2000, С. 187].

Говоря о причинах падения Сибирского юрта (Сибирского ханства), можно отметить, что он пал по ряду причин. Прежде всего, хан Кучум и его потомки «были обречены в контексте начавшегося кризиса степной государственности под давлением расширяющихся оседлых государств. Этот процесс был закономерен для исследуемого периода, и гибель Сибирского ханства стала одним из компонентов постепенного исчезновения феномена кочевого могущества в Евразии [Маслюженко, Рябинина: 2009, С. 108–109]. Можно согласиться и с мнением А.В. Матвеева и С.Ф. Татаурова о том, что этот наследник Золотой Орды опирался на золотоордынские традиции государственной организации, которые уже сходили

на нет, а хан Кучум «не успел создать… выстраивая в Западной Сибири полноценное по меркам Средней Азии государство… нечто более адекватное вызову эпохи» [Матвеев, Татауров: 2012 а, С. 224].

Однозначно, Московское царство в экономическом и военном отношении было намного сильнее Сибирского ханства. В военном плане следует заметить, что сибирские татары, вооруженные согласно степным традициям и использовавшие старые тактики военных действий, оказались не готовы к использованию противником новых видов оружия (огнестрельного, прежде всего), новой тактики (опора на военные городки) [Худяков: 2000, С. 268–271; Маслюженко, Рябинина: 2009, С. 108]. Еще одной причиной падения Сибирского ханства надо признать существование в нем внутреннего противостояния Тайбугидов и Шибанидов, восходящего еще к концу XV–началу XVI вв. Похоже, что не была завершена и консолидация кочевого (полукочевого) и оседлого населения ханства. Ислам, который в период правления хана Кучума еще только укоренялся, не успел стать сплачивающей идеологией для всех жителей государства. Да и Шибаниды, по-видимому, «не смогли предложить единой идеологии, которая смогла бы всех сплотить» [Маслюженко, Рябинина: 2009, С. 108]. Наконец, ставший частью исламского мира Сибирский юрт в лоне исламской цивилизации оказался в ту эпоху, когда она в целом клонилась к упадку.

Литература

1. Акты исторические, собранные и изданные Археографической комиссией. Т. II. 1598–1613. СПб., 1841.

2. Исхаков Д. М. Введение в историю Сибирского ханства. Очерки. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2006.

3. Маслюженко Д. Н., Рябинина Е. А.Реставрация Шибанидов в Сибири и правление Кучум хана во второй половине XVI в.// Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Вып. 1, Казань, 2009. С. 97–111.

4. Матвеев А. В., Татауров С. Р. Сибирское ханство: военно-политические аспекты истории / Bibliotеca Tatarica. Серия «Этнополитическая история татар». Монография. Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2012а.

5. Матвеев А. В., Татауров С. Ф. Предатели хана Кучума и его союзники // Сибирский сборник. Вып. 2. Тобольск, 2012б. С. 80–87.

6. Миллер Г. Ф. История Сибири. Т. 1. М.: Изд. фирма «Вост. лит-ра» РАН, 1999.

7. Небольсин П. Покорение Сибири. Историческое исследование. СПб., 1849.

8. Ремезов С. У. История Сибири. / Памятники литературы Древней Руси. XVII в. Кн. 2. М.: Художественная литература, 1989.

9. Рябинина Е. А. Внешняя политика Кучум-хана в 1582–1598 гг. // История, культура и экономика средневековых тюрко-татарских государств Западной Сибири: материалы международной конференции. Курган, 2011. С. 90–95.

10. Скрынников Р. Г. Сибирская экспедиция Ермака. Новосибирск: Изд-во «Наука». Сибирское отд., 1982.

11. Собрание государственных грамот и договоров, хранящихся в Государственной коллегии иностранных дел. Ч. 2. М., 1819.

12. Соболева Н. А. Очерки истории российской символики. От тамги до символов государственного суверенитета. М.: Языки славянских культур; Знак, 2006.

13. Трепавлов В. В. Сибирский юрт после Ермака: Кучум и Кучумовичи в борьбе за реванш. – М.: Вост. лит., 2012.

14. Успенский Б. А. Царь и император. Помазание на царство и семантика монарших титулов. М. 2000.

15. Файзрахманов Г. Л. История сибирских татар (с древнейших времен до начала XX в.). – Казань, 2002.

16. Труды Восточного отделения Русского археологического общества. Т. 21. СПб. 1892.

17. Худяков Ю. С. Комплекс вооружения воинов Сибирского ханства // Средневековая Казань: возникновение и развитие. Материалы конференции. Казань, 2000. С. 268–271.

18. Щеглов И. В. Хронологический перечень важнейших данных из истории Сибири (1032–1882 гг.) / И. В. Щеглов. Иркутск: Восточно-Сибирский отдел ИРГО, 1883.

Фәнни популяр язмаларда төбәк тарихы

Краеведение в научно-популярных публикациях

ТӨРЕК ҖИРЕНДӘ ТАТАР ЭЗЛӘРЕ

Г. Ф. Шәйхиева

Истанбул

Без – Төркиянең иң борынгы шәһәрләренең берсе Истанбулда. Бу илгә килүебезнең максаты – биредә яшәүче милләттәшләребезнең яшәеше белән якыннанрак танышу иде.

Истанбул безне томан эченнән елмаючы кояшы, өч меңнән артык мәчетнең азан тавышына төренеп каршы алды. Үзенең тарихи биналары, мәгърур мәчетләре, кунакчыл халкы белән бик якын безгә Төркия. Бу илдә, узган гасырларда, халкыбыз сыену тапкан. Шуңа да якын һәм кадерле ул җирләр.

Исеме җырларда җырланган Истанбул – Төркиянең иң зур, иң куәтле, портлы каласы, сәүдә, мәдәният, мәгърифәт үзәге дә. Элеккеге Рим, Византия, һәм Госманлы империясенең башкаласы булган, Босфор култыгында урнашкан әлеге шәһәрне бер ягыннан икенче ягына кичәр өчен генә дә 150 чакрым юл узарга кирәк. Архитектура үрнәкләре белән шаккатырган искиткеч гүзәл кала тарих битләренә безнең эрага кадәр 659 ел белән теркәлгән. Истанбул, элеккеге исеме Константинополь, 1923 елга кадәр Төркиянең башкаласы булган. Илдәге үзгәрешләр, милли хәрәкәтнең үсешеннән соң, Төркия Республикасы төзелә һәм илнең башкала Әнкарага күчә.

Әнкара

Истанбул белән Әнкара арасы 500 чакрымга якын. Юл әйбәт, табигать искиткеч гүзәл. «Сәфәребез дәвамында без әле Истанбулга, әлбәттә, кире кайтачакбыз» дигән уй күңелдә рәхәт хисләр уятып, безне озата барды. Ә алда татарлар белән очрашулар, күрешүләр, аралашулар көтә... Кояш нурларын төрелеп, бар дөнья алтынсу-сары төскә кергән мизгелдә без Төркиянең башкаласына килеп тә җиттек.

Әнкара шәһәрендә 5 миллионга якын кеше гомер итә. Илнең иң мөһим дәүләт оешмалары, министрлыклары һәм иң зур дәүләт телерадиохолдингы нәкъ менә шушы калада урнашкан. TRT компаниясендә татар

телендә радиотапшырулар әзерләүче редакция дә эшләп килә. Гомумән, башкаланың үз йөзе, горурлыгы, дөнья мәйданында үз урыны бар.

Безне милләттәшләребезнең яшәеше, шушы илдә калган эзе кызыксындыра. Әнкарада Габдулла Тукай исемен йөртүче урам бар, бөек шагыйребезгә 125 ел тулу уңаеннан 2011 елны бюсты та куелган. Төркиядә Тукайга мөнәсәбәт бик яхшы. Шагыйрь үз гомерендә бер тапкыр да Төркиядә булмаса да, аның иҗатын биредә яшәүче татарларыбыз күз карасыдай саклый, кадерли, ярата. Алай гына да түгел, Төркия мәктәпләрендә Тукай иҗаты өйрәнелә.

Башкалада Казан шәһәре татарларының мәдәният һәм ярдәмләшү дигән үзәк эшли. Аның җитәкчесе – Әнвәр Мөзәффәр. Ул безне милләтне саклауда башкарылган эшләр белән таныштырды, киләчәктә башкарылачак уй-фикерләре белән дә уртаклашты. Очрашуга Әнкарада яшәүче милләттәшләребез, Татарстаннан килеп белем алучы яшьләр дә җыелган иде. Без аларга туган як сәламен тапшырсак, алар безгә үзләренең тормышлары хакында җиткерделәр, милләтнең горурлыгы булырдай шәхесләр турында сөйләделәр. Ә андый изге җаннар күп булган биредә. Шуларның берсе – күренекле татар зыялысы, инде мәрхүм Гали ага Акыш. Без аның бертуган сеңлесе Сәйдә ханым Акыш белән дә очраштык. Ул безгә Гали аганың үткән юлы турында сөйләде.

Гали Акышның әти-әнисе Октябрь инкыйлабыннан элегрәк Пенза губернасының Усть-Рахманов волостендагы Татар Юнәсе авылыннан килеп, Хайларда урнашып калганнар. Гали ага 1918 елның 14 гыйнварында Төньяк Маньчжуриянең Хайлар шәһәрендә дөньяга килә. 1924–29 елларда Хайларда татар башлангыч мәктәбендә белем ала. Аннан соң, шунда ук рус гимназиясендә укуын дәвам итә. 1934 елда Гали Акыш Гаяз Исхакыйның Хайлар татарлары алдында ясаган чыгышын ишетә. Әлеге чыгыш Гали Акышны гомере буе милләткә хезмәт итәргә этәрә. Гимназияне тәмамлагач, ул Ерак Көнчыгыштагы татар милли-мәдәни оешмасы ярдәме белән Мисырдагы Әл-Әзһәр университетына җибәрелә. 1938 елдан башлап Гали ага Варшава каласында яши башлый, «Прометей лигасы» эшчәнлегендә актив катнаша. 1938 елда ул Гаяз Исхакый белән таныша.

1940 елда Гали Акыш Төркиягә күченә. Анда Истанбул университетының икътисад факультетын тәмамлый, журналист булып эшли башлый. 1956 елның 28 ноябрендә Финляндия татары Зарифә Хөснетдин белән гаилә кора. 1966 елда Гали Акыш «Азатлык» радиосында эшләү өчен Мюнхенга күчә. 1983 елга кадәр «Азатлык»ның татар-башкорт редакциясендә тәрҗемәче һәм диктор булып эшли. 1990 елда ул беренче тапкыр Казанга килә. Бөтендөнья Татар Лигасы җитәкчесе итеп сайлана. 1990 еллар башында Чаллыдагы бер татар гимназиясенә Гали Акыш исеме бирелә.

Гали Акыш – татар, рус һәм төрек телләрендәге алтмыштан артык мәкалә авторы. Ул татар, рус, төрек, алман, инглиз телләрен яхшы белгән. 2000 елда ул кабат Төркиягә әйләнеп кайта. Гомеренең соңгы елларын Төркиянең Әнкара шәһәрендә сеңелләре Саидә һәм Нажия Акышлар белән бергә кичерә. Гали Акышның йөрәге 2011 елның 17 июлендә тибүдән туктый. Ул Әнкараның Җебежи зиратында, әти-әнисе, абыйсы һәм сеңлесенең каберләре янына җирләнгән.

Сәйдә апа менә шулай безгә гаиләләренең үткәнен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. «Безнең теләгебез шул, халкыбыз кая гына яшәсә дә, телен, динен, мәдәниятен, әдәбиятын сакласын иде. Габдулла Тукай халкыбызның бөек шагыйре. Киләчәк буын да шуны аңлап, хөрмәтләп яшәсә иде», – диде ул безнең белән саубуллашканда.

Бик кызыклы очрашу булды Әнкарада. Озак елларга күңелдә калачак мизгелләргә рәхмәтле булып, без кабат юлга кузгалдык. Көнчыгышка таба барабыз. Биредәге табигать көнләшерлек. Агачлы тауларны таш кыялар алыштырды, аннары таулар катыш далаларга күчтек. Матур! Таулар күп һәм алар төрле бу якларда. Итәкләрендәге сирәк кенә үскән агачлар аларга тагын берничә төс өсти. Сап-сары басулар. Инде уңышы җыеп алынган. Безнең өчен гел җәй булып тоелган Төркиядә дә табигатьнең үз кануннары бар икән. Каты җил чыгып, яңгыр сибәли башлады. Әйе, Төркиядә дә көз үз хакимлегенә кереште. Шәһәрдә яфрак өермәсе булса, кырда төсләр көрәше...

Бөгрүдилек

Юлыбыз – Төркиядә себер татарлары нигез салган бердәнбер Бөгрүдилек авылына. Ул Конья провинциясендә урнашкан. Бу авылга егерменче гасыр башында, ягъни бер гасыр элек, Русиянең Омск якларындагы Үләнкүл, Яланкүл, Кушкүл, Чарналы, Каракүл авылларыннан 100 гә якын гаилә күчеп килеп нигез салган. Килүчеләрнең максатлары – ислам динен югалтмау, саклау булган. Төркия хөкүмәте аларга Истанбулга урнашырга рөхсәт бирсә дә, милләттәшләребез авыл җирендә урнашырга телиләр. Ике ир-ат ил буйлап җир карарга чыгып китәләр. Сулы урын күреп, нәкъ менә бүгенге авыл урынын сайлыйлар. Шулай итеп, 1908 елда Бөгрүдилек авылына нигез салына. Авылның исеменең мәгънәсе «бәгъре тишек», ягъни «чишмә чыккан урын» дигәнне аңлата.

Юлда килгәндә салкын тидереп, башка авырулар ияртеп, әлеге җиргә килеп җиткәч тә бакыйлыкка күчүчеләр шактый булган. Бу турыда зираттагы кабер ташлары да сөйли.

Тора-бара Бөгрүдилек үсә, зурая. Авылның 350 йортка җиткән вакытлары да булган. Халык игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнгән. Хәзер дә шулай. Ләкин инде авыл кечерәйгән. Моннан егерме еллар элек

башлангыч мәктәп ябылгач, күп яшь гаиләләр якын-тирәдәге шәһәрләргә күчкәннәр. Авылда олы яшьтәгеләр генә калган. Ләкин китүчеләр туган нигезләрен онытмыйлар. Һәр бәйрәмгә шунда җыелалар. Кемнәрнең җирләре бар, алар җәен биргегә кайтып чәчәләр үстерәләр, уңыш җыялар – ноябрьгә кадәр авылда яшиләр икән. Кайчандыр күпләп хайван асрасалар, хәзер инде бу эш белән шөгыльләнмиләр. Авылдагы йортлар барысы да балчыктан һәм таштан салынган. Бер генә агач йорт та күрмәдек без. Агачларны бик кадерләп үстерәләр һәм саклыйлар Төркиядә. Авылда ягу өчен газ юк. Утын да ягарга ярамый, төп ягулык – күмер.

Бөгрүдилек авылы уртасында иман нуры сибеп мәһабәт мәчет калкып тора. Авылга нигез салганнан бирле, көнгә биш тапкыр намаз укылган. Ул бүген дә шулай. Узган ел яңа мәчет салып куйганнар, чөнки янгын чыгып, агачтан төзелгән иске мәчетләре янган булган. Авыл халкы һәм тирә-күрше авыллар ярдәме белән аякка баскан бу яңа мәчет.

Безнең сәяхәтебез Корбан гаете көннәренә туры килү сәбәпле, милләттәшләребезне күбрәк мәҗлес җыю, бер-берсенә кунакка йөрешү мизгелләрендә очраттык. Баклеҗан, пылау, катык чурба, тавык ашы кебек милли ризыклар белән сыйладылар. Катык чурбаныннан барлык мәҗлесләр вакытында да кунаклар авыз итәләр икән. Безне дә шулай сыйладылар.

Абидә апа Дүнмәс шушы авылда туып-үскән. Аңа 72 яшь. Балалары Коньяда. Дүрт бала үстергән. «Әти-әниләребезнең гореф-гадәтләрен, милли ризыклар әзерләү серләрен саклыйбыз», – ди Абидә апа. Кышка Коньяга күчәләр. Яз, җәй, көз үстергән уңышны сатып, кыш шунда көн күрәләр.

Салиха Орхан – шушы авыл кызы. Анталиянең Манаугат бистәсендә яши. Укытучы булып эшли. Татар телен әйбәт кенә белә. «Гаиләдә өйрәндем», – ди. Төркиядә Ураза гаетен – өч көн, Корбан гаетен дүрт көн бәйрәм итәләр икән. Менә шул вакытта кая гына яшәсәләр дә, кем генә булсалар да, туган нигезләрен онытмыйча, Бөгрүдилеккә җыелалар. Бу авылда туып-үскән кешеләр Даниядә, Норвегиядә, Финляндия, Германиядә дә яшиләр.

Безне авыл башында ук каршы алучы кеше Әрҗүмәнт Елдырым булды. Ул себер татар телендә дә, Казан татарлары телендә дә бик камил сөйләшә. Казанда да, әби-бабаларының туган якларында да күп мәртәбәләр булган. Үзе – эшкуар. Хатыны Венераны да ул Омскидан алып килгән. Без аларның гаиләләрендә дә булдык. Бергәләп өч малай, бер кыз үстергәннәр. Үзләре Конья шәһәрендә яшиләр, туган нигезләрен дә саклыйлар. Бөгрүдилек авылы тарихын өйрәнеп, «Яктылыкка омтылучылар» дигән роман язылган. Аның авторы – Әрҗүмәнт әфәнденең әтисенең энесе Әнвәр Елдырым. Ул башта шушы авылда имам булган. Аннан Финляндиядә егерме ел ислам динен тараткан. Хәзер Әнвәр ага Омскида яши. Аңа җитмеш биш яшь. Авылы белән элемтәсен өзми икән.

Моннан биш еллар элек Бөгрүдилек халкы авыл читенә урман утырткан. Үсентеләрен районнан биргәннәр. Бүген ул урынны халык күз карасыдай саклый. Урманга Әбдерәшит Ибраһим исемен биргәннәр. Әбдерәшит бабай «безнең жирлектә ислам дине бетә, әйдәгез, Исламбулга», дип, Омски якларыннан Төркиягә халыкны җыеп алып килүче кеше булган. Истанбулны ул «Исламбул» дип атый. Менә шулай, вакытында халык аңа ышанып Төркиягә юл ала һәм биредә төпләнә. Шушы шәхесне үз авылы тарихында саклар өчен урман утыртып, авылдашларының исемен мәңгеләштерә бер гасырлык тарихы булган себер татарлары авылы.

Биредә яшәгән милләттәшләребез белән саубуллашып Османия авылына таба кузгалабыз.

Османия

Без илнең башкаласы Әнкараны калдырып кабат юлга кузгалдык – Искешәһәр районында урнашкан Османия авылына. Тигез, яхшы юллардан узган чакрымнарны сизмәдек тә. Ә бит кайчандыр милләттәшләребез шушы тауларны атлар белән дә, җәяүләп тә кичкән. «Корытау» атамасын йөрткән җирләрнең урманын күреп – утын булыр, кое табып – су чыгар, дип өметләнеп бирегә туктаганнар һәм 1904 елда шушы авылга нигез салганнар. Араларында Казан татарлары, Оренбург, Самара, Уфа якларыннан килгән милләттәшләребез дә булган. Үгез җигеп җир сөргәннәр. 12 метр тирәнлектән су чыгарганнар. Кыскасы, авырлык белән булса да яңа тормыш корып җибәргәннәр. Ислам диненә тугры милләттәшләребез иң беренче булып мәчет салганнар. Вакытында авыл гөрләп торган. Хәзер биредә яшәүчеләрнең күбесе – өлкән яшьтәгеләр. Мәктәп ябылу белән яшьләр якын-тирә шәһәрләргә китү ягын караган. Күбесе – Искешәһәрдә тукталган. Ләкин туган нигезләрен, телләрен, гореф-гадәтләрне саклыйлар. Измир шәһәреннән туган авылына кунакка кайткан Мәҗит ага Сузар дөньяга аваз салган, кендек каны тамган, тәпи киткән изге җире белән безне бик кадерләп, матур итеп таныштырды. Авылдагы йөзәр еллык йортлар биредәге һәр вакыйганы саклап яшиләр кебек тоелды миңа.

Авылда йортлар таштан һәм балчыктан салынган. Бер генә агач йорт та күрмәдем мин. Монда агач бик кадерле, кыйммәт төзелеш материалы булып тора. Авылның ак әбие Хәлимә апа Баяр безгә әбисе сөйләве буенча мичкә ягып коймак пешерүне, чабынып мунча керүне искә алды. Хәзер инде авылда элеккеге гадәт буенча мич тә якмыйлар, мунча да юк. Мине иң гаҗәпкә калдырганы – мунчаның булмавы. Хәлимә апа, тарихи ватанына, үзенең сәламнәрен кечкенәдән хәтерендә тоткан, әнисе өйрәткән җырлары белән җиткерде. Милләттәшләребезнең янган йөрәк хисләрен, өзгәләнеп җиткергән сәламнәре тулы сандыкны җыеп алдык та кабат юлга чыктык. Бу юлы – Искешәһәргә.

Искешәһәр

Яшьләр каласы саналган Искешәһәргә килеп кергәндә инде караңгы төшкән иде. Биредә иң зур университетларның берсе урнашкан. Анда күпсанлы студент белем ала. Шәһәрнең үз йөзе бар. Искешәһәрдә милләттәшләребез шактый. Быел ул төрки дөньясының мәдәни мәркәзе итеп сайланган. Искешәһәр бик төзек, тыныч, осталарга бай кала. Тар урамнарда төрле төстәге йортлар тезелеп киткән.

Иң элек юлыбыз Яшел әфәнде урамында урнашкан Татар йортына алып килде. Искешәһәрдә халкыбызның үткәнен, бүгенгесен, йолаларын саклаган музей да ачылган. Казан татарларының мәдәни үзәген төзүдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның ярдәме зур булган. Аны ачу тантанасында ул үзе дә катнашкан. Татарларыбызны берләштерүче оешманың җитәкчесе – Нәди Өздәмәр. Чыгышы белән Османия авылыннан. Татарлыкны саклау өчен төрле чаралар уздыралар, милли, дини бәйрәмнәребезне онытмыйлар. Сабантуйны да зурлап уздыралар икән Искешәһәрдә.

Үзе архитектура үрнәкләренә бай, үзе иске, үзе тарихи һәм гүзәл каладан аерылуы авыр булса да, китми хәлебез юк, безне татар авылларында гомер итүче милләттәшләребез көтә иде. Без сәфәребезне дәвам итәбез. Бу илдә узган чакрымнарның һәр тукталышы онытылмаслык хатирә булып хәтер дәфтәрендә теркәлә тора. Күпме газаплар чигеп килеп җиткән монда татарлар. Таулар, диңгезләр кичкән, Истанбулны ислам иле дип, бабалар мирасын саклар өчен үз туган туфракларын ташларга мәҗбүр булганнар алар. Бәхет эзләп киткәннәр, бәхет алар өчен иман булган.

Юлда барганда көзге табигатьнең матурлыгына соклануыбызны һич кенә дә яшерә алмадык. Төркиядә ул бигрәк тә күп төсле икән дигән фикергә килдек. Яңгыр ява, ул арада көзге кояш чыга һәм төсләрне тагын да баета. Әле кояш, әле яңгыр безнең юлдашыбыз. Көзге яңгыр болытларыннан калышмыйча, Әфәнде Күпере авылына килеп туктадык.

Әфәнде Күпере

Без килеп җиткәндә көн кичкә авыша башлаган иде. Безне Әфәнде Күпере авылының мохтаре, ягъни башлыгы, Якуп Дургун каршы алды. Көзге яңгырның салмак кына сибәләве тәнгә суык үткәрде. Җылы өйгә узасы, туңган кулны җылы мичкә куясы килә. Бу яклар Төркиянең иң салкын урыннары диделәр безгә. Сигез ай дәвамында мичкә ягалар икән Әфәнде Күперендә. Татар халкына кунакчыллык хас. Бу якларда нык сакланган ул. Якуп абый да безне өенә дәште. Мәгърифәт, дин таратучы искиткеч матур гаилә – Якуп абый белән Сафия апа Дургуннар гаиләсе белән дә якыннанрак таныштык. Дүрт бала: өч ул, бер кыз үстергәннәр. Улларының хәзер үз тормышлары. Салих – Кырымда, Рамазан – Кутахи-

ядә, Борһан Идәле авылында хәзрәт булып эшлиләр, кызлары Сөхәйдә Кутахиядә унынчы класста укый. Якуп абый сыер да асрый, умарта да тота. Казлары, тавыклары да бар. Нәкъ бездәгечә!

Көз көнендә тән әле суыкка ияләшмәгән, шуңадыр җылыга керү аерым бер рәхәтлек өстәде. Эчкә уздык, җылындык, тик кулны мичкә куеп түгел. Бу якларда таш мичләр калмаган инде, алар җәйге йортларда ризык пешерер өчен генә кулланыла. Шулай ук утын ягу да юк. Чөнки ул бик кыйммәт. Йортларда тимер мичләрдә ташкүмер ягалар. Алай арзанрак чыга икән. Тормыш таләпләре үзгәргән. Ә менә сагыш, хәтер, үзгәрешсез... Авылның яше-карты бер йортка җыелып, еш кына шул хисләр дулкынына чума. «Безнең әбиләребез бәлеш, кош теле, коймак, «ачык авыз» – пәрәмәч пешерәләр иде. Самаварсыз чәй артына утырмаганнар. Без дә шул гореф-гадәтне сакларга тырышабыз», – ди хуҗабикә Сафия апа.

«Мунча элек бар иде, хәзер юк инде. Чөнки утын юк. Ун елдан артык, закон буенча, ягырга утын бирмиләр. Урманнар аз икән. Бөтен ил, хәтта тау битләренә дә агач утырту белән мәшгульләр. Имән-мишә агачы белән чабына торган булалар», – ди Якуп абый.

Әлбәттә инде, мин иң элек авыл тарихы белән кызыксындым. Якуп абый әйтүенчә, Әфәнде күперенә 1908 елда нигез салына. Хәзерге Татарстанның Лениногорск районы Сарабиккул авылыннан бәхет эзләп күченеп киләләр. Елга буена килеп урнашкан татарлар, елга аша йөрергә зур күпер дә салалар. Кайчандыр тирән һәм мул сулы елганың хәзер суы кимегән. Яз көнне су арта, ул вакытта балык та тоталар авылныкылар. Тирә-күрше авылларда яшелчә үстерү белән шөгыльләнәләр, суны елгадан ала башлагач, су кими икән.

Авылга нигез салыну белән мәчет тә төзелә. Биредә вәгазь гомер-гомергә төрек телендә сөйләнә. 1970 елда җир тетрәгәндә мәчетнең манарасы мәчет өстенә төшеп, аны җимерә. Соңыннан, 1972 елда, яңа мәчет салына, агачтан манара куялар. 1993 елда манара җилдән ава. 1995 елда кабат яңа манара торгызыла. Стеналары ярылып китә башлагач, мәчетне сүткәннәр. Тирә-күрше шәһәрдә яшәүче авылдашлары да ярдәм кулы сузарга вәгъдә биргәннәр. Тиздән Әфәнде Күпере авылында яңа мәчет калкып чыгачак, моңа Әфәнде күпере халкы чын күңелдән ышана.

Авылда бүген егерме биш йорт бар, алтмышка якын кеше яши. Барысы да татарлар. Ике гаилә бар, аларның хатыннары татар, ирләре төрек. Барысы да татарча сөйләшәләр. Яңа гына Измирдан тагын бер татар гаиләсе кайтып урнашкан.

Әфәнде күперендә мәктәп 1993–94 елларда ябылган. Укыту төрек телендә булган. Балалар үзара татарча сөйләшсәләр, укытучы аларга җәза бирә торган була.

Авыл халкы элек-электән игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. Бүген дә авылда яшәүчеләр бу шөгыльләрен югалтмаганнар. Шәһәрдә яшәүчеләр дә үз җирләрен саклаганнар. Язын кайтып чәчәләр, көзен урып-җыйганчы туган авылларында яшиләр.

Авылда элек җирләр аз булган, 1954–56 елларда утызлап гаилә, авылларын калдырып яңа җирләр эзләргә чыгып китәләр. Һәм яңа авылга нигез салына, аңа Каракуа дип исем кушалар. Бүген ул авылның исеме Гюрсу. Бу – гөрләп торган сулы авыл дип атала.

Бик җанлы, матур очрашу булды Әфәнде Күпере авылында. Чәйләп алдык та, юл кешесенең юлда булуы хәерле, дип, кабат юлга кузгалдык. 270 чакрымнан соң, кайчандыр шушы Әфәнде Күпере авылында гомер иткән, аннан, җир җитмәү сәбәпле, тору урыннарын үзгәрткән, Әфәнде Күперенең бертуганы Гөрсу авылында яшәүче милләттәшләребез янына ашыгабыз.

Гөрсу

Әфәнде Күпереннән аерылып «башка чыккан» Гөрсуга килеп җиткәндә инде караңгы төшкән иде. Авыл безне йолдызлы төндә айлы шәлен ябынып каршы алды. Төнге караңгылыкны бизәп, бөтен авылны яңгыратып музыка уйный. Монда туй итеп яталар икән, дөресрәге, Гөрсу авылында «кына кичәсе»нә туры килдек. Безне, ерактан килгән кардәшләр буларак, үзләренең бәйрәмнәренә дәштеләр.

Кына киче

«Кына киче» – кыз озатуның бер йоласы Төркиядә. Айсал исемле кызны озаталар икән. Авылның әбиләре, апалары, яшьләре, балалары кәләш өенең ишегалдында җыелган. Ирләр, егетләр капканың урам ягында калган. Кияү егетенә генә ишегалдына керергә рөхсәт, диделәр. Биредә җыелганнарның олысы да, кечесе дә төрек көйләренә рәхәтләнеп бии. Без килеп кергәндә булачак килен алсу-кызыл күлмәктән иде. Бераз биегәч, Айсал күлмәген алыштырырга кереп китте. Кич буена берничә тапкыр алыштырып чыкты ул киемен.

Менә кәләш янына кияү егете килеп утырды. Кулларына шәм тоткан кызлар аларны уртага алып биеделәр дә биеделәр... Соңыннан кияү ягыннан туган тиешле бер ханым кәләшнең кулына кына сөртте һәм перчатка киертте. Аның махсус перчаткасы бар икән.

«Бу йола нәрсәне аңлата?», – дип кызыксындым мин. «Кәләш бәхетле һәм иренә тугры булсын өчен кирәк», – дип аңлаттылар миңа. Әлеге йола өч очракта үткәрелә икән: ир-егетне солдатка озатканда – башына, кияүгә чыкканда яшь кәләшнең – кулына, корбан чалганда сарыкка сөртәләр икән кынаны. Берсе – иленә, икенчесе – иренә, өченчесе Ходайга тугры булсын дип.

Кунакчыл гаилә

Кәләш йортында тәм-томнар белән сыйлангач, безне кунарга Комҗылар гаиләсенә алып килделәр. Гаилә башлыгы Халит – татар егете. Татарча бик матур сөйләшә. Аның ханымы Нәргиз – Болгарстан гучманы. Икесе дә әле яшьләр, Мәрвә һәм Хәйрия исемле кызлар үстерәләр. Бу якларга килеп урнашканда Халитнең әбисе Зәйҗан алты яшьтә була. Әби 105 яшькәчә яшәп, күптән түгел генә вафат булган. Халитләр гаиләдә алты бала үскән. Әнисе Мөкәррәмә апага 75 яшь. Әтисе Мөхәммәтгали исемле булган, хәзер гүр иясе. Алар барысы да тамырлары белән Татарстанның Лениногорск районының Әби авылыннан икән. Ничек тә булса нәсел җепләренең очын табарга хыялланып яшиләр.

Иртән, хуҗабикә корган табыннан авыз иттек тә, хуҗаларга рәхмәт әйтеп авыл белән якыннан танышырга урамга ашыктык. Гөрсу авылының таң әтәчләре белән үк тормасак та, йокыдан торып урамга чыкканда кояш әле түбән иде. Төнлә килү сәбәпле, авылның никадәр матур урында урнашканын күрмәгәнбез. Әйе, бу җирләрне сайлап бер дә ялгышмаган безнең милләттәшләребез.

Йөзем

Без биредәге татарларның яшәеше, көнкүреше белән якыннанрак танышу теләге белән, иң беренче... йөзем басуларына киттек. Бу татлы җимешне ничек үстерәләр соң?

Авылның 500 гектар җире бар икән. Элек-электән шул җирне 28 гаиләгә бүлгәннәр. Бу уңдырышлы җирдә кемдер йөзем генә үстерә, кемдер мал да тота, арыш, бодай да чәчә. Барлык мәйданның 50 гектар өлешендә йөземнең «султания» дигән сортын үстерәләр. Бер гаилә сезонга биш тоннадан алып ун тоннага кадәр йөзем жыя. Уңышның, әлеге «султания» дигән яшел төстәге йөземнең, 90 проценты Россиягә озатыла икән.

Эш сезоны декабрь аенда башлана һәм сентябрьдә тәмамлана. Һәр гаиләдә уртача 3500 төп йөзем утыртылган. Үсентеләрне кисәләр, бәйлиләр, җирне сөрәләр, ашлыйлар, сугаралар... Август-сентябрь айларында өлгергән җимешләрне җыеп озаталар.

Җыелган уңышны, килеп, җыеп алып китүчеләр дә бар, диделәр. Йөземне җиргә җәеп киптерәләр. Кипкән йөземне җыю нокталарына үзләре илтеп тапшыралар икән. Авыл кешеләре йөземнең согын кайнатып, бикмәз дә әзерлиләр. Ул бик татлы, нәкъ бал кебек. Без дә авыз иттек.

Авыл тарихы

Йөзем басуларында эш беткәч, халык хәзер туй итә, диделәр. Әйе, иң күп туйлар нәкъ менә шушы көз айларына туры килә икән. Башта зурлап никах уздыралар, аннан алдан телгә алынган – «кына киче».

Без авыл халкы белән танышуыбызны дәвам иттек. Татар түбәтәе кигән Хәйретдин бабай Кыякны авылның иң өлкән кешесе, диделәр. Хәйретдин бабайның сөйләве буенча, аның нәсел очы да Татарстанның Лениногорск районына барып тоташа. Гөрсуга, әйткәнемчә, узган гасырның илленче елларында Әфәнде Күпере авылыннан аерылып чыгучылар нигез сала.

Октябрь аеның икенче яртысы, бертуктаусыз яңгыр ява, кайбер көннәрне яңгыр бозга әйләнеп китеп аралаш ява. Көзге суык җилләр төн яктан сызгырып исәләр. Табигатьтә көз үзенең бөтен күңелсез кыяфәте белән, чырайларын сытып, каш-кабакларын җыерып, ачулы тавышлар чыгарып дулаган бер таңда Габдрахман мулла арбасына кечкенә сандык белән арыш капчыгына салган азык-төлекне куеп, кечкенә Талип арба артыннан җәяүләп, ерак Тайсуган авылына укырга дип чыгып китә. Болытлар калын һәм түбән булганлыгы өчен таң белән көн арасы бик озак сузыла, вак яңгыр өстән һич туктамый сибәләп тора. Юл күптән изелеп үзенең шәкелен югалткан, арба юлы лай җәймәсенә әйләнгән, ат исә, әкерен генә авырсынып шул сузылган җәймәнең уртасыннан бара. Кечкенә Талип юл читеннән, кеше йөрмәгән, сукмак булмаган җирдән атлый. Чөнки монда аяккаябышса да, сыек лае юк. Ләкин чабаталарга лай бик нык ябыша, аякны куе, үзле лайдан тартып алуы бик кыен, аны кулдагы таяк белән тиз-тиз тазалап барырга килә. Ул вакытта авыл араларындагы юлларның пычраклыгы, күперләрнең начар һәм күбесенең җимерек булганлыгы, яңгырның бер туктамый коеуы сәбәпле Талипка бер сәгать тә арбага утырырга туры килми. Хуҗаның үз улы үзе белән бара. Талип кай вакыт тирән уйга батып, мәдрәсә хәятын, андагы хәлләрне күз алдына китерә, кайчак эченнән генә җырлап та куя. Әмма бүгенге кыенлыклар аның күзенә дә күренми. Яңгыр беленми, суык та сизелми. Югыйсә көзге былчырак бишмәтен үтеп тәнгә барып җиткән, аяк бармаклары арасындагы куе кара лай шалбырдап, сытылып бара. Чабата да «арып» «мыеклары» сузыла башлаган. Әмма укырга бару теләге барысыннан да өстен иде. Ул көнне күктә кояш бөтенләй күренмде. Төш вакытында бер авылга кереп ат ашатып, чәй эчеп чыгалар да юлны дәвам итәләр. Караңгы төшкәндә генә Кичү дигән урыс авылына кунарга туктыйлар. Талип арбага бер минут утырып карамаган булса да, атны тугарып, аңа ашарга бирә, шуннан соң гына өйгә керә. Кичү авылы кайчандыр зур гына урыс авылы булып, Казан ханлыгы җимерелгәч, урыс дәүләтенең

шәркый чигендә, гаскәрләр торган крепость вазифасын башкарган. Әби патша Екатерина Икенче заманында Кичү аркылы Казан-Оренбург каенлы юлын ясыйлар. Бу юл җирдән шактый гына күтәрелеп өсте комлы вак таш белән тигезләнгән. Вак сызаларга кадәр күперләр салынып юлның ике ягына тигез сызык белән тезеп дүртәр рәт каен агачлары утыртылган. Халык бу юлны «әби патша юлы» яки «каенлы юл» (автор искәрмәсе: «Екатеринский почтовый тракт») дип йөртәләр.

Кичәге юл газабыннан соң, бу каенлы юл ат өчен дә, Талип өчен дә бераз җиңеләйгән кебек булып кала. Менә алар Колшәрип, Бигәш, Әлмәт, Тихоновка, Түбән Мактама дигән авылларны үтеп, кичкырын Зәй елгасына салынган зур тегермән буасын үтеп, Тайсуган авылына барып керәләр.

ТАЙСУГАН МӘДРӘСӘСЕ

Тайсуган авылы Бөгелмә өязе, Самара губернасы биләмәсенә кереп, Зәй суының уң ягына урнашкан татар авылы булып, Кармыштан 70-75 чакрым ераклыкта тереклек итә. Тайсуган авылы бу дәвердә үзенең дини мәдрәсәсе белән күрше авылларга гына түгел, бәлки татар дөньясында яхшы даны чыккан дини мәдәният үзәге иде. Бу чорда мәдрәсәнең әсаси җитәкчесе (иң төп яки беренче җитәкчесе мәгънәсендә), аңа рухи көч биреп, Ислам мәдәниятенең фәлсәфә дәресләрен, дини тәгълиматны укытучы Зәки хәзрәт Ногманов дигән белемле һәм бай имам була. Тайсуган мәдрәсәсендә шәкертләр шунда торып укыйлар. Шәкертләр идәндә йоклыйлар, шунда ук укыйлар, китаплар кую өчен тәбәнәк дүртпочмаклы кечкенә өстәлләр кулланалар. Әсәселбәйт (өй җиһазлары, мебель) турында әйтеп тә торасы түгел, аның нәрсә икәнен дә белүче юк. Кичләрен чаршау тартып, бүлмәне бүлеп, шуның эченә кереп йоклый торган булалар. Ашарга һәркем үзе пешерә, чәйне үзе кайната, өсте-башын да үзе карый. Ашлар пешерү өчен зур плитәле таштан салынган аерым бер өй бар. Ә мәдрәсә зур бер ишек алдын хасил иткән җиде аерым-аерым агач өйләрдән гыйбарәт. Өйләрне ягу яки җылыту, идәннәрне юуу, тәртип саклау һәммәсе дә укучылар кулында. Менә шундый шартларда 10 яшьтән алып 30 яшькә кадәр булган шәкертләр мәдрәсәдә гыйлем җыялар. Тайсуганда уку елы җәйге авыл хуҗалыгы эшләре бетеп, кыр эшләре туктагач, гадәттә кар төшкәндә башлана. Шулай ук укучылар өчен сыйныфлар да төзелми, сыйныфтан сыйныфка күчү кебек кагыйдәләр дә булмый. Программалы укуны да белмиләр. Барысы да бер өйдә мөгаллим сөйләгәннән чыгып белем ала. Гадәттә шәкертләрне аталары алып килеп, Зәки хәзрәт белән сөйләшеп, аңа өч яки биш сум хәерне төртеп, баласын шундагы таныш яки якын булган бер хәлфәгә тапшырып китәләр. Шул хәлфәдән алар сабак алалар, тәгълим (өйрәнү) күрәләр. Янында беркеме дә

булмаган Талибетдин бу мәсьәләләрне үзе хәл итә. Ул мәдрәсәдә якташ мишәр малайлары белән таныша. Алар аны Кармыштан ерак булмаган Чертуш авылыннан чыккан мишәр Кивам хәлфә белән таныштыралар. Кивам хәлфә Талипны үзенә ала һәм башлангыч дәресләрне үзе укыта. Бу 1885 елның көзе, үктәбер аеның соңгы көннәре иде.

Ярлы гаиләдән белемгә сусап килгән Талип беренче көннән үк тырышып укый, ялкаулык яки иренү кебек гадәтләрне һичбер белдерми, ялган сөйләүдә яки үзенә кирәк булмаган нәрсәләргә аралашмый, шуның өчен абруе шәкертләр уртасында да, хәлфәләр арасында да бик тиз күренеп кала. Ул мәдрәсәдәге кайбер акчалы эшләрне дә бик тиз эшләп куя. Шул чордагы татар мәдрәсәләрендә һәр шәкертнең ләкабе (кушаматы, псевдоним) булуы шарт була. Монда ләкабне шәкертләр үзләре куя, баш ватып торасы да түгел. Талипка да ләкаб табыла. Усалырак шәкертләрнең берсе аңа: «Нәрсә син, сука башы кебек катып калдың», – ди. Балаларга бик кызык була, кычкырышып көләләр. Шул минуттан алып мәдрәсәне тәмам кылып чыгып киткәнгә кадәр аны «Сука башы Талип» дип йөртәләр. Кушаматы туры да килеп тора үзенә. Чөнки җилкәсе бераз күтәренке була. Бу гомуми гадәт булганга, Талип моңа хурланмый. Талипка катып калган арыш ипиен ак су белән ашап көннәр үткәрүләре бик кыен, бик авыр булса да уку дәрте, гыйлемле кеше булу, тамагы тук бай булу һәрдаим хәтерендә торды. Беренче елларда укулар бетү белән Кармышка сөекле әнисе Гамбәр карчык һәм бабасы Фәхри карт янына кайтырга ашыга. Мәдрәсәдә укулар, язгы дала эшләре башлану белән тәмам була. Чөнки шәкертләрнең күбесе үз өйләрендә эшче яки сабанчы булып хисапланалар. Шул сәбәпле мәдрәсәдә бик аз гына бала кала. Алары да чынлап яз җитү белән укуларны ташлап туган җирләренә кайтып китәләр. Талип та авылда бабасына, туганнарына булыша. Мәдрәсәгә китә башлагач, тагын шул арыш капчыгын аркага күтәреп, лайга бата-бата үз ихтыяры белән укырга китә. Фәхри бабай хуҗалыгы аңа бернәрсә дә җиткезеп бирә алмый, яңа киемнәр дә тегә алмый, чиста кәүеш тә (җиңел аяк киеме) алып бирә алмый. Шуның өчен Талип шәкерт 18 яшьләренә җиткәч авылга кайтмый, туп-туры Чистай пристанына китеп эшли. Җәй айларында эшләгән акчасына, ул үзенә матур итеп бай балалары кия торган чалбар, якалы җиләннәр дә, аякка итек-кәүеш, кыш өчен киез итекләр дә алып куя. Үзенең яраткан хәлфәсе Кивамга да бүләкләр алу җаен таба. Талип шәкерт белән Кивам хәлфә арасындагы мөнәсәбәт елдан ел ныгый, бер-берсенә ышаныч вакыт үткән саен арта гына бара. Соңгы елларда мәдрәсәдә Кивам хәлфәнең абруе бик күтәрелә. Зәки хәзрәт аны үз итә. Чөнки Кивам хәлфә гади крәстиян баласы булганлыгы өчен бар көчен һәм булганлыгын

күрсәтеп Зәки хәзрәткә хәләл хезмәт итә. Зәки хәзрәт аны мәдрәсәгә казый итеп билгеләгән.

Кивам хәлфә үзендә булган бөтен гадәтләрне, яхшы хосусыятьләрне (үзенчәлекләрне) Талип шәкерткә дә өйрәтә. Гарәп телен, диннәр фәлсәфәсен, «Гакаид тәварих» кебек китапларны яхшы белә, рузаны бер дә калдырмый. Зәки хәзрәт тә аның зирәклеген күреп ала. Кивам Тайсуган халкы арасында да билгеле булып, авыл халкы аны ярата, аш-суга, кыз туе, балага исем кую, үлем-китем, Коръән багышлау кебек дини һәм иҗтимагый мәрасимнәрдән дә (гадәткә кергән эшләр) калдырмыйлар. Соңгы елларда хәлфәсе белән бергә Талип шәкерт тә мондый эшләрдә еш катнаша. Аны да Тайсуган халкы таный.

Тайсуган мәдрәсәсе җитәкчесе һәм имамы Зәки хәзрәт бик бай була. Ул игенне күп игә, Зәй суына корылган 6 ташлы он тегермәне эшләп тора, Зәй суының бик матур тугаенда, шомырт, сирень әрәмәләре эчендә умарталык, анда 250–300 баш багана умарталар утыра, аның янында халык тарафыннан муллаларга бирелә торган болынлык, хуҗалыкта бер утар аяклы маллар, зур урам ягына ишеген каратып салган таш кибет, болар һәммәсе бертуктамый эшләп торалар. Шуның өстенә татар галәменә даны таралган мәдрәсә, мәчет, мәхәллә, уку-укыту кебек мәсьәләләр Зәки хәзрәтнең вакытын бик күп ала. Зәки хәзрәт күптән инде үзенең кайбер эшләрен үзе ышанган Кивам хәлфәгә тапшырып, аның аркылы җитәкчелек итә. Мәдрәсәдә ул казый, андагы интизам (кагыйдә буенча эш итү), тәртип, канун-кагыйдәләр, уку-укыту эшләрен оештыру, мәдрәсәне ягу, җыештыру, «килде-киттеләр» белән очрашу кебек вазифалар аңа йөкләтелгән. Кивам хәлфә һәр көн кичкырын хәзрәтнең өенә кереп хисабәт (хисапка алу, санау) биреп, хәзрәтнең яңа күрсәтмәләрен һәм боерыкларын алып чыга. Кайбер вакытларда Кивам хәлфә кунакта була яки авырып кала, мондый чакларда бу эшләрнең һәммәсе Талип шәкерт җилкәсенә төшә, ул аларны хәлфәсеннән дә яхшырак үтәү өчен чын күңелдән тырыша. Зәки хәзрәт җәй айларында да Кивамны җибәрәсе килми, тегесе дә авылларына кайтырга ашыкмый, чөнки анда кайтып эшләүдә бер файда юк. Инде бу хезмәтләр өчен хәзрәт аңа яхшы гына айлык түләп бара. Аңа ияреп Талип та Тайсуганда калып, я умарталыкта эшли, я тегермәндә тора, кайвакыт кырдагы ашлыкларны суктырып амбарларга һәм көзге чәчүлекләргә әзерләтә. Монда эшләү аңа киләчәк язмышында бик күп тормыш сабагы бирә. Кесәгә бераз акча кергәч әнисеннән алып киткән сандыгын да кире кайтара, ә үзенә Мәкәрҗә ярминкәсеннән гармунлы һәм каешлы зур чемодан сатып ала. Яңа Әлмәт базарыннан уку әсбаплары алып шуның бәясен бераз арттырып та сатып үз көнен үзе күрергә өйрәнеп китә. Дәрәҗәсе, буе үсеп, Зәки хәзрәтнең үзеннән генә дәрес алырга йөри.

КӨТЕЛМӘГӘН ФАҖИГА ЯКИ ТАЛИП ХӘЛФӘ

1892 елның үтә киткән суыклы гыйнвар ае. Җир өстен каплаган кар, бөтен дөньяны үз астына алып туңдырганга, җир өстендә бер җылылык калмаган. Тайсугандагы Зәки хәзрәтнең агач өйләрдән гыйбарәт булган, һәр кайсы аерым утырган мәдрәсә бинаналары укучы балалар белән тулы. Мәдрәсә ишекләре ачылганда шәкертләрнең кычкырышулары ишетелеп, ишек башыннан мунчадагы кебек пар күтәрелә. Һаваның суыгы тынны каплый, анда-монда йөргән кешеләрнең авызларыннан чыккан пар папирос төтене кебек аларны озатып бара. Бу иртәнге сәгать уннар. Шул вакыт мәдрәсә капкасыннан йөгереп, куркынган кыяфәтле бер шәкерт килеп керә дә, кулларын бутап: «Кивам хәлфә коега төште» дип дүртенче өйгә мөгаллимнәр яши торган йортка таба чаба. Ул арада булмый аннан 3–4 кеше чабып чыгалар. Аларның берсе Талип. Бу вакытта кое янында ике кеше, «ай харап булды, тизрәк» дип нәрсә эшләргә белмичә бер урында таптанып каушап торалар. Талип бик җитезлек белән лапаста эленеп торган сүс дилбегәне алып, бер башын биленә бәйли, икенче башын баганага бәйләп коега төшеп китә. Кое эче калын боз булып каткан, кеше сыярлык кына. Талип дилбегәгә асылынып сак кына аска төшә. Аның бөтен уе дустын коткарып калу иде. Әмма тәкъдирдә башкача язылган була шул. Кивам хәлфә иртә белән коедан су алган чакта, кое крыенда шомарып каткан бозга аягы таеп китеп, коега башы белән киткән икән. Талип аны су эченнән башы түбән хәлдә тартып ала. Бу вакытта ул инде җансыз, башы белән кое төбенә бәрелгән була. Кивам хәлфәне һәм Талипны коедан дилбегә белән тартып чыгаралар. Бу көтмәгәндә һәм искәрмәгәндә аяк астыннан килеп чыккан бәла мәдрәсә эчендә генә түгел, бәлки бөтен Тайсуган авылы халкы өчен дә зур вакыйга, фаҗига булып кала. Икенче көнне мәдрәсәдә дәресләр булмый. Кивам хәлфәне олы тантана белән Тайсуган авыл зыярәтенә җиназа укып җирлиләр. Җиназа намазында меңнән артык кеше катнаша...

Бу аянычлы фаҗига Зәки хәзрәтне зур хафага (кайгыга) салып куя. Ул җиназа намазыннан кайткач та хезмәткәрләренә, олырак шәкертләргә коены күмеп ташларга куша. Талип та сагышлы хәсрәттә йөри. Әмма моның белән генә үлгән хәлфә кире кайтып килми. Талип озак итеп дустының рухына дога кыла. Ходадан ялварып: «Әй ходаем, миңа беренче баламны угыл кыл! Мин аның исемен Киваметдин дип атар идем», – дип чын йөрәктән сорый. Шуның белән күңелен юата һәм нәзер әйтә. «Берәү үлми, берәү көн күрми» дигәннәр борынгылар. Кивам хәлфә үлеме белән мәдрәсәдә эшләр туктамый. Мәдрәсә янәдән җанланып үз юылыннан бара. Талипның хәлфәне коткарудагы омтылышын шәкертләр дә һәм олылар да бер каһарманлык итеп сөйлиләр. Яшь шәкертләр Талипны укытучылары итеп куюны сорап Зәки хәзрәттән үтенәләр...

Зәки хәзрәт Талип шәкертне укытучы кылып тәгаенләнгән көннән алып Тайсуган мәдрәсәсе шәкертләре Кармыш авылы ярлы крәстиян углы Талибетдинне «Талип хәлфә» дип олылап дәшәләр. Элек татар мәктәп-мәдрәсәләрендә эшләүче хәлфәләр, мөгаллимнәр, укытучыларның хезмәтенә билгеләнә торган айлык-мәгаш (хезмәт өчен акча) булмаган. Хәлфәләрнең айлык эш хаклары атнага бер мәртәбә пәнҗешәмбе көн шәкертләр алып килә торган хәер садакадан гыйбарәт була. Атналык садака ике тиеннән алып биш тиенгә кадәр кабул кылынган ягъни бер атналык керем бер сумга да тулып бетмәгән. Әлбәттә, садакага гына тереклек итү мөмкин булмаган. Шул сәбәпле хәлфәлеккә яки мөгаллимлеккә бай мулла балалары гына алынган. Аларның киләчәккә булган хыяллары күп очракта берәр татар авылындагы карт мулланың үлүен, андагы муллалык яки мәзинлек вазифасын көтеп ятуда иде. Шулай да надан мишәр гаиләсендә туып, фәкыйрь крәстиян баласы була торып, Тайсуган мәдрәсәсе кебек татар дөньясында мәгълүм булган бер урында, хәлфәлек дәрәҗәсенә күтәрелү Талип өчен бик зур уңышлык, абруй икәнлеген ул бик яхшы аңлый, үзенә борын чөяргә ярамаганлыгын да ачык белә...

ӘЛМӘТ БАЗАРЫ

Бу вакытта Бөгелмә аркылы үтә торган Сембер-Уфа тимер юлы корылмаган, әле проекты да төзелмәгән. Казан, Уфа, Самара шәһәрләре уртасында хасил булган зур авыл хуҗалыгы массивы, шул өч губерна керә торган өязләрдә авыл хуҗалыгы җитешереп бирә торган азык-төлеккә бик бай була. Зур сәүдә юллары булмау сәбәпле аларны арзан бәягә сатып алырга мөмкин була. Икмәк, ат, сыер, сарык, тире, йомырка, җон, сары һәм ак май шикелле нәрсәләр бик күп һәм арзан сатылалар. Янәшәдә тимер юл булмагач, Кама елгасы буена утырган Чистай, Алабуга, Чаллы кебек төбәкләрдә җәйге чорда су юлы белән ризык сатуга керешәләр. Кыш көне елгалар боз булып каткач бу эшләр туктап кала. Менә шундый шартларда Тайсуганнан ерак булмаган базарлы Яңа Әлмәт (бүгенге шәһәр) авылы икътисади яктан үсеп китә. Якын тирәдәге авыллар, волостьлар өчен эчке базар ролен уйный. Әлмәт базары әтрафтагы (тирә як тараф) башка авыл базарларыннан һәммәсеннән зур булып, төрле яктан килгән сәүдәгәрләр дә бик күп була. Товар-акча мөнәсәбәтләренең үсүе белән татарларның үзләренең яшь татар буржуазиясе үсеп чыга. Әлмәтнең үзендә Исхак хаҗи Ильясов, Минзәлә өязендәге Яхшыбай авылыннан Мортаза Мусиннар, Теләнче-Тамактан Хәлфиннар, Нөркәй тегермәнчесе Гали байлар, Алабуга миллионеры Стахеевлар һәм башкалар шул тирәдә даны таралган эре байларга әйләнеп, зур капитал туплап, шундагы базарларны үз кулларында тоталар.

Әлмәт базары һәр атнада бер мәртәбә булып, сишәмбе көн төш вакытында башланып, чәршәмбе көн кичкырын тәмам була. Шул кыска вакыт

эчендә Яңа Әлмәт мәхшәр кебек бер кайнап, диңгез кебек дулкынланып, шаулап ала. Бу көннәрдә ике мәхәлләлек Әлмәт авылы «кунак» белән тулган, һәр хуҗалык сәүдәгәрләргә урын биреп 2–3 сум эшләп кала. Исхак хаҗи йорты һәм Һади Атласиның таш мәчете алдындагы мәйданда базар туплана. Талип хәлфә булганнан бирле Әлмәт базарыннан калмый. Яңа Әлмәт Тайсуганнан 15 чакрымнар чамасы гына ераклыкта булса да, арбада яки чанада барганда яхшы ат белән ике сәгать барырга кирәк. Еш кына Тайсуганнан кичтән чыгып китеп Әлмәткә барып куналар. Иртән базарга чыгып Исхак хаҗига яки Мортаза хаҗига икмәк төяргә ярдәм итә. Аның вазифасы базардагы икмәкләрнең корылыгын, тазалыгын күреп ярлык бирү, крәстияннәр шул ярлык белән икмәкләрен складка тапшыралар һәм акча алалар. Мортаза хаҗи Талип хәлфәнең шул эше өчен пот башыннан хак түли. Талип һәр базардан 5-6 сум эшләп кайта. Шуның өстенә базар яки ярминкәдән укучылар өчен дәфтәр, китап, кәгазь, конверт, резина-бетергеч, каләмише әйберләрне күпләп алып кайтып файда белән сата. Авыл эчендә була торган үлем-китем кебек керемле хәдисәләр (яңа чыккан хәлләр, сөйләшү мәгънәсендә) дә очрап тора.

Яхшыбай авылы Мортаза хаҗи Әлмәттә агачтан ясалган бик зур икмәк складлары тота. Базар көннәре икмәк җыючы агентлары да бик күп була. Шулар эчендә хуш мөгамәләле, диндар, белемле Талип башкалардан аерылып тора. Тәмәке тартмый, аракы эчми, авызыннан начар сүз чыкмый. Мортаза хаҗи да аны ярата. Һәр базарда яхшы эш хакы түли. Алар әнә шулай дуслашып китәләр. Талип хәлфә Әлмәткә кичтән килгәч тә Мортаза хаҗи янына фатирга төшә, күп вакытта хаҗи аны көтеп ала. Алар бергә ашыйлар, эчәләр, бергә кичке намазларны укыйлар. Намаз укыганда Талип хәлфә имам тора, соңыннан озын итеп Коръән укып бирә. Бу гадәт Талип өчен дә, хаҗи өчен дә бик мәгъкүл (аңлаешлы яки лаеклы) эш була. Мортаза хаҗи Талип хәлфәне күп авыл байлары белән таныштыра, аларга аны исе китеп мактый. Талипның инде кесәсеннән акча өзелеп тормый. Ул инде хәзер үзен генә кайгыртмый, Кармыш авылыннан укучы мишәр балаларын, шулар белән бергә үзенең кечкенә энеләрен үзе янына мәдрәсәгә укырга алып килә. Кармыштагы анасына, бабасына күчтәнәчләр, ярдәм акчалары җибәреп тора. Туганнарының ясакларын түләп ат-сыер алып бирә. Фәхри бабай белән Гамбәр әби Талип уллары өчен биниһая (чиксез) шат, аның белән халык арасында горурланалар.

(Дәвамы бар).

ОКЛЕВЕТАННЫЙ ИМАМ-ХАТЫБ

Р. З. Салиев

Аннотация: *В данной публикации на основе архивных документов я восстанавливаю доброе имя Галяутдина Замалетдинова Гайнуллина, который в начале XX в. был указным муллой села Старая Киреметь нынешнего Аксубаевского района. Жителями села его заслуги были забыты, а он сам незаслуженно оклеветан недоброжелателями.*

Ключевые слова: *Указной мулла, имам-хатыб, прихожане, мечеть, кадимизм, джадидизм.*

Как известно, в начале XX в. в Старой Киремети было два прихода, две мечети, двое мулл. Среди жителей Старой Киремети почему-то распространено мнение, что имам-хатыб 2-й мечети (югары оч мәчете) Галяутдин Замалетдинов Гайнуллин был неграмотным, что он нигде не учился. В деревне также считают, что Галяутдин мулла плохо читал Коран, что его проповеди были скучными и малосодержательными. Вся эта чушь с чьей-то «легкой» руки гуляет и по интернету. Даже уважаемая Команда «Кочующие», пишет: «В деревне было две мечети, двое мулл. Одного звали Замалетдинов Галяутдин, он был неграмотным. Второго звали Ахмеров Хасанжан».

Команда «Кочующие» пишет все правильно, кроме одного утверждения, что Галяутдин мулла был неграмотным. Очевидно, «Кочующим» об этом рассказали жители деревни. Не с потолка же они взяли не совсем верное утверждение? Мне говорят, что жители деревни и Команда «Кочующие» глаголят истину. Советуют почитать, что же об этом пишет уважаемый Салих абый Ахметшин в своих записках.

Признаюсь, у меня нет полной версии записок Салих абыя Ахметшина, есть только часть родословных древ жителей деревни, которые он составил. Поэтому я обратился к Лейле апа Ахметовой, дочери муллы Хасанжана Ахмерова, которая в настоящее время проживает в г. Заинске. Мы же родственники и изредка созваниваемся. Она как будто ждала моего звонка.

Лейла апа:

– Равил туганым, сейчас я надиктую тебе о Галяутдине Замалетдинове из записок Салих абый Ахметшина. Копия записок у меня под рукой.

– Пишу, пишу, Лейла апа, диктуйте.

Лейла апа:

– Салих абый Ахметшин (урыны оҗмахта булсын!) миңа шундый сүзләр язып калдырган: «Хәзерге Ленин урамы белән Тукай яки Вахитов урамы кисешкән җирдә югары оч мәчете урнашкан иде. Бу мәчеттә Җәмалетдинов Галяутдин муллалык итә иде. Үтә кадимче, бер кая да укымаган диләр. Малае Гамалетдин үзләренә җыеп кадимчә балалар укыта иде. Халык сөйләүләре буенча бу мулла дөрес кыйраәт буенча укымаган, вәгазе эчтәлексез, сүзгә бай булмаган, аның мәхәлләсеннән күп кешеләр икенче мәхәлләгә күчкәннәр. Мәчете дә иске, кечкенә иде».

– Лейла Апа, ваш отец Хасанжан Ахмеров почему-то об этом не пишет?

– Действительно, мой отец о безграмотности Галяутдина муллы нигде не упоминает, он только пишет, что он его обманул, но без подробностей...

– Лейла апа, обратите внимание, что уважаемый Салих абый Ахметшин пишет: *«Бер кая да укымаган диләр... Халык сөйләүләре буенча»*. Выходит, Салих абый пишет то, что он слышал от кого-то? Выходит, небылица об этом человеке появилась раньше записок Салих абыя Ахметшина. Значит кто-то постарался? Не сорока же на хвосте принесла.

Лейла апа:

– Равиль энем, я могу только повторить, что мой отец писал, что Галяутдин мулла его обманул. Ничек алдаганын әткәй язмаган, ачыклап калдырмаган. Монысын Аллаһы Тәгалә үзе генә белә инде. Салих абый Ахметшин кем сүзен язып калдырганын әйтә алмыйм. Барысы да Ходай кулында...

В моих руках два документа, написанные от имени муллы Галяутдина Замалетдинова.

1-й документ [НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Ед. хр. 7954. Л. 13]. В Казанское Губернское Правленіе Указнаго муллы Чистопольского уезда, Аксубаевской волости деревни Старо Татарской Киремети Галяутдина Зямалетдинова Гайнуллина ***Прошеніе:*** *Имею честь покорнейше просить Губернское Правленіе благоволить прислать мне копию со списка самостоятельных домохозяевъ прихожанъ ввереннаго мнъ 2-го прихода соборной мечети, дабы я знал в случае встретившейся необходимости кто именно из домохозяевъ состоятъ прихожанами къ оказанной 2-й соборной мечети и кто не состоитъ, так какъ таковыхъ списковъ нетъ и въ 1-й соборной мечети, то у нас между нами муллами происходятъ нежелательные недоразумения, по получении же списка недоразумений уже быть не можетъ. На что и буду ожидать распоряжения. Января 30 дня 1910г.. Указной мулла Галяутдинъ Зямалетдиновъ Гайнуллинъ».*

Согласитесь, что документ читается хорошо. Суть вопроса мулла Галяутдин Замалетдинов изложил кратко и вполне доходчиво. Он просит Губернское правление, чтобы ему прислали копию списка прихожан, относя-

щихся ко 2-й соборной мечети, которой он руководит. Так как из-за этого списка между Хасанжаном Ахмеровым (имам-хатыб 1-й соборной мечети) и Галяутдином Замалетдиновым (имам-хатып 2-й соборной мечети) происходили стычки за прихожан. Мулла Галяутдин Замалетдинов не сгущает краски, он эти стычки называет недоразумениями. Примерно через месяц мулла Галяутдин Замалетдинов на свое прошение получает ответ.

2-й документ [НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Ед. хр. 7954. Л. 25]. Привожу полностью содержание и этого документа. *«1911 г. января 27 дня я нижеподписавшийся указной мулла 2-й мечети, дер. Стар. Татарск. Киремети, Аксубаевской волости Чистопольскаго уезда Галяутдинъ Замалетдиновъ Гайнуллинъ выдалъ настоящую расписку Приставу 3 стана Чистополь уезда в томъ, что присланный при порученіе Казанскаго Губернскаго Правленія от 13 января за № 138 спискоъ прихожанъ 1-й соборной мечети, желающихъ образовать изъ себя новый самостоятельный второй приходъ... Сего числа предъявленъ в томъ и подписуюсь. Галяутдинъ Гайнуллинъ».*

Как видим, 27 января 1911 г. мулла Галяутдин Замалетдинов пишет расписку о том, что он получил копию списка прихожан 1-й мечети, желающих образовать новый приход.

Имеется ещё и 3-й документ [НА РТ. Ф.2, Оп.2. Ед.хр. 8373. Л.10], который на многое прольёт свет… *«Приговоръ 1907 г. февраля 26 дня, мы, нижеподписавшиеся Казанской губерніи, Чистопольскаго уъзда, Аксубаевской волости Старотатарскаго Киреметскаго сельского общества, прихожане 1 мечети въ числе 81 человекъ и 288 наличныхъ мужскаго пола душ, бывъ сего числа въ общем собраніи в присутствіи местных нашихъ: Волостного Старшины Егора Петрова и Сельскаго Старосты Нурулгаты Губайдуллина имели сужденіе о томъ, что по приговору нашему явленному къ, свидетельству въ местномъ Волостномъ Правленіе 4 декабря 1906 г. и записанному въ книгу приговоров подъ № 30, решено образовать нами изъ себя отдельный самостоятельный 2-й приходъ съ постройкой новой мечети, почему намъ необходимо для, вновь образуемого прихода избрать кого либо муллою, что въ нашемъ обществе имеется однодеревенецъ Галяутдинъ Зямалетдиновъ хорошо свъдущий въ правилахъ и обрядахъ магометанской религии и что Зямалетдиновъ на занятие должности муллы въ образуемомъ нами новомъ 2 приходъ изъявилъ свое согласие, а потому мы единогласно постановили: избрать и избрали въ должность муллы ко вновъ образуемому нами приходу одножителя крестьянина Галяутдина Зямалетдинова 43 летъ, которого обязуемся съ семейством его содержать на свой счетъ прилично его званию и при этом удостоверяемъ, что Галяутдинъ Зямалетдиновъ человекъ жизни трезвой, поведения хорошего, под судомъ и следствиемъ не состоялъ и не состоитъ, обряды и бого-*

служения по магометанской религии выполнить в состоянiи. Настоящий приговоръ по доставленiи Зямалетдиновымъ надлежащихъ документов требуемыхъ для утверждения муллою – представить по принадлежности на предметъ утверждения его, Зямалетдинова Губернскимъ Правлениемъ въ званiи, какого онъ удостоится при испытанiи въ духовномъ магометанскомъ собранiи; въ чемъ и подписуемся старшие домохозяйства – входящiе въ составъ вновъ образуемого 2-го магометанского прихода, а именно: 1) Миннихаиръ Гафиятуллинъ, 2) Ибрагимъ Исмагиловъ, 3) Хисамутдинъ Гайнетдиновъ… 80) а за неграмотныхъ поименованныхъ въ семъ приговоръ крестьянъ по ихъ доверии и за себя расписался 81) Хасамутдинъ Гал……иновъ (?)

На сходъ при избирании муллы присутствовали: Волостной Старшина Петровъ. Сельский Староста Нурулгата Губайдуллинъ. (подпись, печать). 1907 г., Марта 10 дня, настоящiй приговоръ къ свидетельству въ Аксубаевском Волостномъ правленiи явленъ и въ книгу приговоровъ Старо-Татарско-Киреметскаго сельскаго общества записанъ под № 5-м. За Волостной Старшина Безруковъ (подпись, печать)».

Внимательно прочитав 3-й документ, я сделал некоторые выводы:

1. Жители с. Старая Татарская Киреметь ещё 4 декабря 1906 г. на сходе вынесли Приговор под № 30. Они решили выделиться из 1-го прихода, где муллой был Х. Ахмеров и образовать из себя новый 2-й приход с постройкой новой 2-й мечети.

2. 26 февраля 1907 г. прихожане 1-го прихода вновь собрались на сход. И, уже опираясь на приговор № 30, решили для вновь образуемого прихода избрать муллу. Как видим из содержания Приговора, муллой 2-й мечети был избран житель села – крестьянин Галяутдин Замалетдинов.

Далее я считаю, что нет необходимости пересказывать содержание этого приговора. Думаю, что пытливый читатель сам разберётся, что к чему. Отмечу только, что прихожане характеризуют Галяутдина Замалетдинова как человека трезвого, поведения хорошего. Самое главное в Приговоре прихожане отмечают, что их будущий мулла в состоянии выполнять обряды и богослужения по магометанской религии.

В НА РТ сохранилось Свидетельство, выданное в 1908 г. Галяутдину Замалетдинову по указу Его Императорскаго Величества въ присутствiи Оренбургскаго Магометанскаго Духовного Собранiя, в котором написано, что ему учинено испытание в знание правил магометанской религии, в котором оказался быть способным имамом и мугалимом. Этот документ имеется в моей книге «История села Старая Киреметь» на С. 151. Не лишним будет, если отмечу, что мулла Г. Замалетдинов в 1909 г. получил свидетельство Чистопольского городского 4-классного училища, где

он успешно выдержал испытание на знание русского языка, установленное для кандидатов на должность сельского муллы. Этот документ также имеется в книге на С. 152.

Изучив все эти документы, мы не можем сказать, что мулла 2-й мечети Галяутдин Замалетдинов был неграмотным, что он нигде не учился. Если мы согласимся с общепринятым утверждением, что он был неграмотным, то это не будет соответствовать действительности. Факты – упрямая вещь. Легендарный имам-хатыб Хасанжан Ахмеров в деревне Старая Татарская Киреметь открыл 1-ю соборную мечеть, два медресе: одно для мальчиков, одно для девочек; открыл новометодную джадитскую школу, библиотеку. В подтверждение этому имеется масса документов, которые имеются в НА РТ и в музее Хасана Туфана на его родине. Смею утверждать, что эти документы ещё до конца не изучены. Никто не покушается на заслуги Х. Ахмерова, они общеизвестны. Скажу даже больше, заслуги Хасанжана Ахмерова ещё недооценены жителями села, педагогической и религиозной общественностью республики. Будучи 72-летним стариком он написал «Истәлекләр» («Воспоминания»). Эти «Воспоминания» стали достоянием общественности благодаря известному писателю Газизу Кашапову и доктору филологических наук Масгуту Гайнетдинову. В подробности этих воспоминаний я вдаваться не буду. Я много писал об этой книге, она настоящее сокровище.

Привожу документ за подписью имам-хатыба Хасанжана Ахмерова адресованный Аксубаевскому Волостному Правлению.

Х. Ахмеров пишет: *«1906 г., февраля 4 дня, я нижепододписавшийся, хатыпъ мечети дер. Старо-Татарской Киремети, Аксубаевской волости, Чистопольскаго уъезда, Хасянзянъ Мухаметзяновъ Ахмеровъ далъ настоящий отзывъ Аксубаевскому Волостному Правленiю въ томъ, что на постройку новой мечети я согласия дать не могу, такъ какъ существующая мечеть не оштукатурена изнутри и на постройку ея прихожане задолжали 550 рублей, въ чемъ и подписуюсь. Хасянзянъ Ахмеровъ» (подпись).*

В тот же день, 4 декабря 1906 г., прихожане 2-й мечети пишут встречное заявление Аксубаевскому Волостному Правлению. Привожу содержание и этого документа: *«1906 г., декабря 4 дня, мы, нижеподписавшиеся, прихожане, образующие новый 2-й приходъ, въ деревнѣ Старо Татарской Киреметь, заявляемъ, что за постройку мечети, существующей теперь, прихожане ея нисколько не должны, так какъ на уплату долга 500 руб. общество нынешней осенью продало 10 десятинъ земли по 50 руб за каждую однодеревенцу своему Ишмухамету Сабитову, что и удостоверяемъ грамотные собственноручнымъ своимъ подписомъ» (подпись).*

Если бы имам-хатыб 2-й мечети села Старая Татарская Киреметь Галяутдин Замалетдинов был неграмотным то, как он умудрился организовать из прихожан 1-й мечети 2-й приход и построить новую 2-ю мечеть? Строительство 2-й мечети в нашем селе – заслуга муллы Галяутдина Замалетдинова и с этим утверждением надо согласиться, документы это подтверждают. По утверждению одного из старожилов Старой Киремети Василия Петровича Кузьмина, 2-я мечеть по своим размерам уступала 1-й мечети.

– Она была больших размеров? – повторно спросил я его.

– По размерам она чуть уступала 1-й мечети, но не красотой, а только по размерам. При советской власти эта мечеть долго пустовала и только после войны её разобрали, – ответил он мне.

Таким образом, в Старой Татарской Киремети сначала был один указной мулла – Хасанжан Ахмеров, чуть позже появился второй указной мулла – Галяутдин Замалетдинов. Думаю, что не все знают, что мулла указной потому, что назначался указом Императора, данным из соответствующего губернского правления…

В своих «Воспоминаниях» («Истәлекләр») имам-хатыб Хасанжан Ахмеров ни словом не обмолвился, что мулла Галяутдин Замалетдинов был неграмотным. А мог бы написать, если бы так было в действительности. Ведь в течение многих лет они читали свои проповеди в мечетях, которые находились «в 2-х шагах» друг от друга, они даже были друзьями…

Прекратились ли недоразумения после получения муллой Галяутдином Замалетдиновым копии списка своих прихожан?

Думаю, что они не прекратились. Мулла Хасанжан Ахмеров стал зачинателем джадидизма – обновления татарской конфессиональной школы в Киреметри. Он впервые в деревне для обучения детей стал применять парты и доски, его ученики изучали географию и историю Ислама с заменой языка преподавания с арабского на татарский. При сохранении платы за обучение от шакирдов, Х. Ахмеров начал привлекать в процесс обучения спонсоров-купцов (Ахмед Хусаинов). В послесловие к «Воспоминаниям» («Иман» нәшрияте, 2004) Валиулла хазрат Якупов пишет: «Эта менеджерская по сути операция проведена была так грамотно, что до сих пор наши ученые, обремененные даже многими учеными званиями и степенми, не могут понять ее сущность». Далее Валиулла хазрат Якупов пишет: «Также понятно, что с потерей финансирования джадидские школы сразу становились обычными, т.е. кадимистскими».

И все же разница между этими школами была: джадисты читали книги по-татарски, кадимисты те же книги читали на языках оригинала, т. е. на арабском и персидском. Очевидно весь сыр-бор между кадимистами

и джадистами заключается в платности системы образования. Как видим из «Воспоминаний» Х. Ахмерова, он умел находить деньги на нужды обучения своих учеников. В то же время мулла Хасанжан Ахмеров нажил и врагов среди прихожан 1-й и 2-й мечети. *«Бездә коммунист мулла бар»*, – диеп аның өстеннән донос була. Об этом он пишет в своих «Воспоминаниях». Также он пишет: *«Мин кара горуһлар тарафыннан динсез дип сүгеләм, яшләр-фәнчеләр тарафыннан – каты динче булуым берлә сүгеләм. Минемчә, дин гыйльме, фән гыйльме – дин-исламның ике баласы. Динчегә фән кирәк, фәнчегә дин кирәк»*.

Хасан Туфан с любовью вспоминал своего первого учителя Х. Ахмерова и прямо указывал, что он сыграл большую роль в его становлении как поэта. *«Давыллы еллар лирикасы» (1970) исемле җыентыгында, «Бәлки шагыйрь булмас та идем» дигән кереш мәкаләсендә Хәсән ага Туфан бу мәсьәләгә аерым туктала. «Соңга таба минем «белем даирәм» тагын да киңәя төште. Безнең авылның мулласы Хәсәнҗан Әхмәров абый мине үз өенә килгәләп, китаплар, газетлар укып йөрергә чакырды... Хәсәнҗан абый безне кояш тирәсендә әйләнүче планеталар һәм Галәмнең төзелеше белән дә аз-маз таныштырды»*.

Как видим, классик татарской поэзии Хасан Туфан оставил очень хороший отзыв о Хасанжане Ахмерове. Прочитав эти строки, становится понятным, откуда берёт начало родник поэзии Туфана…

Х. Ахмеров, нажив много врагов среди своих прихожан и жителей села, в конце-концов вынужден был покинуть навсегда Старую Киреметь.

Заканчивая свои «Воспоминания», он на С. 132 пишет: *«Дус булып бик каты алдаучылар Акбулат мулла Шакирҗан, Чистай техникум директоры Зариф учитель, Кармәт мулласы Галәэтдин Жамаллар булды»*. Автор умалчивает, в чем его обманул мулла Галяутдин Замалетдинов, но отмечает, что он был его другом. Далее он перечисляет жителей села, кто причинил ему зло (их четверо): *«Мин шул дүрт әдәмнән каты хафа булдым? Дөньядан үткән булсалар, Алла гафу кылсын»*.

А что если такая же история приключилась с муллой Галяутдином Замалетдиновым? Могли же его оклеветать враги? Имеется документ – Список лиц, лишенных избирательных прав по селениям Аксубаевской волости Чистопольского кантона, утверждённый постановлением поверочной комиссии от 25 мая 1930 г. [НА РТ. Ф. Р-2777. Оп. 3. Ед. хр. 1. Л. 122]. В этот список попала вся семья Г. Замалетдинова, его жена и трое детей. Так он в возрасте 66 лет стал врагом народа. Его недоброжелатели, очевидно, решили, что теперь о нём можно писать всякую небылицу. Он же враг народа.

92-летняя жительница села Закира Равзутдиновна Губайдуллина говорит: «В это дело вмешалась «политика». В Старой Киремети была группа людей, пораженных завистью, которая «мутила воду», они не жалели слов». Несмотря на почтенный возраст, Закира эби обладает хорошей памятью и строит умозаключения… 90-летний Гали абый Мухутдинов, в течение 20 лет исполнявший обязанности муллы, сказал: «Равиль, ты пиши правду. В твоих руках факты и документы. Правду не спрячешь».

Как же сложилась дальнейшая судьба муллы Г. Замалетдинова, в деревне не знает никто. По документу, который сохранился [НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Ед. хр. 8373. Л. 15, 15 об.], можно установить, что он родом не из Старой Киремети. В этом документе указано, что его мать дочь Камалетдина Манасыпова (Новое Дёмкино), вышла замуж за жителя Старой Киремети в 1891 г., что у неё имеется сын Галяутдин, которому к этому времени исполнилось 28 лет. В отличие от муллы Хасанжана Ахмерова, он нам не оставил своих воспоминаний. Жаль… В любом случае Галяутдин мулла Замалетдинов не был неграмотным, иначе об этом мы узнали бы из «Воспоминаний» Х. Ахмерова. А что он был кадимистом – это же не обвинительный приговор. В конце XIX и начале XX в. большинство мулл были кадимистами. Даже во время учебы Хасанжана Ахмерова в Казани в одном здании уживалось два медресе – джадидским руководил Салихжан хазрат, а кадимистским – Каюм хазрат.

При помощи одного слова – «безграмотный», на человека возвели хулу, а вот для его защиты мне нужны целые страницы. Известно, что оправдание не распространяется так быстро, как клевета. Недоброжелатели муллы Галяутдина Замалетдинова допустили один досадный промах: они не учли, что в НА РТ сохранилось достаточно документов, чтобы восстановить доброе имя одного из мулл нашего села. И вообще, рядом с имам-хатыбом Хасанжаном Ахмеровым вряд ли были неграмотные люди, тем более муллы…

Литература

НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Ед. хр. 7954.

НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Ед. хр. 7954.

НА РТ. Ф. 2, Оп. 2. Ед.хр. 8373.

НА РТ. Ф. Р-2777. Оп. 3. Ед. хр. 1.

НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Ед. хр. 8373.

Салиев Равил. Иске Кармәт авылы тарихы. Казан: «Яз» нәшрияте, 2017.

Әхмәров Хәсәнҗан. И сәлекләр. Казан: «Иман» нәшрияте, 2004.

МӘРҖАНИ ШӘКЕРТЕ БАРУДИ

Ф.К.Дәминова

Без үз тарихыбызны беләбез дә, шул ук вакытта белеп тә бетермибез, аның күпсанлы сорауларына һаман да тиешле җаваплар табылып беткәне юк әле.

Татар халкындагы дини-агарту фикерләренең күп гасырлык тарихы һәм традицияләре бар. Шиһабетдин Мәрҗани дә, Гатаулла Баязитов та, Каюм Насыйри һәм Галимҗан Баруди да, барысы да бер үк чорда диярлек – XIX гасыр ахырында–XX гасыр башында яшәп иҗат иткәннәр. К. Насыйри совет хакимияте елларында шактый, Ш. Мәрҗани – узган гасырның 60 нчы елларыннан соң азмы-күпме өйрәнелгән булса, Г. Баруди һәм Г. Баязитов турында, гомумән, мәгълүматыбыз юк диярлек иде. Тоталитар система шартларында революцион-демократик карашларны гына өйрәнү белән чикләнергә мәҗбүр булдык, ә татар либераль-демократик хәрәкәте вәкилләрен исә, гомумән, «буржуаз милләтчеләр» яки «халык дошманнары» дип атый идек.

Алар һәммәсе дә үз чорлары вәкиле иде һәм заманның коточкыч сынауларын да, рухи фаҗигаләрен дә бөтен халык белән башларыннан кичерделәр, аларның иҗаты – Ватан язмышы, каты авыруларга тарыган милләтебез язмышы, табигый үсеше дорфа көч белән тоткарланган, җимерелгән һәм бозуларга дучар ителгән мәдәниятебез язмышы өчен борчылу иде. Бөтенрусия мөселманнарының 1906 елның августында Түбән Новгородта үткәрелгән өченче, 1917 елның маенда Мәскәүдә узган бишенче корылтайларының мәгариф мәсьәләләренә багышланган карарлары, XX гасыр башында милли мәгарифне, иҗтимагый-сәяси фикерне, иҗтимагый-сәяси хәрәкәтне берләштерүче төп адымнар булды.

Галимҗан Баруди бу корылтайлар эшендә иң актив катнашучыларның берсе иде. Баруди, шәхсән, үзе бәхетле булгандырмы, юктырмы – әйтүе кыен. Кеше буларак, ул ышаныч һәм үкенечне дә, өмет һәм хәсрәтне дә үз башыннан байтак кичергән. Үзе Чимкәнт шәһәрендә чагында, Русия мөселманнарының гомуми корылтаенда мөфти итеп сайлануын белгәч, аны нинди уйлар биләвен дә, 1921 елның салкын декабрь көннәрендә нинди газаплар кичерүен дә без әлегә фараз итә генә алабыз. Аның фикер куәсен дә, кичереш–тойгыларын да, язып калдырган сүзләре аша, иҗаты һәм эшчәнлеге аша аңларга мөмкин. Барудины дин галиме, педагог һәм журналист буларак өйрәнгән этрафлы хезмәтләр киләчәктә булыр әле.

Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиев 1857 елның 2 февралендә туган. Татар дини-иҗтимагый фикер тарихында ул безгә Галимҗан Баруди буларак билгеле.

Барудиның тәхәллүсе гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә «дарылы» дигән мәгънәне аңлата. Соңныннан аның фамилиясе булып киткән «Дары бистәсе» ул туганнан соң шәҗәрәнең төп тармагын тәшкил итә. Галимҗанның әтисе ягыннан бабасы дары заводында хәрби хезмәттә саналган Ибнеәмин ибне Колмөхәммәт тә, булдыклы сәүдәгәрләр рәтендә йөргән әтисе Мөхәммәтҗан да Галиевләр фамилиясе белән билгеле булганнар. Россиянең рәсми кәгазьләрендә мәдрәсә «Мөхәммәдия» дип түгел, нигез салучысы һәм җитәкчесе хөрмәтенә «Галиевләр мәдрәсәсе» дип йөртелгән. Татар җәмәгатьчелеге арасында да, Россиянең күп кенә төбәкләрендә татар телендә чыгып килүче газета-журналларда да бу уку йорты «Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсе» буларак танылган. Бу исемне башкача берничек тә шәрехләргә хаҗәт тумаган. Ул вакытта Ш. Мәрҗани, И. Гаспринский һәм Тукай гына шундый зур абруй казанган булган.

XVIII–XIX гасырлардагы татар галимнәренең күбесе, Урта Азиянең төрки һәм гарәп-фарсы мәдәни мохите белән бәйләнгәнлектән, тәхәллүсләрен дә үзләре туган яки яшәгән төбәк топонимнары белән бәйле рәвештә сайлаганнар. Шулай итеп, Мәрҗани – Мәрҗан авылы, Курсави Курса авылы атамаларын үз исемнәренә кушканнар. Галимҗан Баруди, үзен мәшһүр галим һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) дәвамчысы итеп санаганлыктан, бик күп мәсьәләләрдә күренекле остазның тормыш юлын кабатлаган.

Аның тормыш юлын өйрәнүчеләр Барудиның укуга бик яшьли сәләтле булуын, белемгә дәртен билгеләп үтәләр. Ул телләрне өйрәнүгә күп игътибар иткән: гарәп, фарсы, төрек, уйгур телләрендә иркен сөйләшкән, үзбәк, кыргыз һәм казах телләрен дә ярыйсы гына белгән.

1875 елда аның мөгаллиме Сәләхетдин әфәнде үлеп китә, һәм Галимҗан белемен Бохарада дәвам итәргә карар кыла. Электән килгән традиция буенча, XIX гасырның икенче яртысында Бохара мәдрәсәсе, татарларда бүтән дөньяви уку йортлары булмаганлыктан, аз керемле татар балалары өчен үзенчәлекле «лицейларны» һәм «пансионнарны» алыштырган.

Баруди үзенең «Хәтер китабы»нда: «1875 елда белемемне күтәрү максаты белән Бохарага киттем, анда берничә ел дәвамында дәресләр бирдем. Дөньяви фәннәрдән математиканы өйрәндем», – дип яза. Бохарада алган белемнәреннән канәгать булмыйча, Г. Баруди Һиндстанда, Согуд Гарәбстанында, Мисырда булу турында хыяллана, бу илләрдәге атаклы галимнәр белән очрашу уе белән яши.

Баруди үзенең «Хәтер китабы»нда: «1882 елда Казанга кайттым. Шул ук елның 12 ноябрендә указ алып, Казанның 5 нче Җәмигъ мәчетенә (Ак мәчеткә) икенче имам һәм мөдәррис итеп билгеләндем», – дип яза. «Шул көннән башлап бер-ике шәкерткә дәресләр бирә башладым, укучыларым саны да артканнан-арта барды. Хәзер дә эшләп торган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен оештырдым. 1908 елга кадәр дәресләргә кайбер үзгәрешләр керттем», – дип күрсәтә ул.

Г. Баруди Казанга, Урта Азиядә 7 ел булганнан соң, бик зур уникаль фәнни әдәбият алып кайта. «Заман» календарендагы мәгълүматларга караганда, бу йөкнең авырлыгы кырыклап пот, бәясе 5–6 мең сум тирәсе тәшкил итә. Галимҗан гомер буе китаплар җыю белән шөгыльләнә. Тормышының азагында аның инде борынгы кульязмалардан һәм сирәк китаплардан торган уникаль китапханәсе була.

Төрки-татар тарихы буенча күпсанлы хезмәтләр авторы, галим һәм язучы Габделбарый Баттал-Таймас (1880–1969) үзенең «Галимҗан Баруди» исемле китабында: «Минем Галимҗан хәзрәт белән якыннан танышлыгым аның китапханәсе белән кызыксынудан башланды. Ул тарихи истәлекләргә гаять бай иде», – дип яза. Башка галимнәр дә Барудиның китапханәсе турында шундый фикердә. Һичшиксез, анда борынгы кульязмалар һәм сирәк китаплар байтак була. Хәтта «Кыйсса-Йосыф»ның XVI гасырга караган кульязмасы да саклана. Г. Баруди 1920 елда Татарстан Республикасы карамагына тапшырган күпсанлы мәдәни ядкарьләр арасыннан күренекле галим-археолог Гали Рәхим (1892–1943) Уразмөхәммәтнең мөрите Кадыйр Али бәйнеке дип исәпләнгән һәм 1602 елга караган «Елъязмалар җыентыгы»ның яңа нөсхәсен ачыклый. Ул Баруди башкарган хезмәтләрнең исемлеген төзи һәм аның турында беренче булып язып чыга.

Бу чыганакларның беренче күчермәләре белән үз вакытында Шәрекъ белгечләре И. Хәлфин һәм И. Березинның кызыксынулары мәгълүм. Хәлфин күчермәсеннән аермалы буларак, гәрчә аңа «Бориска (Годуновка) мәдхия» өлеше кертелмәсә дә, Баруди күчермәсе тулырак санала. Күчермә хәзерге вакытта университетның Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең Көнчыгыш бүлегендә саклана. Тикшеренүчеләр фаразлавынча, бу кульязма Касыйм шәһәреннән алып кайтылган. Бәлки ул бик билгеле сәетләр нәселеннән саналган, кызларының берсе Г. Баруди белән никахта торган, Шакуловлар гаиләсенеке булгандыр.

Хәзер Г. Баруди китапханәсенең зур өлеше университет фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә саклана. Шунда ук Г. Барудиның аларны 1920 елның 24 июлендә үз ихтыяры белән шушы китапханәгә тапшыруы турында гаризасы да бар. Ул үз китапханәсен

халыкныкы итәргә хыялланып яшәгән. Бу китапханәдә 4288 китап, 947 кулъязма һәм аннан тыш гарәп телендәге 2274 китап һәм кулъязма саклана. Шуңа өстәмә рәвештә 1923 елда тагын 101 берәмлек китап кайтарылган.

Соңрак, Г.Баруди китапханәсенә зур бәя биреп, академик И.Ю.Крачковский аңа тасвирлама төзи. Бу күренекле шәрыкъ белгече фикеренчә, мөселман кулъязмалары тупланмасының бер өлеше хәзер дә Санкт-Петербург университеты китапханәсенең иң гүзәл хәзинәләреннән санала. Ул Татарстан Республикасының мәгариф ихтыяҗларын гамәлгә ашыручы шәхесләр, галимнәр дөньясын бу хәзинәләр белән тулы күләмдә таныштырырга тиешләр, дип саный.

Күренекле тарихчы-археограф М.Әхмәтҗанов, Ш.Мәрҗани туруннарының берсе әйткән мәгълүматларга таянып: «Ш.Мәрҗани үлгәннән соң, мәрхүмнең васыятен үтәү йөзеннән, аның шәхси китапханәсен өч баласына (улы Борһанетдингә, кызлары Галия белән Хәвага) бүләләр. Бу җитди эш атаклы мөселман хокук белгече җитәкчелегендә башкарыла. Күрәсең, Г.Баруди ул китапларның кайберләрен үзенә дә калдыргандыр. Ул бит инде мәшһүр китап сөючеләрдән санала. Шуңа күрә кайбер кулдан язылган китаплар һәм Ш.Мәрҗани хезмәтләре күчермәләре Г.Баруди мирасы белән бергә фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар фондына килеп эләгә», – дигән кызыклы фактлар китерә.

Бу аның китапка булган мәхәббәтеннән булгандырмы, әллә үзенең остазына ихтирамыннандырмы – ул кадәресе сер булып кала. Әле китерелгән факт, күрәсең, XIX гасыр азагына карыйдыр.

Билгеле булганча, Ш.Мәрҗани 1889 елда вафат була, ә Баруди аның белән соңгы көннәренәчә аралашып тора. Баруди үзе хәбәр иткәнчә, остазын ул соңгы тапкыр аның вафатына ике көн кала күрә.

«Мәктәпләрне һәм мәдрәсәләрне дингә якынайту, тормышчан итү – минем төп максатым. Карты да, яше дә дингә керешеп, бар көчләренә аның мәнфәгатен күздә тотып, гадәт-әхлак хакында кайгыртырга тиеш. Дин – фән түгел, теләсә кайсы фән омтылырга тиешле тәҗрибә», – ди Г.Баруди. Безнең карашыбызча, ул «тәҗрибә» дип әйткәндә, мөселман дине йолаларын берсүзсез һәм тулысынча үтәүне күздә тота. «Башкаларга иярмичә, икейөзлеләнмичә үз фикерен булдыру – һәркемнең бурычы. Ышануның илаһилыгын сакларга кирәк», – ди ул.

Татар җәмәгатьчелегенең кайбер даирәләре төрле үзгәрешләргә, аерым алганда, Баруди «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә керткән һәртөрле яңалыкларга каршы чыга. Жандармерия карашынча, Баруди ул чакта инде иң күренекле 28 панисламистның берсе санала. Казан жандарм идарәсе начальнигының 1907 елның 18 августындагы депешасыннан күренгәнчә,

«...кайбер хәбәрләр буенча, Казан губернасындагы мөселман революцион партиясе гамәлләрендә Казан шәһәренең указлы муллалары Габдулла Апанаев, Салихҗан һәм Галимҗан Галиевләрнең, Казан купецлары Габделхәмит Казаков, Садыйк Галикәев һәм Сөләйман Аитовның, шулай ук Мөхәммәтгаяз Исхаковның да катнашы барлыгы күренә...». Ахыр чиктә: «Мулла Апанаевны, бертуган Галиевләрне һәм купец улы Казаковны, 3 елга Архангельск губернасына сөреп, ачык күзәтү астында тотарга», – дигән резолюция пәйда була.

Күрәсең, Эчке эшләр министры мәсьәләнең асылын бик үк төпченеп тә тормагандыр, губернаторның үз белдеге белән вәкаләтләрен арттыруын да абайламый калгандыр; аның карарын ул, вак-төяк ташламалар ясап, җәза срогын ике елга калдырып, раслап та куя. Сөрген урыны итеп исә Вологда губернасы билгеләнә.

Шушы вакытта Галиевләр гаиләсенә зур кайгы килә: берьюлы ике улы Казаннан сөрелү хәсрәтеннән аталары Мөхәммәтҗан, 1908 елның 31 декабрендә йөрәк өянәгеннән үлеп китә. Бу бәлаләрдән тәмам югалып калган әниләре Фәхерниса император хатыны Александра Федоровнага мөрәҗәгать итеп тә карый. Ләкин бу тырышлыклары бушка гына була. Галимҗанны да, Салихҗанны да азат итмиләр. Дөрес, хакимият, янәсе, миһербанлык күрсәтеп, калган срокны чит илдә үткәрергә рөхсәт бирә.

Баруди үзе: «1908 елда Вологда шәһәренә сөрелдем. Анда 4 ай яшәгәннән соң, Эчке эшләр министрлыгыннан чит илгә чыгарга рөхсәт алдым, Вена, Будапешт шәһәрләрен күрдем, мәшһүр Истанбул, Дәмәшкъ, Бәйрут һәм Триполи калаларында булдым. Уңышлы сәяхәттән соң Казанга кайттым. Имам-хатип һәм мөдәррис дәрәҗәләрем булганга күрә, 1912 елда эшкә керештем», – дип яза.

Чит илләргә сәяхәтеннән кайткач, Баруди бөтен гомерен мәктәптә эшләүгә һәм «Әд-дин вәл-әдәб» («Дин вә әхлак») дигән педагогик журналны нәшер итүгә багышлый. Баруди педагог-галим генә түгел, журналист та. Аның үзе нәшер иткән журналда дөнья күргән юлъязмалары бу сәяхәтнең гадәти хаҗ кылу гына булмавын күрсәтә.

Беренче Бөтенрусия мөселманнарының съезды чакырылыр алдыннан Төркестанга бөтен мөселман даирәсендә абруй казанган булачак мөфти Галимҗан Баруди җитәкчелегендәге делегация җибәрелә. Үзенең анда баруы хакында Баруди: «1917 елда Төркестанда өченче тапкыр булдым. Бу баруымда Ферганәдә, Ташкентта һәм башка шәһәрләрдә революция хакында вәгазьләр укыдым, азатлык турында, олуг фикерләр турында, мәктәп системасын үзгәртеп кору турында фикерләрем белән уртаклаштым. Чимкентта булуым вакытында Россия мөселманнарының Мәскәүдә үткәрелгән гомуми съездында читтән торып мөфти итеп сай-

ландым. 1918 елда, кабаттан сайланып, Беренче Милли Мәҗлес тарафыннан расландым. Дин әһелләренең һәм мөтәвәллиләрнең 1920 елда үткән бу съездында да, үзем каршы килүгә карамастан, халык ихтыяры белән өченче кат сайландым. Илаһи зат юлымны изге эшләргә юнәлтсен», – дип яза.

Дәүләт иҗтимагый структуралары системасында диннең мөһим һәм күренекле урын тотуын исәпкә алып, 1920 елның 26 июлендә ул Мәскәүгә килә һәм Совет хөкүмәтенең милләтләр эше буенча комиссариаты әгъзасы, үзенә туган тиешле Мирсәет Солтангалиев белән очраша.

Г.Баруди аңа Шәрыкъ проблемасының мөселманнар өчен никадәр мөһим булуы һәм анда яшәүче халыклар турында кайгыртуны үзенең изге бурычы итеп санавы турында сөйли. Совет хөкүмәте мөселманнарга булышырга тиеш, ә мөселманнар, үз чиратында, хөкүмәт ихтыяҗларын аңларга бурычлы, ди ул.

Зыялы, эшлекле, ораторлык сәнгатенең нечкәлекләрен белгән, хөкүмәттә югары урын биләп, мөселманнарны чын-чынлап якларга сәләтле булган Мулланур Вахитовның ак чехлар тарафыннан үтерелүе Барудины тирән кайгыга сала. Г.Баруди фикеренчә, мулла Габдулла Апанаевның кызыллар тарафыннан үтерелүе дә зур ялгышлык саналырга тиеш, чөнки мөселманнар киләчәктә Совет хөкүмәтенә файда китерердәй кирәкле кешене югалттылар.

Ул чакта большевиклар Россиянең мөселман халыкларына карата катлаулы да, сыгылмалы да сәясәт үткәрәләр. Төркиянең беренче булып совет Россиясен тануы да тикмәгә түгелдер. Ләкин бу хакимият ныгыган саен дини даирәләргә мөнәсәбәт тә үзгәрә бара. Баруди үзе икърар иткәнчә, аңа Ш.Мәрҗани аеруча зур йогынты ясый. Ул остазы кебек үк дини тәгълиматны һәм мәгарифне үзгәртеп кору белән гомере буе шөгыльләнә. Ш.Мәрҗани һәм Г.Баруди хезмәтләрен чагыштырып карасаң, күп очракта аларның фикерләре тәңгәл булуын күрерсең. Остазының тууына 100 ел тулуга багышлап аның тарафыннан язылган һәм юбилей уңаеннан чыгарылган җыентыктагы ике мәкаләнең эчтәлеге аларның рухы һәм фикер йөртү ягыннан бик якын торулары турында сөйли.

Мәкаләсенең азагында, «Авторның юбилярга мөнәсәбәте» дип исемләнеп, 1908 елның 9 сентябрендә язылган кушымтада, Г.Баруди остазы белән «Назурат-әл-хак» («Хакыйкатькә күзәтү») китабы чыккач танышуын әйтә. Юбилярның аерым китаплары белән танышкач, ул аның белән ешрак очраша башлый. Мәрҗани белән алты ел дәвамында ныклап аралашып, аны барлык сәфәрләрендә озата йөри, рәсми һәм шәхси кабул итүләрдә катнаша. Шуңа күрә Баруди үзен Ш.Мәрҗани хакында

объектив фикер йөртергә хаклы дип саный. Әлеге хезмәтендә Г. Баруди Ш. Мәрҗани хезмәтләренең тулы һәм төгәл исемлеген дә китерә.

Татарларның мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында егермегә якын хезмәт язган урыс галиме Я. Д. Коблов, Г. Барудины күренекле галимнәр рәтенә кертә.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе һәм Татар укытучылар мәктәбе – шул чорның иң мәртәбәле уку йортларыннан булып, татарларны Аурупа мәдәнияте белән таныштыруда зур роль уйный, – дип яза узган гасыр башында тел белгече, тюрколог һәм этнограф Арминий Вамбери (1831–1913). Мәдрәсә Россиядә шулкадәр таныла – бирегә Россиянең төрле төбәкләреннән ел саен 300–400 шәкерт килә башлый. Бу мәдрәсәдә Ф.Әмирхан, Г. Камал, К. Тинчурин, Галимҗан һәм Борһан Шәрәфләр, М. Гафури, С. Сәйдәшев, С. Габәши, М. Укмасый, Х. Ямашев, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт, Б. Урманче, Ә. Исхак һәм башка күренекле шәхесләр белем ала.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсен октябрьгәчә чорның университеты дип атарга мөмкин. Я. Д. Коблов та бу уку йортын атаклы дип атый һәм «югары дәрәҗәле»гә исәпли.

Милли идарә большевиклар тарафыннан куып таратылгач, Г. Баруди идарәнең берничә әгъзасы белән бергә Көнбатыш Себергә китеп бара. 1919 елның мартында Уфа аклар кулына күчкәч, ул яңадан шунда кайта. Ләкин инде 3 апрельдә шәһәрдә яңадан большевиклар хакимлеге башлана.

Г. Баруди соңгы көннәренә кадәр мөфти булып кала. Габделбари Баттал билгеләп үткәнчә, Г. Барудиның абруе Россия мөселманнары арасында гына түгел, чит илләрдә дә зур була. Шуңа күрә большевиклар аны эзәрлекләргә кыймыйлар. Г. Баруди үзенең гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлый, шул юлда кыюлык һәм фидакарьлек күрсәтә.

Менә ул тормышның бер сәхифәсе: 1921 ел. Русиядә коточкыч ачлык. Ил өчен хәлиткеч вакытларда, 4 июньнән 6 июльгә кадәр, Баруди Уфа губернасының аеруча корылыкка дучар булган өязләрен йөреп чыга. Башкортстанның ачлыктан интеккән төбәкләрендә булу нәтиҗәсендә мөфтинең җиде бүлектән торган шәхси хаты языла. Бу гозерләр, урысчага тәрҗемә ителеп, халык комиссарлары Советы рәисе В.Ленинга, милләтләр эше буенча комиссар И. Сталинга, азык-төлек буенча халык комиссары А. Цурюпага һәм Бөтенрусия Үзәк Башкарма комитеты рәисе М. Калининга җибәрелә. Хәзер бу документ Башкортстан Республикасының Үзәк дәүләт архивында саклана.

Бу гозернең үз адресатларына барып җиткәнме-юкмы икәнлеген төгәл генә әйтә алмыйбыз. Бәлки, аның эчтәлеге дәүләт җитәкчеләренә башка юллар белән дә җиткерелгәндер. Законлы сайланган һәм билге-

ле вәкаләтләре булган Г.Барудиның югары даирәдәге җитәкчеләр белән шәхси очрашкан булуы да мөмкин. Аның кара көздән алып декабрь аенача, үзенең Мәскәүдә вафатынача, хөкүмәтнең ачлыктан интегүчеләрнең хәлен җиңеләйтү өчен гадәттән тыш чаралар күрүенә ирешү артыннан йөрүе, соңгы көннәренәчә Мәскәү белән Казан арасында юл таптавы билгеле. Бер нәрсәгә шикләнмәскә мөмкин: бу мөрәҗәгатьне башкалада барыбер ишеткәннәр. Һәрхәлдә, 1921 елның августыннан башлап, Совет хөкүмәте Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Дини идарәсе вәкилләренә Идел буе һәм Урал төбәкләрендә ачлыктан интегүчеләргә ярдәм итәргә комачауламаган. Ни кызганыч, үлем аның үзен дә ачларга ярдәм фонды оештырып йөргән чакта эзләп таба. Әмма аның үлеме турында үзебездә бер некролог та бирелми. Бердәнбер некролог, Г.Баттал – Таймас хәбәр иткәнчә, Парижда урыс телендә басылган «Соңгы хәбәрләр» газетасында, Ф.Туктаров тарафыннан гына языла.

Галимҗан Барудиның кабере Казандагы Татар зиратында Г.Тукай, Х.Ямашев, К.Насыйри, Ш.Мәрҗани җәсәдләре җирләнгән урыннан ерак түгел генә урнашкан. Тагын шунысы да мәгълүм булсын: Казандагы Татар зиратының коймасы Барудиның этисе акчасына тотылган.

Галимҗан Баруди гаҗәеп мәрхәмәтле зат була. Ул: «Мине яхшы яктан искә алсалар, шул җитә. Миллионнарны үзең белән алып китә алмыйсың. Соңгы сыену урыныбыз – өч аршин җир», – дип тә тикмәгә генә әйтмәгәндер.

Г.Баруди – бөтен төрки халыклар тормышына дини һәм мәдәни яктан мәгълүм дәрәҗәдә үзгәрешләр керткән тәэсирле шәхес. Ул педагог, дин галиме, җәмәгать эшлеклесе, журналист була. Журналист буларак, Баруди «Әд-дин вәл-әдәб» журналы ярдәмендә татар укучыларына нык йогынты ясый, аларны яңача, фикерләргә этәрә. Г.Баруди татар җәдитчелегенең иң күренекле вәкилләреннән булып, аның исеме Исмәгыйль Гаспралы, Ризаэтдин Фәхретдин, Һади Максуди, Габдулла Бубый исемнәре белән янәшә тора.

ЯСАВИ: «ВРАГ НАРОДА»

Р.Р. Яушев

Сведения, которые излагаются в настоящей публикации, были получены мною в течении трех лет от Клары Ясавеевны Яушевой (о ней см. ниже). К.Я. Яушева родилась 7 марта 1926 г. Во время моих бесед с ней она рассказала очень много интересного, в том числе показала воспоминания отца, излагаемые в двух рукописных книгах. Недавно она звонила мне, и сообщила, что от руки переписала и хочет передать мне эти рукописи. Как я полагаю, биография Ясави Яушева, прошедшего все круги ада в лагерях, может быть весьма и весьма информативной… В дальнейшем, быть может, какие-то части этих книг удастся опубликовать в журнале «Туган җир»/«Родной край».

Ясави Яушев. Так назвали сына родители. Знали ли они о суфийском поэте и мистике Ходже Ахмете Ясави? Не связан ли он с родом мурз Яушевых? Ясави Яушев родился в 1895 г. в деревне Средняя Сунь Мамадышского района Татарстана в семье крестьян Шигабутдина (1860–1922) и Бибилатифы (1859–1918), учился в деревенском медресе, с детства был приучен к труду, с возрастом овладел множеством навыков, в том числе шитьем, вязанием. Умение делать разнообразную работу спасло ему жизнь на Колыме.

Ясави покинул родной дом в 16 лет и начал работать в иностранной концессии на уральских приисках в Пермской губернии, затем рабочим на строительстве Пермской железной дороги. Началась Первая мировая война. До призыва в армию он вернулся домой и один год помогал отцу в его хозяйстве в качестве хлебороба. В 1915–1918 гг. солдат лейб-гвардии кавалергардского полка, получает боевой опыт и навыки повара, которые ему пригодятся. Ясави, как и подавляющее большинство татар, всей душой принял Октябрьскую революцию. В 1918–1919 гг. стал председателем сельсовета в родной деревне, затем инструктором по организации комитетов бедноты в г. Мамадыше. С 1919 по 1921 гг. участник Гражданской войны – в составе Красной Армии воевал против Врангеля и Махно, член ВКП(б) с 1926 г. С наступлением мирного времени Ясави Яушев короткое время работал учителем в г. Семипалатинске, надо полагать, в татарской школе. Следующие годы связаны с Сибирью. В 1922–28 гг. – сначала рабочий Лензолото (г. Бодайбо), затем руководитель лесозаготовок в Бодайбо, инструктор ВКП(б) (г. Бодайбо), секретарь татарской секции окружкома ВКП(б) в г. Томске. После учебы в Татарском коммунистическом университете Ясави Яушев работал ответственным редактором

газет «Динсезләр» (Безбожники, Казань), «Коммунизм» (Дрожжаное), заведующим РОНО (Дрожжаное). Последнее место работы – ответственный редактор газеты «Яңа юл» (Новый путь, г. Буинск). Ясави с женой-красавицей, библиотекарем Хадичей, играли в народном театре, Хадича хорошо пела, Ясави исполнял роли мулл, в те времена отрицательных персонажей. К этому времени у Хадичи и Ясави родились две дочери, ныне здравствующие: Клара (07.03.1926) и Наиля (08.06.1935). В стране начались массовые репрессии.

В конце августа 1937 г. по поручению Сталина в Татарстан прибыл заведующий отделом ЦК КПСС Г.М. Маленков. От руководителей Маленков потребовал очистить республику от террористов, троцкистов, султангалеевцев, бухаринцев и шпионов. Формальным поводом этих преследований была смерть кандидата в члены ВКП(б) Сабиры Сайфутдиновой в марте 1937 г. В связи с выдвинутыми обвинениями, не став скрываться в Средней Азии по совету тестя Магсума, Ясави поехал в Казань искать правду. И «нашел» – через три дня он был арестован. Открытый судебный процесс в Буинске велся Специальной коллегией Верховного суда ТАССР в отношении 21 человека. Это был последний громкий процесс террора 1937 г. Каждый день под конвоем с собаками, как особо опасных преступников, вели подсудимых из КПЗ в клуб. В ходе рассмотрения дел судья по неизвестным причинам был арестован, поэтому протокол судебного заседания остался не подписанным. Решение суда зачитывалось 04.11.1937. Пока судья поочередно приговаривал 14 человек к расстрелу (приговор был спешно исполнен через 15 дней в Казани), адвокат Тагиров успел сообщить Ясави: *«Озынны көт»* (дословно с татарского «Большой [срок] жди»). Ему дали 15 лет тюремного заключения с поражением в правах на 5 лет как «участнику вредительской организации и за создание условий для теракта над кандидатом в члены ВКП(б)»). Судьба 6 человек неизвестна.

Супруга Хадича, не надеясь увидеть мужа живым, через два года вышла замуж за односельчанина. Сделаем небольшое отступление. Его дочь, Клара Ясовеевна Ахметзянова, проживает ныне в г. Альметьевске. Она 11-летним ребенком вместе с Магсум бабаем (приемный отец матери, о нем не знали в НКВД) воочию видела судилище над отцом (мать на суд не пустили), в одночасье превратились с сестрой в дочерей врага народа. Обе дочери продолжали горячо любить отца, Наиля, выйдя замуж, даже не стала менять фамилию. После суда Клара была вынуждена переехать к Магсум бабаю в д. Туктарово-Урдала Лениногорского района, где она успешно окончила 7 классов и прямиком попала в колхоз. Но в дальнейшем судьба ей благоволила. Ее, школьную учительницу, перево-

дят бухгалтером в Шугурово в РОНО и та забирает Клару секретарем. С 1942 по 1947 г. Клара работает Азнакаевском исполкоме, руководство которого «не замечает» что она дочь врага народа, к ней сослуживцы уважительно обращаются «кызым», «иптәш Яушева», «сеңлем». Позже в Альметьевске она выходит замуж за Мирзагита Ахметзянова, участника войны, учителя, впоследствии 30 лет руководившего школой рабочей молодежи. Мирзагит тогда еще не был знаком с Ясави, но он с самого начала не верил в виновность тестя.

До отправки в лагеря Ясави в течение года находился в тюрьме в г. Казани. На Колыму плыли морем из Владивостока. Во Владивостоке его ошибочно записали Душевым, поэтому он отстал от татарстанцев и больше никогда их не видел. Посуду для еды не выдавали, пользовались консервными банками, да и те отбирали уголовники. Условия перевозки были чудовищные. При прохождении пролива Лаперуза окна корабля были предусмотрительно задраены, чтобы не попасться на глаза японцам. Из нескольких тысяч арестантов до Сусумана живыми добралось лишь 800 человек. С 1938 по 1952 гг. Ясави отбывал срок в различных лагерях на Колыме. Он попал туда человеком в рассвете сил, а вышел рано постаревшим с подорванным здоровьем стариком. Дальстрой существовал для добычи золота, кобальта и урановой руды. На Колыме многое пришлось пережить. В первое время Ясави занимался строительством новых лагерей. Был случай, когда их построили и каждого 14-го расстреляли. Однажды Ясави послали в 55-градусный мороз за дровами, он сильно обморозился. Приходилось работать в любую погоду на каменоломне, хоронить товарищей. Большинство заключенных были уголовниками, политзаключенным приходилось нести двойной гнет. Условия жизни и питание были чудовищные, нередко на ежедневных перекличках прямо в строю умирали люди. Ужасы рабского труда чередовались передышками: повар, санитар, работник склада, домработник.

Когда Ясави дошел до «ручки», ему повезло стать санитаром в лазарете, он хоронил мертвецов. Но тут пришло указание перевести его на работу в урановую шахту, означавшую смерть через три месяца. Ясави откупился от «повестки» часами. Некоторое время Ясави посчастливилось работать домработником в семье одного из руководителей Дальстроя – Клавдия Георгиевича Егорова. Мы не знаем деталей их взаимоотношений, известно лишь, что в отсутствие посторонних Клавдий Егоров обращался к заключенному уважительно «батя». В 1947 г. пришло время Егоровым переезжать в Москву. Ясави, вопреки воли Егорова, упаковал все его вещи и мебель в собственноручно приготовленную деревянную тару. Жена Егорова (врач) подарила Ясави часы, позже спасшие ему жизнь. После освобождения Ясави приезжал к Егоровым в Москву. Вот что они написали Кларе

после смерти отца: «Узнав о случившемся у Вас горе, мы очень сожалеем и вместе с Вами глубоко скорбим о нашем лучшем друге – дедушке Яше. Он для нас был и остается очень близким человеком, как член нашей семьи». Ясави всегда оставался человеком и интеллигентом, он не использовал в своей речи бранные слова, не повышал голос, единственным его ругательством было «ахмак» (с татарского «дурачок»).

Во время 17-летнего тюремного заключения Ясави, несмотря на запрет, удавалось тайком вести переписку с Кларой, сохранилось 262 письма, они были пронумерованы дочерью для контроля их получения. Во время войны три года не было писем, Клара даже решила, что отец погиб. Также непонятным образом Ясави в 1946 г. умудрился сделать денежный перевод Кларе. Правда, из заключения он вернулся без копейки в кармане. В 1952 г. в нарушение приговора суда его «обрадовали» бессрочной ссылкой в Магадан. В Магадане он устроился поваром в Дом инвалидов. Инвалидом 2-й группы Ясави был освобожден 18.12.1954, на поруки дочери Клары, без права выезда из г. Альметьевска и поселился в доме зятя Мирзагита. В тот же день соседка проявила бдительность и сообщила в милицию о появившимся «враге народа». Раз в месяц приезжал оперуполномоченный Спецкомендатуры МВД из соседнего г. Лениногорска удостовериться в присутствии Ясави. Чувствовалась симпатия и сочувствие оперуполномоченного. Через некоторое время тому нашлось простое объяснение: он оказался кряшеном-татарином из села Васильево родных мест Ясави. Однажды он сказал: «Вы свободны». Ясави, никогда не считавший себя преступником, не сломленный Колымой, коротко ответил: «Я жду большего». Он ждал от государства извинений и реабилитации.

Вскоре наступила хрущевская оттепель и его реабилитировали. Решением бюро Обкома КПСС он был восстановлен в рядах КПСС с сохранением прежнего стажа. Ясави не таил обиды на советскую власть, оставался верен идеалам марксизма-ленинизма. Лишь однажды у него невольно сорвалось: «Немецкие концлагеря бледнеют перед нашими». Несомненно, это были слова колымских друзей, побывавших в немецком плену. Про Сталина говорил, что у того «глаза сзади», часто повторял: «Судьба играет с человеком». Ясави Яушев тайком «писал в стол» воспоминания. О них стало известно только после его смерти. В то время так поступали многие, без всякой надежды, что произведение увидит свет. Воспоминания состоят из двух рукописных книг на татарском языке, каждая объемом по 150 страниц. Ясави вышел на пенсию, любимым делом стало огородничество, выступал с лекциями, несмотря на лагерное прошлое, сумел быстро завоевать авторитет и уважением среди альметьевцев. И скончался он во время партийного собрания 04.10.1963, на котором он выступал с докладом.

Похороны Ясави Яушева стали грандиозным событием для Альметьевска. Собралось большое количество людей, вся улица была заполнена, был выставлен почетный караул, прощались три дня, так хоронили директоров крупных предприятий и руководителей района. За процессией наблюдала изумленная та самая соседка. Мирзагит не упустил случая припомнить соседке ее слова: «Смотри, как хоронят врага народа!». Из письма Александра Кузьмина (г. Балахна) дочери Кларе: *«...Ясави был моим самым близким другом, в заключении жили вместе, делились и горем и радостями. ...Ваш папа был настоящим человеком, честным, справедливым, прошел такую пытку, муку, а остался образцом порядочности и был честен до конца... В заключении смерть ходила за спиной, и вот выжили. А вот дома, когда бы жить, смерть сразила...».*

Во время 17-летнего заключения Ясави приходилось сталкиваться с татарским писателем Суббухом Рафиковым (1913–1971), его имя носит Центральная Заинская библиотека. Уже после его смерти, с 1989 г. по 1998 г., завязалась переписка дочери Клары с известным писателем Ибрагимом Салаховым (1911–1998), автором «Черной Колымы». Сохранились 39 писем. В последнем письме Ибрагим Салахов беспокоится о сохранении имени Ясави Яушева для потомков. В воспоминаниях Ясави подробно описывается шеджерэ рода, начиная от Яуша (сын Ягфар-Япай). Ягфар-Япая звали Ягофер Рахманкулов, а значит отца Ягофера звали Рахманкул, а не Яуш. Тогда кто же Яуш? Известно, что во время следствия в 1937 г. следователи приезжали в деревню Средняя Сунь выяснить, не является ли Ясави потомком мурз Яушевых.

В истории татарского народа известен род мурз Яушевых, ведущий свое происхождение от Яуша. Мурза Яуш был на службе у Ивана Грозного, однако в трагичное для нации время в 1552 г. он стал на сторону защитников Казани, участвовал в боевых действиях в составе отряда мурзы Япанчи, действовавшего вне кольца окружения. Надо принять во внимание, что после революции 1917 г. вплоть до 1960-х потомки дворян, опасаясь репрессий, тщательно скрывали свое происхождение, особенно от детей. Если учесть, что Ясави сделал запись про Яуша в 1955 г., то разумно предположить, что Ясави по отношению к горячо любимой дочери Кларе действовал по тем же мотивам. Но это только предположение, которое надо доказать.

Статью хочется завершить словами из русской народной песни:

«...Судьба играет с человеком,
Она изменчива всегда,
То вознесет его высоко,
То бросит в бездну без стыда».

ОЛЫ НЫРСЫ АВЫЛЫ ТАРИХЫ «ИЗГЕЛӘР»ДӘН БАШЛАНА

Рамилә Нотфуллина

Кабер ташы – тарихның бер чаткысы...

Теләче районы Олы Нырсы, Кече Нырсы һәм Бичер авыллары тарихы янәшәдәге «Изгеләр зиратыннан» башлана. Каберлекләр борыңгы һәм бай шәһәрчек урынына урнашкан, дип фаразлый археолог, тарих фәннәре докторы К.А. Руденко. 2001 елда ул, Татарстан Республикасы Милли музееның Археологик экспедициясе җитәкчесе буларак, бу якларда эзләнү эшләре белән шөгыльләнгән. «Әлеге шәһәрчекнең тулы канлы тормыш алып барган чоры – XI–XII гасырларга карый. Ә Изгеләр зиратындагы иң борыңгы таш – 1357 елда куелган. Бу шәһәрчекнең хәзерге Казан каласы, Иске-Казан урыны белән нык бәйле булуы да бик мөмкин, - дип фикерли галим. Әмма ниндидер сәбәпләр аркасында, бер мәлдә әлеге шәһәрчек җир йөзеннән юкка чыга. Биредә яшәгән халык бәлки башка урыннарга күчеп киткән, яки коточкыч куркыныч авыруга бирешкән, әллә инде яу килеп, янгын чыгарып, көлгә әйләндергәннәрме? Әлегә билгесез». Тик бу урында хәзерге вакытта «Изгеләр зираты» булуы һәм халыкның әлеге зиратны нык хөрмәтләве игътибарга лаек. Олы Нырсы, Бичер һәм Кече Нырсы җирлек халкы гасырлардан-гасырларга, өлкәннәрдән – балаларга «Зөлкатә», «Нырсы суы», «Бичерхан» турындагы бәет-риваятьләрне, «Изгеләр»не зурлавы, зиратта кылынырга тиешле гореф-гадәтләрне саклап килүе куанычлы күренеш.

Әлеге зиратның чикләрен билгеләү өчен кешеләр канау казып, аннан балчыкны зират чигенең эчке ягына үр итеп салып барганнар. Бу чокыр-үрләр зират эченә мал-туар керүдән дә саклану өчен кирәк булган. Үрнең биеклеге берәр метр чамасы булгандыр, тик вакыт үтү белән, ул инде тәбәнәкләнгән. Кешеләргә зират эченә керү уңайлы булу өчен махсус кечкенә капка эшләнгән, олы арба белән керү мөмкинлеге дә бар – зур капка ясалган. Хәзерге вакытта «Изгеләр зираты» тайга урманын хәтерләтә. Биредә йөзъеллык имәннәр, ап-ак каеннар, тубыл, юкә, чыршы, нарат агачлары шаулап үсеп утыра. Төрле кош-кортлар, көртлекләр, урман тавыклары, ябалаклар, тукраннар, урман чыпчыклары, сандугачлар, саесканнар, козгыннар, каргалар биләгән бу тыныч урынны. Шулай ук, төрле күбәләкләр, бөҗәкләр, керпеләр, еланнар, куяннар да хәтта бар диләр монда. Әлеге урынга бәйле күп төрле бәетләр язылган, риваятьләр сөйләнелгән.

Тарихи вакыйгаларга күз салсак, бу чорда Алтын Урдада тәхет өчен сугышлар башланудан файдаланып, русларның Болгарга хөҗүм итүләре билгеле. Алтын Урдадагы чуалчыклык көннәрендә – 1359 һәм 1398 еллар арасында – руслар Болгар иленә ун тапкыр яу чапкан. Болгар вилайәте халкының бу дәвердәге төп дошманнары «ушкуйник» дип йөртелгән Новгород башкисәрләре һәм Мәскәу кнәзләре булган. [Баттал Г. Казан төркиләре. Тарихи язмалар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1996. – 192 б.] Русларның бу хөҗүмнәрдәге төп максаты – бай Болгар вилайәте җирләрен бөтенләе белән кулга төшерү була. Бу каберләрдә җирләнгән кешеләр, бәлки, шушы сугышларда катнашкан шәхесләрдер. Чөнки биредә 1357, 1399 еллар дип уеп язылган кабер ташларының булуы билгеле. Тик шунысын искәртергә кирәк, әлеге зираттагы күп кенә каберләр хәзерге вакытта инде җир белән тигезләнгән, урыннары билгесез...

«Изгеләр зиратындагы» кабер ташларының затлы, кыйммәтле булуы күзгә күренеп тора. Коръән сүзләре сугарылган ак ташлар – күмелгән кешеләрнең дини булуын искәртә. Бу кабер ташларына охшаш олы, зәвыкъ белән эшләнгән ташлар борыңгы гасырларда хакимнәргә, мирза-бәкләргә, дини башлыкларга гына куелган. Димәк, биредә олы хөрмәт белән җирләнгән кешеләр, бәлки, җәмгыятьнең феодаль катлам вәкилләредер. Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов бу фикерне раслый. Галим билгеләвенчә, әлеге зираттагы ташларда искә алынган мәрхүмнәрнең исемнәре Казан ханы Сәхиб-Гәрәй хан тарафыннан 1523 елның 3 гыйнварында тарханлык ярлыгы бирелгән затларның исемнәре белән туры килә. Шуңа өстәп, янәшә торган ике таш бер нәселнең буыннары вәкилләренә куелганнар. Ярлыкта әлеге нәселнең ничә буыннар заманында ханнар ярлыгы буенча тарханлык катлавына кертелгәннәре күренә [Зыятдинов А., Әхмәтҗанов М. Галимнәр сәяхәте//Шәһри Казан. – 17.01.2014]. Сәхип Гәрәй хан ярлыгында: «Минем сүзем шул: – бу Мөхәммәд углы Шәйех Әхмәт, дәхи Шәйех Әхмәтнең углы Әбдал, дәхи Сәет Әхмәт, энесе Мөхәммәднең углы Муса, Сәет углы Якуб, энесе Буланс(ы), дәхи энесе Нурсәет – шушы җиде кеше Борыңгы хан агаларыбыздан бирле тархан кешеләр икән. Без, дәхи бүләк итеп, бу сөйләнгән кешеләрне тәңре тәгалә ризасы һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәфәгате өчен тархан кылдым...», – диелгән. Биредә өч буынның нәсел чылбыры санала. Бу чылбыр буенча алар якынча 1440–1520 нче елларда яшәгәннәр.

«Олы Нырсының изгеләр зиратында сакланучы ике борынгы каберне һәм аларның ташбилгеләрен безгә дә барып күрергә туры килде, – дип язалар А.Зыятдинов һәм М.Әхмәтҗанов. – Ташларның беренчесе һиҗри 847, милади 1443 елның июнь аенда вафат булган Йосыф Шәйех углы кабере өстенә куелган. Ташның үлчәме 20×59×110 см. Ташбилгегә гарәп һәм та-

тар телләрендәге язмалар уеп язылган. Ташбилгенең тимпан дип аталган өске йөзлегендә алтыпочмаклык – Давыт йолдызы уеп ясалган. Ташның түбәсендә «җан кошы» өчен су җыела торган уенты да уелган. Ташбилгедәге ун юлның алты юлы гарәп телендә, ул Коръән аятьләреннән һәм хәдис үрнәкләреннән гыйбарәт. Калган дүрт юлдагы текст татар телендә:

«...Тарих сәкиз йөз кырык йитидә, сәфәр айының горрәсендә (календаренда – М.Ә.) ирди, Йосыф ибне Шәйех дарел-фанадин дарел-бакайа рихләт кыйлды. Гафир (гафу итүче) Аллаһ ля вә ля-вәлядин» (тудыручыларны – М.Ә.).

Шушы типтагы ташбилге әлеге зиратта 1472 елның 6 декабрендә вафат булган Мөхәммәд углы Әйүб кабере өстендә дә сакланган. Бу ике таш янәшә тора, алар бер нәселнең буыннары вәкилләренә куелганнар», – дип билгели галимнәр. Әлеге каберлекләр «Изгеләр зираты» эчендә махсус аерым тимер рәшәткә белән уратып алынган.

Әлеге зират янәшәсендә ялгыз каберлек тә бар. XIV гасырда куелган әлеге ташка борынгы болгар телендә уелып язылган. Кабер өстендә бик карт имән агачы үсеп утыра. Элекке заманда авыл каберлекләренә үз кешеләреннән башкаларны, читтән килгән кешеләрне, мөселман булсалар да, җирләмәгәннәр, аларны, үлә калсалар, читтәрәк күмгәннәр. Галим Һарун Йосыпов та шуны ассызыклап әйтә. Әлеге ялгыз кабер ташы Нырсы, Бичер кешесенеке булмавы да бик мөмкин, димәк.

Бу кабер ташлары ул чорларның язма мәдәнияте, ташка уеп язу осталары мәктәбенең нык үсеше күрсәткече булып тора. Татар эпиграфик истәлекләрне өйрәнүче галимнәр моны кат-кат раслый. Казан архиепископы Григорий кушуы буенча 1848 елда миссионер, көнчыгыш илләрен өйрәнүче галим Н.И.Ильминский Казан губернасының татар авыллары буенча сәяхәткә чыга. Татар-мөселманнарының яшәү рәвешен, динен тикшерә ул. Бу төбәктәге эпиграфик кабер ташларын тарихта беренче булып ул исәпкә ала. Нырсы авылы янәшәсендә берничә каберлек булуын һәм аның болгар чорына туры килүен дә әйтеп уза.

XIX нчы гасыр ахырында рус археологы С.М.Шпилевский археология фәне өлкәсендә зур эшләр алып бара: Казан төбәгендә йөздән артык кабер ташы исәпкә алына һәм шуларның 18 русчага тәрҗемә ителә. 1877 елда Шпилевский археологларның IV нче съездында әлеге хезмәтен тәкьдим итә һәм китап итеп бастыра. Анда Бичер һәм Нырсы авыллары арасында булган зират тарихи чыганакларда беренче мәртәбә «Зөлката» исеме белән атала.

«...7. Два кладбища близ деревни Бичуриной. Эта деревня, иначе называемая Мал. Меретяки, находится на правом берегу Нырсы, притока Меши с левой стороны.

Н.И. Ильминский указывает влево от дороги в Бичурино изъ с. Карабаянъ, находящегося на противоположном берегу Нырсы, верст. въ 4 отъ д. Бичуриной, небольшое огороженное старое кладбище, съ несколькими старыми березами, изъ которых иныя упали отъ ветхости и гниют ни кем не тронутыя.

Это место называется Золката...» [Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. – Лейпциг, Казань, в университетскй типографии, 1877. – С. 399].

Зөлхи ата эзләре...

Теләче районы Олы Нырсы һәм Бичер авыллары арасында урнашкан борыңгы мөселман зираты «Зөлката» исемен йөртә. Зөлката – Зөлхи ата, Зөлмөхәммәт исемле тарихи шәхес, XVII нче гасырда яшәгән. Аны Зөлкә ата, Чүлкә ата дип тә йөрткәннәр. Тәтеш-Буа тирәләрендә яшәгән Багдан Чеменеев исемле морзаның улы булуы билгеле аның. Галим М. Әхмәтҗанов «Урыс документларында 1602–1603 елларда Богдан Чеменеевның йомышлы татар», булуын әйтә. Аның җир биләмәләре хәзерге Балык бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылыннан ерак булмаган «Большой (?)» (бәлки Олы Нырсы) дигән урынны биләгән. [Әхмәтҗанов М. Нугай урдасы: татар халкның тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф нәшр., 2002. - 343 б.]. Республика районнарының район-авылларының географик картасын карасак, Балык бистәсе районы Тәберде Чаллы авылыннан Теләче районы Олы Нырсы авылының бик ерак урнашмавы күренә. Бәлки Нырсы җирлекләрендә Зөлмөхәммәтнең нәсел җепләре саклангандыр, ата-анасы биредә күмелгәндер? Кайбер риваятьләргә караганда, *«Изгеләр зиратында» Зөлмөхәммәтнең өч кызы ята. Олы Нырсы, Кече Нырсы һәм Бичер авылы халкы Сәгыйдәбану, Шәһидәбану, Захидәбану исемле Зөлхи ата кызларына багышлап бүген дә дога кыла. Олы Нырсы җирлекләренә ул вакытта зур яу килә, имеш. Авыл халкына ярдәмгә гаиләсе белән Зөлхи ата килеп төшә. Кайбер риваятьләрдә Зөлката Бохара шәһәреннән килде дип бәян ителә. Көтмәгәндә, таң вакытында басурманнар авылга басып керә һәм каты бәрелешләр башлана. Зөлхи атанын өч кызы иртәнге намаз укыган вакытта бер кылычтан үткәрелә. Бу хәлләргә ярсыган ата авыл һәм тирә – якта яшәүче ир-атларны җыеп зур көрәшкә күтәрелә. Сугыш канлы һәм аяусыз була. Нырсуар елгасы кан булып ага. Изге җаннарны бик зурлап Изгеләр зиратына күмәләр,* – дип сөйли иде Олы Нырсы авылында туып-үскән, гомер буе тормыш иткән әбием Сәлимә Гыйльметдинова.

Зөлхи ата әлеге вакыйгадан соң, моннан күчеп китәргә карар кыла. Бу чорда, XVII гасырның икенче яртысында – йомышлы татарлар Кама елгасының сул як ярларына аяк баса һәм әүвәлге Нугай Урдасы билә-

гән мәйданнарны үзләштерергә керешә. Зөлмөхәммәт үзе хәзерге Әлки районы Яңа Чаллы авылына нигез сала. Аның биредә кабере дә бар. Юрматы шәҗәрәсендә «Чулкә ата» кабере янына Шыгәли бине җирләүләре дә искәртелә. «Башкортстанда табылган Юрматы нугайлары шәҗәрәсендә, аларның Зәй, Чишмә, Идел елгалары буйларында Биләр шәһәре тирәләрендә күчеп йөргәндә «Чүлкә ата» кабере янында туктаулары хакында хәбәр сакланган, – ди галим Марсель Әхмәтҗанов. – Шунысы кызыклы, Яңа Чаллы авылына нигез салучылар арасында Алатырь Камкасыннан килгән кенәзь Юнәли Мостафин да була. Идрис Хафизнын шушы нәсел кешесе булуы да бик мөмкин», – дип фаразлый ул. Идрис – Зөлмөхәммәтнең улы. Атаклы суфийчы, көрәзәче, дин белгече, халык медицинасы нигезендә дәвалаучы Идрис хафиз бу. «Хафиз» дип хәдис әһелләренә эчтәлек һәм дәлилләре белән йөз мең хәдисне күңеленә ала алган ятлаучыга әйтелсә дә, Багдад мөселманнары тарафыннан үзләренең лаеклы кешеләрен атый торган бу исем-титулны безнең халкыбыз алып, үзләренең һәрбер олылаган, бөек дип саналган кешеләренә мактаулы исем буларак та кулланган. Халык аны тагын Хәлфә бабай дип тә йөрткән. Аның халыкка аң-белем бирүе, сихәтләндерүе яхшы мәгълүм. Риваятьләрдә Бичер халкының Хәлфә бабайны еш очратуы турында әйтелә. Ул бертуган апа-сеңелләре каберләренә зиярат кылырга килгәндә, Бичер мулласы белән күрешмичә китми. Биредә Идрис хафизка «Шәкерт бабай» дип эндәшкәннәр. Аның килгәнен халык көтеп алган. «Шәкерт бабай» дәваланырга килүчене алдан ук күрә торган булган: «Хәзер ерактан кеше килә, самавырны куийк», – дип каршы алган. Рус миссионеры Мещеряков та Мәшләк төбәгендә Идрис Зөлмөхәммәткә дәваланырга керергә теләүче халыкның меңәрләгән метр чиратка тезелүен күреп гаҗәпкә кала. Бүген аның яшәгән нигезе – Балык бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылы янында һәм Бичер-Нырсы арасындагы Зөлката зираты янәшәсендә урнашкан саф, сихәтле чишмә суларының тылсымы һәркемгә мәгълүм. «Изгеләр зираты» янәшәсендәге өч чишмәнең сулары белән халык бүген дә күз, колак, тән авыруларыннан сихәтләнә. Күрәсең, сихәтләндерүче Идрис хафиз «Алланың рәхмәте белән» әлеге сулар, җиләк-җимешләр белән дәвалаган. Сихәтләнүләре турында исә, беркемгә дә әйтергә кушмаган. Чөнки бу чорда патша хөкүмәте татар халкын төрле юллар белән көчләп, кызыксындырып, ислам диненнән православиегә күчерү сәясәтен алып бара. Ә Идрис хафиз ислам дине юнәлешләренең берсе – суфичылыкка өндәүче булган.

Тарихи чыганакларда Зөлмөхәмәтнең тагын бер улы булуы билгеле. Мәшһүр татар галиме, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» дип аталган биобиблиографик хезмәтендә Зөлмөхәммәд

улы Юныс турында бик аз булса да, мәгълүмат бар. Автор Касыйм бине Ибраһим әл-Казаный (Касыйм шәех) турында сүз алып барганда, Яңа Чаллы авылында яшәүче Юныс бине Зөлмөхәмәдне дә әйтеп уза. «Тәварихы Болгария» китабында бу кешене (Касыйм шәехне) «Казан халкыннан иде, вафаты да Казанда булды. Яңа Чаллы авылында Юныс бине Зөлмөхәммәднең бер мөриде иде, дип әйтелгән», – дип яза [Фәхретдин Р. Асар.1 том. – Казан: Рухият, 2006 ел, 360 б.]. Мөрид – суфичылык юлына баскан, остазының сүзеннән чыкмаска, аның юлын дәвам итәргә сүз биргән мөршиднең укучысы булуын исәпкә алып, без, Зөлмөхәммәд улы Юнысның да, суфый, күпләрнең рухи остазы булуы турында фикерли алабыз. Зөлмөхәммәд, аның уллары Идрис, Юныс – үз чорларының атаклы суфый шәехләре (ислам динендә аксакал, юлбашчы дигәнне аңлата) булганнар ахрысы, ә халык аларны газизләр (изгеләр) дәрәҗәсенә күтәргән.

Изге чишмә сулары

«Изгеләр зираты» янәшәсендә җир куенынннан, үләннәр, ташлар арасыннан юл ярып өч чишмә ага. Аларны җирле халык «Изге чишмәләр» (төгәле – «Изгеләр чишмәләре» – ред.) дип атый. Изге сулы чишмәләр хакында тәүге мәгълүматлар Корьәндә үк бирелә. Халык җир астыннан ургып чыккан саф суны башка, шул су кебек үк чиста, нурлы дөньяның, изгеләргә генә ачык булган галәмнең, оҗмахның бер өлеше дип кабул итә. Чишмәләрнең изгелегенә ишарә булган тагын бер фал – аларның «Изгеләр зиратына» якын булуы. Чишмәнең суына да илахи кодрәт хас. Өч чишмәне сүрәтләгәндә, берсеннән – тән авыруларыннан, икенчесеннән – күз, өченчесеннән – колакка шифалы су чыга. Кешеләргә шифа өләшкән бу сулар риваять кенә түгел. Ни гаҗәп, бердәй көчле басым белән, бер үк туфрактан ургып чыккан әлеге чишмәләрнең су составлары сизелерлек аерыла. Суларының әлеге узенчәлеге тәмендә дә сизелә. Сугыш вакытында дин өчен корбан булган Сәгыйдәбану, Шәхидәбану, Захидәбану исемле Зөлхи ата кызларының күз яшьләре изге чишмә суы булып агадыр...

Элекке заманнардан бер гадәт калган: ниндидер авыр сынаулар үтәсе булса, шул сынауны уңышлы кичерү хакына, хәер-сәдака бирү белән беррәттән, халык Изге чишмәгә килә һәм бу урындагы корылмаларны яңарта, чишмәләрне чистарта, кечкенә инеш аша салынган басманы рәтли, бәдрәфне төзекләндерә. Су ияләренә(?) хәер йөзеннән чишмәгә бакыр, көмеш акчалар салалар. Шушы изге чыганаклардан яклау, юаныч, сихәт табалар. Сәдака итеп элеп калдырган яулык, сөлгеләр, чүмеч, чынаяклар – куаныч кичергән кешеләрнең рәхмәте, баш июе бит болар... Шунда барган кайбер кешеләргә чишмә буенда ниндидер серле чаткылар күренгәли диләр. Су иясеме, әллә шушындагы изгеләрме? Әмма алар

яхшы кешеләргә генә күренә. Начар күңелле кешеләргә күренми, – дип сөйли халык.

1920–30 еллар зилзиләсендә мәчет манаралары егылган, тик халык изге чишмәләрнең юлына тузан кундырмаган. «Торгынлык еллары» изгелек һәм намус белән бәйле бөтен нәрсәне дә инкар иткән, әмма хаҗ гыйбадәтләрен үтәүдән мәхрүм калган аксакаллар, шушы изге урынга килеп күңелләрен паклаганнар, яшьләрне хак юлга өндәгәннәр… Замана нинди генә килсә дә, изге чишмәләрнең саф, пак суы белән күңел аклыгы, халык хәтере, иман да буыннан буынга күчә килгән. Элеккедән үк бу җирләрдә «Изгеләр ашы» уздыра торган булганнар. Бу йола хәтта сугыш вакытында да тукталмый. Әйбер юк чагында тавык кына суйганнар, тора-бара, Коръән укып, Аллаһы-Тәгаләдән саулык-сәламәтлек сорап, тынычлык теләп, сарык чала торган булганнар. Бу көнне зиратта авылның барча кешесе җыела торган булган. Олы буын кешеләре сөйләве буенча, бу көнне алты фляга аш әзерләнгән. Калган ашны әрәм итмичә, авылдагы кешеләргә таратканнар, сарык тиресен сатып, сәдака итеп мәчеткә тапшырганнар, тавык йонын күмеп, чип-чиста итеп калдыра торган булганнар. Бирегә килгән халык шушы чишмә суында пешкән ризыклар белән, учак төтене исе килеп торган ризыклардан авыз итәргә ашыккан. Монда узган изге минутларны һәр кеше бик озак сагынып искә ала. Дус ишләренә күргәннәрне иң күңелле хикмәтле вакыйгалар итеп сөйли. Бер тапкыр бу ризыклардан авыз иткән кешеләр бирегә һичшиксез икенче елга да әйләнеп кайта.

Халыкка файдасы тияр кеше – Изге кеше (хәдис)

«Зөлката» зираты янында урнашкан «Изгеләр чишмәләрен», «Изгеләр зиратын» үз вакытында тәрбияләп, тазартып торучы кеше булган. 60–70 нче елларда Башкортостанның Уфа шәһәреннән Теләче районы Олы Нырсы авылына Нурмөхәммәт Маннанов кайтып урнаша. Лаеклы ялга чыккан Нурмөхәммәт бабай (җирле халык үз итеп аңа шулай эндәшә) килеп төшкәндә «Зөлката» зиратында зур тәртипсезлек була. Агачлар ауган, үтеп керә алмаслык таулык, су аркылы чыгарга басмалар начар булуына ышанасы да килми… Ул шәхеснең изге куллары чишмәгә тагын да күбрәк юл ача. Язгы ташу вакытында суга төшкән пычрак, агач ботаклары, ләм һәм вак ташлардан чишмәләр чистартыла. «Изгеләр зираты» эче картаеп ауган агачлардан арындырыла. Нурмөхәммәт бабай берүзе, беркемнән дә ярдәм сорамыйча, зират тирәли баганалар утыртып, әйләндереп койма тота. Кешеләр биргән хәер-сәдака акчасына ул буяу сатып алып, зиратның киртәләрен буяп чыга. Нырсы урманыннан агач үсентеләре алып төшеп, зират эченә рәт-рәт итеп агачлар утырта. Ул утырткан агачлар бүген дә җеп белән сузып утыртылган кебек. Ни гаҗәп,

үзенә игътибар иткән өчен рәхмәт белдергәндәй, зират көннән-көн матурлана, кошлар сайрый, кыр үрдәкләре очып килә, чишмә сулары ишәя. Авыл халкы Нурмөхәммәт бабайга тирән рәхмәтен белдерә.

Изгеләр чишмәләренең, шушы зиратларның буыннан-буынга күчәчәгенә шик юк безнең.

Дөрестән дә, тәрбияле, тыныч холыклы, дини белемле бу бабай, үтенеч белән килгән һәркемгә ярдәм кулы сузарга ашыккан. «Әйдәгез, балалар, шифасы булсын, әйдәгез. Болай итеп карыйк әле. Аллаһының кодрәте киң», – дип, ярдәм сорап килгән авыруларны өшкерә торган була ул. Көмештәй чиста изгеләр чишмәләренең суы белән авыру кешеләрнең күз, колакларын сыпырып, тәннәрен юдыртып, Аллаһтан аларга тәүфыйк, бәхет, сәламәтлек сорый. Аннан соң, авыруны «Изгеләр зиратына» алып менеп, җиде тапкыр әйләндертә. Зират янында Нурмөхәммәт бабай бәләкәй генә йорт та төзеп куя. Намазлык өстендә гыйбадәт кылу өчен җыйнак кына, бик чиста һәм тыныч урын була ул.

Чыгышы белән Нурмөхәммәт Мәннанов Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авылыннан. Өйләнгән, 5 баласы була (1 кыз, 4 егет). Хәзерге вакытта балалары Мәскәү, Уфа шәһәрләрендә, Төркия якларында яши. Әтисенең дини белемле, Коръән сүрәләрен яттан белүе турында улы Рәшид дә искәртә. «Коръән сүрәләрен укып кына калмыйча, аның мәгънәсен белүе һәм башкаларга да шуның асылын җиткерергә омтылганын хәтерлим, – дип сөйли ул. – Уфада яшәгәндә, дини бәйрәмнәрдә әти еш кына мулла кебек өстәл түрендә догалар укый иде. Бәйрәмгә килгән кунакларга, туганнарга шул догаларның мәгънәсен аңлата иде. Аннан соң, бергә-бергә тәмле ризыклар ашап, тәм-томнар белән күңелле итеп чәй эчә идек», – дип күңел түрендәге хатирәләрне барлый Рәшид Мәннанов. Нурмөхәммәт абый яшь чагында 2–3 класс мәдрәсә тәмамлаган булган. Бу аңа, гомер буе, гарәпчә китапларны аңлап укырга мөмкинлек биргән. – 1962–63 нче елларда без гаиләбез белән пароходка утырып, Балык бистәсенә кайттык. Әти юл буе үзенең иң өстендә авыр тимер рәшәткәләрне күтәреп кайтты. Олы Нырсы зиратындагы каберлекләрне әйләндереп алу өчен иде алар. Хәзер аларның күпме булуын төгәл генә әйтә дә алмыйм. Әмма коймаларның 30–40 тан да ким секциясе булмагандыр. Гаиләбез өчен бу бик зур чыгымнар торса да, әнкәй әтигә карышмас иде». Нурмөхәммәт абыйның олы малае Мәлик та, әтисенең Нырсы зираты белән 1960 еллар башында ук кызыксынуы турында әйтә. Биредә, «Изгеләр зиратында» сугыш корбаннары – татарлар җирләнүе хакында, әлеге урынның нык хөрмәткә лаек булуы турында Нурмөхәммәт абый яхшы белгән. Бу турыда хатынына да җиткергән.

Олы Нырсы, Кече Нырсы, күрше Бичер авыл халкы Нурмөхәммәт бабайны үз итә. Гомер буе Нырсы ипиханәсендә эшләгән Әлфия апа Гәрәева сөйләвенчә, Нурмөхәммәт бабайның яшәгән йорты бик чиста, төзек һәм пөхтә булган. «Авылга кайтып төшүгә, ул һәр көнне эшкә барган сыман «Изгеләр зиратына» юл тота иде. Зират тирәләрен чистартты, яшелләндерде, чишмәләрен тернәкләндерде. Бар көч-кодрәтен, мөмкинлеген Изгеләргә багышлады. Әле күптән түгел генә «Изгеләр зиратына» машина белән барып кайттык. Нурмөхәммәт абыйның зират янәшәсендә төзегән өен төзек, чиста күреп, сөендек. Шәһәр өе кебек матур ул... Андагы кыйммәтле намазлыклар, затлы тәсбихлар, йомшак мендәрчекләр, утырып торырга хәтта уңайлы бүкәннәр куелган... Без, абыстайлар, бүген дә «Изгеләр зиратын тәрбияләгән, чишмәләрен караган Нурмөхәммәт абыйга» дип аның рухына багышлап дога кылабыз», – дип сөйли Әлфия апа. Нурмөхәммәт абый үзенең үткәне турында беркайчан да сөйләмәгән. Өлкәннәр аның тормышында авыр вакыйга булган, шуннан котылу максатыннан азарынып, үзен шушы изге зиратка багышлаган, дигән фикерләр генә бар. Нурмөхәммәт бабайның рухи ныклыгына сокланып кешеләр аны изге дип таныйлар. Бабай вафат булгач (1988 елда), «Изгеләр зиратына» күмик дигән фикер дә әйтелә. Ләкин үзенең васыяте буенча, ул туган авылында күмелә. «Зөлката» зираты авыл советы жире карамагында кала.

Нурмөхәммәт Мәннановның халык өчен кылынган эшләре юкка чыкмый. Чишмәдән су алган һәркем татлы суга гына түгел, зиратка, кабер ташларына, шаулап утырган агачларга карап, шуларны бүләк иткән татар бабаена баш иядер!

Мәктәптә төбәк тарихын куллану

Применение краеведения в школах

МЕТОДИЧЕСКИЕ РЕКОМЕНДАЦИИ ПО СОЗДАНИЮ МУЗЕЯ ИСТОРИИ КАЗАНСКОГО АДМИРАЛТЕЙСТВА И ЖИЗНИ ТАТАРСКОГО НАСЕЛЕНИЯ АДМИРАЛТЕЙСКОЙ СЛОБОДЫ (БИШБАЛТА) МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОГО УЧРЕЖДЕНИЯ «ТАТАРСКАЯ ГИМНАЗИЯ №15» КИРОВСКОГО РАЙОНА Г.КАЗАНИ

К.А. Габбасова,
Д.М. Исхаков,
А.Д. Хайруллина,
Ф.Ф. Харисов

Введение

Кировский район один из самых динамично развивающихся районов г. Казани. Здесь тесно соседствуют прошлое и настоящее: огромный промышленный потенциал, уникальная архитектурное и историко-культурное наследие, богатая многонациональная культура, традиции в области межнационального и межконфессионального общения. Одним из приоритетных направлений в развитии части его территории является проект возрождения Адмиралтейской слободы (Бишбалта), инициаторами которого выступили руководители района. Важную роль в его подготовке и реализации могут сыграть музеи района.

Было бы весьма актуально, в канун 300-летия основания Казанского адмиралтейства и слободы, в 2018 г. открыть музей, посвященный истории Казанского адмиралтейства и слободы адресованный подрастающему поколению – школьникам и гимназистам. Подобный музей, создающийся в Муниципальном общеобразовательном учреждении «Татарская гимназия № 15» Кировского района г. Казани, мог бы стать базовым для проведения работы по формированию исторического мировоззрения детской аудитории, воспитывая у подрастающего поколения чувство патри-

отизма и гордости историей «малой» родины – Адмиралтейской слободы (Бишбалта бистәсе).

Гимназия, расположенная на Мало-Московской улице (бывшая Поперечно-Адмиралтейская, Мало-Кузнецкая) – в сердце Адмиралтейской слободы, органично и теснейшим образом связана со своей средой, местом, в котором расположена. Она, по сути своей, «запрограммирована» на концентрированное выражение окружающей среды, индивидуальности исторического развития. Эта социально-культурная сущность формирует все содержание музея, в т. ч. «идеологию» экспозиции.

Вместе с тем, с учетом ограниченности экспозиционных площадей и профильной направленности данного образовательного учреждения – речь идет о татарской гимназии, следует придерживаться определенных тематических рамок, связанных с историей и культурой татарской части населения Адмиралтейской слободы/Бишбалты.

Предмет экспозиционного исследования

Современная территория Кировского района – одна из старейших частей города Казани. По утверждению археолога А.Х. Халикова, на основании археологических исследований за Казанкой в районе Зилантовой горы, на так называемой Пороховой слободе, зафиксированы остатки пригородных поселков XII в. Село Бишбалта (в переводе с татарского «пять топоров») являлось одним из центров судостроения периода Казанского ханства. О строительстве судов еще в Волжской Булгарии рассказывалось и в русских летописях. После взятия Казани Иваном Грозным в 1552 г. по царскому указу был основан Успенский монастырь на месте первой ставки царя, на которой располагалась Адмиралтейская слобода Казани. Впоследствии из-за разлива реки в 1559 г. обитель была перенесена на верхнее плоскогорье Зилантовой горы (на татарском языке – «Елан тау»). С тех пор монастырь стал называться Зилантовым.

Указом Петра I в 1718 г. было учреждено Казанское адмиралтейство России. Оно предназначалось для строительства, ремонта и длительного хранения речных и морских судов. Выбор Петра I на Казань пал не случайно. Казанские корабелы еще в начале XVIII в. были известны в стране как опытные и знающие свое дело судостроители. В 1718 г. из Казани на Балтику была отправлена эскадра из 5 кораблей, затем 8 судов для Азовского флота. Другим важным фактором основания Адмиралтейства стало обилие в Казанской губернии дубовых и сосновых лесов, столь необходимых при строительстве кораблей.

Петр I 27 мая 1722 г. лично осматривал Адмиралтейство и остался доволен работами, а через несколько дней он на кораблях, построенных в Казани, вышел в морской поход против персидского шаха Гусейна. Это

была крупная судостроительная мануфактура эпохи парусного и гребного флота, просуществовавшая до 1830 г. За указанное время на казанской верфи было построено более 4000 морских судов различных размеров, главным образом, для Каспийского моря, столько же вспомогательных судов к ним и несколько сот речных судов для перевозки корабельного леса.

Указ от 31 января 1718 г. предписывал вице-губернатору Н. А. Кудрявцеву (ум. в 1728 г.) основать близ Казани особое Адмиралтейское поселение [ПСЗ. – Собр.1-е. – СПб., 1830. – Т. 5, № 3149]. В качестве рабочей силы к Адмиралтейству приписали крестьян из окрестных сел, преимущественно татар, чувашей, марийцев. К концу XVIII в. их общая численность превышала 100 тысяч человек. Вскоре около Адмиралтейства выросло поселение – слобода, насчитывавшая до 500 дворов мастеровых верфи и чиновников Адмиралтейской конторы. Вместе со строительством производственных помещений шло строительство жилых домов. С этого времени берет свое начало история Адмиралтейской слободы.

Адмиралтейская слобода с момента своего возникновения постепенно застраивалась, появлялись новые улицы, главная из которых называлась «Адмиралтейская». Все дома в слободе были деревянными. Для слобожан были две церкви: Макарьевская в Бишбалте, построенная в 1712 г., и каменная Екатерининская (Боголюбская), построенная в 1689 г. (В советское время остов этой церкви был разрушен, на этом месте в 1968 г. было возведено здание и общежитие речного техникума [Бикбулатов Р.-Адмиралтейская и Ягодная слободы // Татарстан. – 1996. – № 3. – С. 42]. В 1780 г. была заложена церковь Чудотворца Николая.

На социальную структуру населения Адмиралтейской слободы непосредственное влияние оказывала верфь. Большинство местного населения состояло из работных и мастеровых людей Адмиралтейства и их семей. В составе населения превалировали мужчины. Значительную часть населения слободы составляли военнослужащие: офицеры, солдаты и матросы. Работа жителей на верфи и удаленность от города определяли своеобразие слободы. Так, во время занятия Казани войсками Е. Пугачева в 1774 г., когда суконщики присоединились к повстанцам, в Адмиралтействе организовали им отпор.

После ликвидации Адмиралтейства ситуация в Адмиралтейской слободе резко изменилась. Фактически ее хозяином в XIX–начале XX вв. стал И. И. Алафузов. С его именем связан предпринимательский бум и промышленный расцвет этой территории. На Всемирной

выставке в Париже в 1867 г. кожа и брезентовые изделия его фирмы были удостоены бронзовых медалей. Его изделия были удостоены еще одной бронзовой медали на Филадельфийской промышленной выставке, а сам он был пожалован царем орденом Св.Анны второй степени. 25 июня 1918 г. все предприятия Алафузова были национализированы.

4.	Тимкино	-//-	23	-//-
5.	Сохаев	сл. горные татары	34	…
	Итого:		92	
	Итого по Ногайской дороге		92	
	Из них:			
	служ. татар		49	
	служ. мещеряков		9	
	служ. горных татар		34	
		Сибирская дорога		
1.	Уктеево	сл. татар	24	…
2.	Акпердино	-//-	7	…
3.	Бешелап	-//-	35	…
4.	Деуш	-//-	87	…
5.	Уреш	-//-	49	…
6.	Мрясимово	-//-	66	…
7.	Турна	-//-	25	…
8.	Тюбяк Карагой	-//-	101	…
9.	Табен	-//-	1	…
10.	Конабеково	-//-	6	…
	Итого:	401		
11.	Мостафино	-//-	15	…

12.	Смалянов	-//-	16	…
13.	Кикбаево (Улу Илга)	-//-	10	…
14.	Черлай	-//-	1	…
15.	Табен	-//-	10	…
16.	Искучеково	-//-	1	…
17.	Булатово	-//-	5	…
18.	Ирдечи	-//-	4	…
19.	Мусино	-//-	15	…
	Итого:	77		
20.	Сапарово	-//-	26	…
21.	Лакле Тамак	-//-	13	…
22.	Кузылово	-//-	42	…
23.	Ик	-//-	19	…
24.	Утешево	-//-	15	…
25.	Ялангачево	-//-	59	…
26.	Атгаево	-//-	34	…
27.	Кызылово	-//-	7	…
28.	Аучино	-//-	2	…
	Итого:	217		
29.	Дюскеево	-//-	17	…
30.	Ибраево	-//-	15	…
31.	Аитово	-//-	6	…
32.	Нуреево	-//-	72	…
33.	Дербенево	-//-	4	…
34.	Сапарово	-//-	6	…
35.	Муратово	-//-	4	…
36.	Кукеево	-//-	3	…
37.	Еспаево	-//-	6	…
38.	Арбаш	-//-	49	…
39.	Урекаево	-//-	37	…
	Итого:		219	
	Итого по Сибирской дороге:		914	
	Всего по четырем дорогам		3663	

Из них:	
служ. мещеряков	2185
служ. татар	1418
служ. горных татар	60

Источник: РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Ед. хр. 178. (по старым данным – Ф. 350. Оп. 3. Ед. хр. 5545).

Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар

Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики

ХРОНИКА СОБЫТИЙ

3–5 августа 2018 г. в г. Тобольске Тюменской области прошел XI Международный фестиваль историко-культурного наследия сибирских татар «Искер-жыен», организованный Региональной татарской общественной организацией по Тюменской области «Наследие». В ее рамках 3 августа прошла также XII Всероссийская научно-практическая конференция «Историческая судьба Искера». В мероприятии приняла участие делегация из Татарстана, в том числе от имени Исполкома ВКТ Д. М. Исхаков, доктор исторических наук, гл. редактор журнала «Туган җир/Родной край», А. А. Бурханов, кандидат исторических наук, председатель РОО «Общество татарских краеведов РТ», М. Х. Сагидуллина, референт Исполкома Всемирного конгресса татар, ответственный секретарь журнала «Туган җир/Родной край», Ф. А. Байрамова, кандидат исторических наук, член Союза писателей РТ, лауреат ряда литературных премий, общественный деятель, активистка краеведческого движения, Р. Р. Мингазов, журналист, заведующий отделом газеты «Ватаным Татарстан», Г. А. Валеева, певица, лауреат международных конкурсов, Ф. А. Хабирова, певица, Заслуженный работник культуры РБ (они оба являлись официальными представителями Министерства культуры РТ).

Ученые приняли участие в работе конференции: Д. М. Исхаков в соавторстве с З. А. Тычинских сделал доклад «Присоединение Сибирского ханства к Московскому царству: некоторые недостаточно изученные аспекты», А. А. Бурханов выступил с докладом «Вопросы средневековой истории Сибири в трудах татарского историка и просветителя Хади Атласи (1878-1938)»; Ф. А. Байрамова сделала сообщение ««Һиҗрәт» романында Габдрәшит Ибраһим образы һәм Япония темасы».

В рамках названной конференции была проведена также презентация краеведческого журнала «Туган җир/Родной край».

Представители Исполкома ВКТ вручили участникам Международного фестиваля «Искер-жыен» Благодарственные письма и подарки от имени Всемирного конгресса татар.

Были проведены встречи с сибирско-татарской общественностью и представителями администрации г. Тобольска и Тобольского района.

* * *

Тарих фәннәре кандидаты, язучы, публицист, күренекле җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова Бөтенроссия татар авыллары сабантуе кысаларында Курган өлкәсендәге татар авылларында сәфәрдә булып кайтты. Әлеге җирлектәге татар халкының бүгенге чынбарлык халәте уйланырлык.

КУРГАН ҖИРЕНДӘ КҮРГӘННӘР...

ТАШЛАНДЫК ТАТАР ЗИРАТЫ...

Курган өлкәсенең көньягында, Казахстан чигендә, Звериноголовски дип аталган урыс авылы читендә борынгы татар зираты бар. Аның мәйданы кимендә 8 гектар, зиратта йөзләгән кабер ташы, кайберләре 2 метр биеклектә. Кабер ташлары XVIII–XX гасырларга карый. Казаннан белгечләрнең килеп укуы кирәк. Бу авылда заманында меңләгән татар яшәгән, төбәктә бердәнбер таш мәчетләре булган, аның хәрәбәләре хәзер дә саклана...

ТАШЛАНДЫК ТАТАР МӘЧЕТЕ...

Звериноголовски дип аталган урыс авылының уртасында ташландык татар мәчете басып тора... Аны 1885 елда татар байлары салдырган, ул бу төбәктә бердәнбер таш мәчет булган. Мәчет янында мәдрәсәсе, хәтта обсерваториясе дә булган! Аның урынында башта агач мәчет булган, таш мәчетне салырга озак вакытлар рөхсәт бирмәгәннәр. Татарлар бөтен кварталы белән урамны сатып алганнар, андагы урысларны акча түләп башка урынга күчергәннәр. Соңыннан да бу җир өчен еллар буе судлар булган, татарлар мәчетне сүтәргә ирек бирмәгәннәр. Ул бөтен тирә-якка хезмәт иткән. Революциядән соң мәчетне татарлардан тартып алалар, анда озак еллар буе тегермән була, хәзер исә ташландык хәлдә. Мәчет ишегалдында такта яру (пилорам) урнашкан. Звериноголовскида хәзер мәчет тә юк, татарлар да бик аз. Абдулваһаб исемле бабай әйтте, уразаны берүзем тоттым, башка кеше булмады, диде. Аның өендә ике гает намазы укыла, 10–15 казах килә икән, җомга намазлары юк... Татарларны барларга, исемлеген төзергә, бер җәмәгать-оешма төзергә, дигән фикергә килдек. Шунысын да әйтергә кирәк, узган гасырларда бу авылда танылган татар язучысы, «Таһир-Зөһрә» һәм «Бүз егет» дастаннары авторы Әхмәт Кормаши-Уразаев туып үскән. Шулай ук Диния нәзаратенең унынчы мөфтие Шакир Хиялетдинов та шушы авылдан булган.

КУРГАН ҖИРЕНДӘ КҮРГӘННӘР... КУРГАН ТАТАРЛАРЫ ТАРИХЫ

КУРТАМЫШТА ТАТАР ЭЗЛӘРЕ...

Курган өлкәсенең Куртамыш шәһәрендә дә узган гасырларда татарлар яшәгән. 1916 елда биредә агач мәчет төзелә, татар зираты була. Хәзер зират урынында полиция бинасы, мәчет урынында геройларга стенд тора. 1956 елга кадәр татар мәчетендә клуб була, аннан сүтеп ташлыйлар. Бүгенге көндә шәһәрдә татарлар юк диярлек, аларның күбесе инде урыслашкан. Шәһәрдә бик үзенчәлекле бер бина бар, анда музей урнашкан. Бу йортны Шахрин исемле байлар төзеткән, аларны Калуга ягыннан килгән урыслар, диләр, әмма өйләре гел мишәр-татарларныкы кебек! Шахриннарның берсе революциядән соң үлә, икенчесе репрессия корбаны була. Бу йортны озак еллар хакимият бинасы итеп файдаланалар, аннан музейга бирәләр. Музейның бүгенге директоры Батуев Станислав Владимирович татар мәчете һәм зираты тарихын өйрәнгән кеше, безгә дә бик ярдәм итте. Мин аңа «Степная Атлантида или история ичкинских татар» китабымны бүләк иттем, ул миңа үзенең староверлар турында монографиясен бүләк итте. Алга таба Куртамышта татар тарихын бергәләп өйрәнергә килештек.

Ф. Ә. Бәйрәмова

* * *

КУРГАН ТАТАРЛАРЫ ТАРИХЫ

Бүгенге көндә Курган өлкәсендә унбиш меңнән артык татар яши, алар Курганның үзеннән тыш, Шадрин, Шумиха, Шатров шәһәрләрендә, шулай ук Әлмән, Эчкен (Юлдус), Сафакүл кебек егермеләп татар авылында көн итәләр. Курган төбәгенә элек-электән Себер капкасы, дип караганнар, шуңа күрә биредә яшәүче милләттәшләребезне дә себер татарлары белән бәйләп өйрәнгәннәр. Курган татарларын, нигездә, тел белгечләре өйрәнгән, Фәрит Йосыпов, Флера Баязитова, Дөрия Рамазанова һәм Тел, әдәбият институты галимнәренең алар турында фәнни хезмәтләре бар. Әмма Курган төбәге татарлары тарихы Казан галимнәре тарафыннан бик аз өйрәнелгән, булган материаллар да, нигездә, Паллас, Миллер, Фальк, Рычков кебек башка милләт вәкилләренеке. Бүгенге көндә курган татарлары тарихына кайбер рус һәм башкорт галимнәре игътибар итә башлады, әмма аларның күбесе безнең файдага түгел. Югыйсә, заманында Төрки каһанлыклар, Алтын Урда һәм Себер ханлыклары составында булган курган татарлары тарихы Казан тарафыннан да ныклап өйрәнүгә һәм яктыртылуга лаек бит! Биредә һәр татар авылы диярлек борынгы скиф курганнары һәм шәһәрлекләр янында урнашкан, шул тормышның дәвамчылары булып тора. Курган шәһәре үзе дә 1782 елга кадәр «Царево Горо-

дище», «Царев Курган» дип аталган, һәм XIX гасыр урыс галимнәре анда элек татар патшалары яшәгәнлеген язып калдырган. Курган каласы һәм өлкәсе туграсында да татарлардан калган ике көмеш курган тасвирланган, аларны кара кеш-чәшкеләр аягүрә басып саклап тора...

Язучы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмова, шушы бушлыкны тутыру ниятеннән, менә инде унбиш ел буе курган татарларының төп нигезен тәшкил иткән эчкен татарлары тарихын өйрәнә. Шушы вакыт эчендә ул Курган өлкәсенең күп татар авылларында һәм шәһәрләрендә, архив-музейларында булып, мәктәп-мәчетләрдә халык белән очрашып, алар турында дистәләгән фәнни мәкалә язды. Ә 2013 елда Казанда Фәүзия Бәйрәмованың «Дала Атлантидасы яки эчкен татарлары» дип аталган фәнни-тарихи китабы татар һәм рус телләрендә басылып чыкты һәм Курган өлкәсендә бик тиз таралып бетте. Халыкның дөрес тарихка булган ихтыяҗын күздә тотып, җирле татарларның сорауларын искә алып, автор бу китабының дәвамын язарга ниятләде һәм шушы максаттан янә Курган якларына барып чыкты. Бу юлы Фәүзия Бәйрәмова моңа кадәр өйрәнелмәгән урыннарда булырга тырышты, беренче эш итеп өлкәнең Казахстан чигенә урнашкан Звериноголовски район үзәгенә юл тотты. Аны бу сәфәрендә Курган өлкәсе татарлары конгрессы рәис урынбасары, биредә төбәк тарихы өйрәнүчеләр оешмасы җитәкчесе, эшмәкәр Әхмәдулла хаҗи Хәбибуллин озатып йөрде һәм зур ярдәм күрсәтте.

Звериноголовски авылында хәзер күпчелек урыслар яши, бераз казахлар һәм украиннар да бар, ә татарлар бик аз һәм күбесе инде урыслашкан. Әмма монда бөек татар тарихына шәһәдәтлек биреп торучы ике урын бар, берсе – сигез гектар мәйданны биләгән борынгы татар зираты һәм икенчесе – 1885 елда милләттәшләребез тарафыннан салынган таш мәчет хәрәбәләре... Ә авылның мондый сәер исем белән аталуын җир казыганда бик сәер җанвар башы табылу белән аңлаталар, аны, имеш, Петербургка алып китәләр. Кеше белмәгән бу хайван башы мөгезборынныкы булырга тиеш, чөнки Эчкен елгасы буенда да шундый ук баш табыла, хәзер ул Курган музееның иң борынгы – 30 миллион еллык экспонаты булып санала.

Җирле төрки халыклар Звериноголовски авылын «Баргын» дип йөрткәннәр, ул әле урыс хәрбиләре монда килеп урнашканчы ук барлыкка килгән булырга мөмкин. Кайбер документлардан күренгәнчә, станицаның «Звериная Голова» дип аталган вакытлары да булган, Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләрендә ул «Звериный Галяуский» дип атала. Тубыл елгасы буена урнашкан бу авыл, хәрби крепость буларак, 1743–1752 елларда чик буйларын күчмәннәрдән саклау өчен төзелә. Аңа кадәр бу кирмән Тубыл елгасының сул ярында була, ул урынны даими рәвештә су баскач,

бирегә күчерәләр. Соңыннан бирегә казаклар да китерелә, тора-бара ул станицага әйләнә. Дөрес, казак хәрбиләре арасында да татар-башкортлар була, әмма Звериноголовскиның гөрләп торган татар чоры XIX гасырның икенче яртысына, бистә үзенең хәрби статусын югалткач, бирегә күпләп татар сәүдәгәрләре килеп урнашкач башлана.

Архив материалларыннан күренгәнчә, Звериноголовскида таш мәчет салдыру өчен көрәш озак вакытларга – 1864 елдан 1885 елга кадәр сузыла. Мәчет салырга рөхсәт булмауның сәбәбе – имеш, казак хәрбиләре арасында өч кенә мөселман икән, имеш, бистәдә яшәүче 131 мөселман монда теркәлмәгән, вакытлыча гына көн күрәләр, ә теркәлгән (имевшие оседлость) 168 җан өчен мәчет ачып булмый... Әйе, мәчет ачар өчен ул вакытта торак урынында теркәлгән 200 ир-ат мөселман яшәргә тиеш булган. Күргәнегезчә, бистәдә ул вакытта ук инде өч йөзгә якын мөселман-татар яшәгән, моңа гаилә әгъзаларын да өстәсәң, ул сан меңнән арта. Моннан чыгып, без XIX гасыр урталарында Звериноголовски бистәсендә меңнән артык татар яшәгән, дип әйтә алабыз. Дөрес, татарларның аңа кадәр дә бистәдә агач мәчетләре (молельный дом) була, әмма мөселманнар арткан саен, алар анда гына сыймый башлыйлар. Кайбер мәгълүматлар буенча, монда инде 1826–1852 елларда ук мәчет була, аны татарлар һәм бохаралылар (себер татарларының бер сословиясе) салдыра, әмма моңа документлар табылмады.

Халык саны җитәрлек булганнан соң да татарларга озак вакыт гыйбадәт йортын мәчет итеп салырга рөхсәт бирмиләр, әле сызымына бәйләнәләр, әле янәшәдә яшәүче урысларның өйләрен сәбәп итеп күрсәтәләр. Нәтиҗәдә, татарлар мәчет урынын бөтен урамы белән сатып алып, урысларны зур акчалар түләп башка урынга күчерергә мәҗбүр булалар. Бистә татарларына ярдәмгә Кустанайдан Закирҗан Юнысов, Ибраһим Исмәгыйлев, Чиләбедән Ибраһим Ишмөхәммәтов, Абдуллатыйф Аитовлар килә, бу байлар акча белән дә, документлар белән дә, мәхкәмә эшләрендә дә ярдәм итәләр. Шунысын да әйтергә кирәк, Звериноголовскидагы 46 зур сәүдәгәрнең утыз өче татарлар була, алар бистәдә йөзгә якын кибет тоталар, зур-зур ярминкәләр оештыралар. Таш мәчетне салырга озак еллар рөхсәт булмагач, 2-гильдия купец Ибраһим Исмәгыйлев 1881 елның 26 августында Оренбург губернасы җитәкчелегенә хат яза, татарларның дин тотарга ирек булган урынга күчеп китәргә мөмкин булуларын кисәтә. Бистә икътисадын үз кулларында тоткан татарларның мондый таләбе тәэсир итәме, 1885 елның башында аларга таш мәчет салырга рөхсәт бирелә. Һәм алты айда ике катлы таш мәчет төзелеп тә бетә. Аңа имам итеп янәшәдәге Өчкүл авылыннан Мөхәмметсадыйк Кадыргалиев билгеләнә, ул үзе чыгышы белән Пенза өлкәсенең Аллагул авылын-

нан була. Соңрак, мөселманнар саны арткач, мәчеттә тагы бер имам – Мөхәммәтхафиз Бикбаев эшли башлый.

Халык сөйләве буенча, әле мәчет ачылганчы ук биредә мәктәп-мәдрәсә була, тирә-юньнән көчле галимнәр чакырыла, хәтта обсерватория дә эшләп тора! Татарларның шулай күтәрелеп китүен күрепме, Звериноголовски урыслары, мәчет җире законсыз, дип, аларны судка бирәләр, бу мәхкәмәләр дә озак дәвам итә. Урыс-казак хәрбиләре татарлардан инде эшләп торган мәчет җире өчен бик зур суммада акча таләп итәләр, Оренбург губернасы идарәсе урысларны яклый, акча түләнмәгән очракта, мәчетне сүтәргә боера. Әмма татарлар да бирешми, бу җирләрне вакыф-фонд милке, дип игълан итәләр, урыс-казакларның үзләрен судка бирәләр. Ул вакытта татарлар мәчетне саклап кала алсалар да, революциядән соң аны мөселманнардан тартып алалар, башта анда тегермән ясыйлар, аннан территориясендә бүрәнә яру – пилорам эшлиләр. Бүгенге көндә мәчет хәрәбә хәлендә – түбәсе дә, идәне дә, тәрәзәләре дә юк, бары тик кызыл кирпечтән булган диварлары гына, яралы татар баһадиры кебек, аумыйча, әле һаман киерелеп басып тора... Чиркәү каланчасы белән бер биеклектә булган манара да юк, дүрт почмактагы дүрт гөмбәз дә юк, имам-азанчы да юк, намаз укучы мөселман-татарлар да юк дип әйтергә була...

Звериноголовски татарлары кая киткән соң? Әле бит 1926 елда гына да, халык саны алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, биредә 1072 татар яшәгән, хәзер алар бармак белән генә санарлык, алары да әллә ни активлык күрсәтми! Бу тема бөтенләй өйрәнелмәгән, моңа җавап бирүе дә бик авыр. Татарларның бер өлешен янәшәдәге Кустанай, Курган кебек шәһәрләр йотса, бер өлешен урыс упкыны йоткан. Ә күпчелеге бистә читендәге татар зиратында ята... Зират бик зур – мәйданы кимендә сигез гектар булыр, аны билдән үлән күмеп киткән, сирәк-мирәк агачлар да очрый. Борынгы татар зираты читенә инде казахлар һәм бүгенге татарлар да мәетләрен күмә башлаганнар. Иске зиратта иң тетрәндергәне – рәтрәт басып торган кабер ташлары, алар бик күп, йөзләрчә, ә заманында меңнәрчә булган. Кабер ташларының кайберләре биеклеккә ике метрга хәтле җитә, алар төрки курганнардагы борынгы торатaшларны хәтерләтә, өсләрендәге гарәпчә язулар гына монда мөселманнар ятканны күрсәтә. Бу кабер ташлары әле галимнәр тарафыннан укылмаган, аларның күпчелеге XIX гасырга карый.

Фәүзия Бәйрәмованы тарихи урыннар буенча Звериноголовски районы имам-хатибы Абдулваһаб хәзрәт Зөлкарнәев һәм шушы авыл кешесе, татар тарихы белән кызыксынучы Марат Борһанов озатып йөрде. Аларның әйтүләре буенча, бу борынгы зиратны да, мәчет хәрәбәләрен

дә Уфадан дин әһелләре килеп карап киткән, әмма уртак фикергә килә алмаганнар. Мәчетне торгызырга йөз миллион сум акча кирәк икән, әмма бистәдә ислам динен тотучылар бармак белән генә санарлык. Елына ике гает Абдулваһаб хәзрәтнең өендә укыла, анда 10–15 казах килә икән, җомга намазлары юк, уразаны да хәзрәт берүзе генә тоткан. Дин юк җирдә бәрәкәт тә юк – район үзәге булса да, бистә халкы бик фәкыйрь яши, газ да, юллар да, эш тә юк. Заманында бай кибетләре, ярминкәләре белән гөрләп торган һәм татарлар хисабына чәчәк аткан Звериноголовски бүген үзе дә җан биреп ята... Шушы үлеп яткан урыс авылында да Казаннан «Ватаным Татарстан» һәм «Безнең гәҗит» газеталарын яздырып алдырып яткан Марат Борһанов мөгаен бу төбәкнең соңгы могиканыдыр... Аңа атасы үләр алдыннан, «Улым, бу мәчетне безнең бабайлар салдырган», – дигән, шуннан соң Марат татарча өйрәнә башлаган, сөйләшергә кеше булмагач, Казаннан татарча газеталар яздырып алып, аларны кычкырып укырга тотынган. Фәүзия Бәйрәмова аңа рәхмәт йөзеннән үзенең «Дала Атлантидасы яки эчкен татарлары» китабын бүләк итте, алга таба төбәк тарихын бергәләп өйрәнергә килештеләр.

Узган гасырларда Звериноголовски авылыннан милләтебез тарихында тирән эз калдырган шәхесләр чыкканлыгын да әйтеп китәргә кирәк. Аларның беренчесе – Әхмәт Уразаев-Кормаши (1855–1883), «Бүз егет» һәм «Таһир илә Зөһрә» поэма-дастаннар авторы, болар – Казанда иң күп бастырылган һәм укылган әсәрләр; танылган татар язучысы, драматург һәм педагог Абдулла Әхмәт тә (1905–1976) шушы Звериноголовскидан зур дөньяга аяк атлаган; танылган дин әһеле, Уфа Диния нәзарәтенең унынчы мөфтие Шакир хәзрәт Хыялетдинов та 1890 елның 15 маенда Звериноголовски бистәсендә туа, Троицкидагы «Расулия» һәм Иж-Бубый мәдрәсәләрендә белем ала, Казахстан һәм Ташкент мәчетләрендә имам булып эшли, 1951 елдан алып, 23 ел буена ДУМЕСның баш мөфтие була, 1974 елның 15 июнендә, 85 яшендә вафат була, Уфа шәһәрендә җирләнә. Звериноголовскидан чыккан тагы күп кенә шәхесләр булырга тиеш, әмма алар турында хәзергә өйрәнүче юк. Татарлар кулында борынгы кульязмалар һәм китаплар да барлыгын әйттеләр, Омскидан ниндидер урыс кешесе килеп, зур акчаларга аларны сатып аларга теләгән, әмма халык бирмәгән. Сентябрьдә Звериноголовски татар зиратындагы кабер ташларын өйрәнергә Казаннан, Тел, әдәбият институтыннан галимнәр киләсен әйттеләр, бәлки алар борынгы мирасыбызны барлый алырлар.

Фәүзия Бәйрәмова шулай ук өлкәнең Куртамыш шәһәрендә дә булды. Дөрес, биредә хәзер татарлар юк, әмма узган гасыр башында аларның Куртамышта мәчетләре дә, зиратлары да булган. Болар турында мәгълүматны Фәүзия Бәйрәмова шәһәр музее директоры Станислав Батуевтан

алды, ул бу хакта эзләнүләр алып барган һәм матбугатта язып та чыккан. Аннан күренгәнчә, XIX гасыр башында Куртамышта халыкның 1% татарлар була. Ә Куртамыш үзе, хәрби ныгытма буларак, шул исемдәге елга буенда 1745 елда барлыкка килә. Шунысын да әйтергә кирәк, әле 1862 елларда да бу җирләр барысы да атаклы татар байлары бертуган Сәйдәшевларныкы була. Документлардан күренгәнчә, 1916 елда Куртамышта агач мәчет ачыла, аңа кадәр мәчет булганмы-юкмы – хәзергә билгесез. Куртамышның күренекле татар байлары арасында Әхмәтовлар, Габдрәшитовлар, Ашировлар, Абуталиповлар, Байгузиннар, Әхмәревлар, Агаповлар, Агафуровлар, Зәбировлар, Мусаковлар, Үзбәковлар, Хәсәновлар, Мураевлар була. Егерменче елларда мөселман оешмасы рәсми рәвештә теркәлә, ул утызынчы елларга хәтле эшли, татар байларын төрмәләргә утыртып бетергәч, мәчет тә, оешма да ябыла. Куртамышның соңгы мулласы Яһудин хәзрәт була, язмышы билгесез. Утызынчы елларда мәчет манарасын сүтеп аталар, мәчеттә мәдәният йорты ачалар, ул 1956 елга кадәр клуб булып эшли. Соңыннан мәчетне дә сүтеп ташлыйлар, аның урынына тегү комбинаты төзиләр. Хәзер бу урында геройларга баннер тора. Ә борынгы татар зираты бөтенләй юкка чыккан, аның өстенә йортлар һәм полиция бинасы салганнар.

Бүгенге көндә Куртамыш татарлары тарихы өйрәнелмәгән, милләт өчен истәлекле урыннар аяныч хәлдә. Әлбәттә, монда мәчет тә, татар оешмасы да юк. Музей директоры Станислав Владимирович татарлар тарихы белән кызыксына, ул аны өйрәнүдә һәрьяклап ярдәм итәргә теләк белдерде. Ул үзе дә «Куртамышское старообрядчество (середина XVIII–первая треть XX вв.)» исемле монография авторы, алар Фәүзия Бәйрәмова белән шушы төбәк тарихы турында китапларын бүләк итештеләр, алга таба бергәләп эшләргә килештеләр. Шунысын да әйтергә кирәк, Куртамыш шәһәр музее уникаль архитектура үрнәге булган йортта урнашкан, аны 1914 елда бертуган Шахриннар салдырган булган. Шәрык стилендә челтәрле болдырлар һәм чардаклар белән, гөмбәзләр һәм кечкенә манаралар белән бизәлгән ике катлы бу йорт мишәр-татарларда еш очрый. Кем белә, бәлки бу йортта да татар эзләре сакланып калгандыр...

Фәүзия Бәйрәмова алга таба сәфәрен Курган һәм Шадрин шәһәрләрендә дәвам итте, биредә мәчетләрдә булды, имамнар һәм милли хәрәкәт активистлары белән очрашып сөйләште. Ул шулай ук Курган өлкә китапханәсендә төбәктә татар тарихы белән бәйле язмаларны өйрәнде, архивтан мәчетләр тарихы турында бай мәгълүмат алды. Курганның үзендә милли һәм дини хәрәкәтнең төрле чорлары булды, ул күтәрелеп тә китте, төшнекелек тә кичерде, хәзер исә тагы күтәрелү, яңару сизелә. Шәһәрнең уртасындагы бер җимерек бинаны татарлар үзләренә алып,

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәмендә аны торгызганнар, анда хәзер Курган өлкәсе татарларының мәдәният үзәге урнашкан. Ике катлы бу бинада музей-китапханә өчен дә, тел һәм дин өйрәнү өчен дә, милли түгәрәкләр өчен дә, төбәк тарихын өйрәнүчеләр өчен дә урын җитәрлек, бары тик оештырып эшли белергә генә кирәк. Фәүзия Бәйрәмова болар турында Курган татар конгрессы рәисе Марат Юнысовка әйтте, киңәшләрен бирде, милли үзәк өчен үзенең китапларын бүләк итте.

Моннан тыш Фәүзия Бәйрәмова Шадрин районының Эчкен авылы мәчетендә халык белән очрашып сөйләште, китабының дәвамын язар өчен бай материал туплады. Бу эшлекле, иҗади сәфәрнең соңгы ноктасы булып Әлмән авылы торды, Фәүзия Бәйрәмова анда федераль авыл сабантуена килгән милләттәшләр белән очрашты. Аның Әлмәндә инде беренче генә тапкыр булуы түгел иде, чөнки бу татар авылы да милләтебезгә күп күренекле шәхесләрне биргән төбәк. Әлмәндә танылган дин әһеле, милли сәясәтче Габдрәшит Ибраһимовның әнисе Гафифә абыстай туып үскән, ун яшьлек Габдрәшит үзе дә 1867–1871 елларда Әлмән мәдрәсәсендә белем ала, ул укыган мәдрәсә урынында хәзер музей тора. Шулай ук бу төбәктә танылган морзалар Ибраһим һәм Фазыл Тончачевлар, дин белгече Габделнасыйр Сабит Әлмәни яшәгән, иң борынгы XVI гасыр кулъязма Коръән дә Әлмән авылында табылган. Шагыйрьләр Макс Гатау, рәссам Ким Сафиуллин да шушы төбәктә туып-үскәннәр. Әлмән районы – татарлар оешып, авыл-авыл булып яшәгән борынгы төбәк. Фәүзия Бәйрәмова Әлмән авылы музее директоры Әнвәр Кидрасовка үзенең «Һиҗрәт» китабын бүләк итте, чөнки анда якташлары Габдрәшит Ибраһимовның да тормышы сурәтләнә. Язучы ярдәмендә Әлмән музеенда Габдрәшит Ибраһим белән бәйле хезмәтләр туплана башлады, шулар аша галим яңадан әби-бабалары туфрагына әйләнеп кайтты...

Фәүзия Бәйрәмова, Курган өлкәсенә булган сәфәренә нәтиҗә ясап, болай диде:

– Әйе, Курган төбәге тарихы бик борынгы һәм гаять бай, ә бүгенгесе шактый каршылыклы, биредә милләт булып сакланып калу өчен соңгы көрәш бара. Милләт тоташы белән ташландык зиратка әйләнмәсен өчен, һәрберебезгә аны сакларга бөтен көчебезне, белемебезне, гайрәтебезне һәм малыбызны бирергә кирәк. Нинди авыр елларда да үз акчаларына мәчетләр салдырган, китаплар язган, авыл-шәһәрләрне тоткан каһарман милләттәшләребез кебек, без дә дин-милләт юлында гайрәт белән иҗтиһад итик, көрәшик, бирешмик!

Журналга бу язма «Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге аркылы керде (2018 ел, 18 июль).

Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр.

Информация о краеведческих трудах. Рецензии.

КОТЫПТАН КИЛГӘН ГЫЙЛЕМ НУРЫ

Ф. Ә. Бәйрәмова

Тарихтан билгеле буганча, бүгенге Пенза төбәге заманында Төрки һәм Хәзәр каһанлыклары составында, Болгар һәм Алтын Урда дәүләтләре карамагында булган, хәтта шушы арада, XIV–XV гасырларда, «Мишәр Йорты» – «Мещерский Юрт» (Касыйм ханлыгы) дип аталган мөстәкыйль үз дәүләтчелегендә дә яшәп алган. Пенза төбәгендә мишәр-татарлар яши, заманында алар скиф һәм һун, кыпчак һәм бортас атамаларын йөрткән, төрки телле, мең ел буе ислам динен тоткан халык. Хәзерге Түбән Новгород өлкәсеннән башлап, Рязань, Мордовия, Пенза төбәге тулысынча шушы гаярь мишәрләр кулында булган. Мишәр Йортының төбәк калалары булып Сарыкылыч (хәзерге Саров), Төмән (Темников), Наручат (Наровчат-Нуриҗан-Мохша) торган, шулай ук Юлау (Городище), Золоторевка кебек зур шәһәрләре булганлыгы да билгеле. Алар арасында бигрәк тә Наровчат – Нуриҗан аерылып тора, чөнки ул 1312–1320 елларда Алтын Урданың төньяк үзәге була. Үзбәк хан (Мөхәммәт солтан) үзе дә бу елларда Наровчатта яши, 1312 елда ислам динен Алтын Урданың дәүләт дине буларак, ахрысы, биредә игълан итә.

Үзбәк хан үз тирәсенә дөньяның атаклы галимнәрен, язучы-шагыйрьләрне туплый. Урта гасырлар шагыйре Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре Наровчат шәһәрендә 1337–1339 елларда язылган, дигән фикерләр бар. Фарсы шагыйре Низами поэмасына нигезләп, Котб безнең җирлеккә, татар ханнары тормышына туры килерлек гүзәл әсәр иҗат иткән. «Котб» атамасы шагыйрьнең псевдонимы булырга тиеш, ул безнеңчә «котып», ягъни, төньяк, дигәнне аңлата. Шунысын да әйтергә кирәк, Алтын Урда шагыйрьләре Котб һәм Сәйф Сараиның әсәрләрендә шушы якка гына хас мишәр сүзләрен күп табарга була.

Пенза төбәге элек-электән ханлы һәм данлы, китаплы, динле, мәгърифәтле төбәк булган. Әмма татар дәүләтләре берәм-берәм юкка чыккач, хансыз һәм гаскәрсез калган халыкның да хәле гаять авырлаша, татар

иле тәре явы астында кала... Мишәр морзаларының бер өлеше, мал-мөлкәтләрен югалтмас өчен, урыс патшалары законына буйсынып, чукынырга мәҗбүр була; бер өлеше, иманны саклап калу өчен, бар байлыгыннан баш тарта һәм «чабаталы морза»га әйләнеп, дөнья буйлап тарала. Гади халык исә бик авырлык белән, чукындыру гарасатларын үз башларыннан кичереп, барыбер ислам динен саклап кала һәм туган туфрагында яшәвен дәвам итә...

Пенза төбәгендә яшәгән мишәр-татарларның чукынганы да, чукынмаганы да хәтер күзәнәкләрендә бөек тарихларын саклыйлар, мәгърифәтле, зур талант ияләре булулары белән аерылып торалар. Тархан авылында туган шагыйрь Михаил Лермонтов - әнисе ягыннан татар, Наровчатта туып-үскән Александр Куприн да чукындырылган татар хатыны Колынчакованың улы. Куприн үзенең татар нәселеннән, Чыңгызхан варисы булуын беркайчан да яшермәгән, әсәрләренә псевдонимны да «Али-хан», дип куя торган булган. Пенза-Мордовия төбәге милләткә дистәләгән талант иясен, акыл ияләрен биргән. Наровчаттан чик аша гына авылларда Һади Такташ, Габдрахман Әпсәләмов, Гафур Коләхмәтов, Шәриф Камал, Фәхрислам Агиев, Мөхәммәтша Мамин, Әхмәт Китаевлар туган, Мирза Мәхмүтов, Рәшит Сюняев, Шамил Тарпищевларның да нәсел тамырлары шушы төбәктән... Шулай ук Еникеев, Акчурин, Тенишев, Кудашев кебек затлы мишәр-татарларның да нәсел башы бирерән.

Ә нәсел тамырлары хәзерге Пенза өлкәсенең Кикин авылына барып тоташкан Муса һәм Заһир Бигиевлар бөтен төрки-ислам дөньясына билгеле шәхесләр бит! Күренекле дин белгече Муса Яруллаһ Бигиевның фәнни хезмәтләрен бүген Төркиядә һәм Финляндиядә, Кытайда һәм Япониядә җентекләп өйрәнәләр, китапларын бастырып чыгаралар, Казанда исә аның турында том-том китаплар чыгарылды һәм документаль фильмнар төшерелде. Аккүл-Тархан-Таракановка авылында туып-үскән танылган татар драматургы, репрессия корбаны Кәрим Тинчурин исемен бүгенгесе көндә Казанда театрлар, урамнар, парклар йөртә, әсәрләре сәхнәдән төшми. Ә Татар Кынадысында туып-үскән Гадел Кутуйның үлемсез әсәрләре, аның сугыш кырларыннан өзгәләнеп:

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта,
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәрчакта, –

дип язган шигырь юлларын җыр итеп башкаралар... Сугыш кырларында мәңгегә ятып калган Гадел Кутуй исемен бүген Казан урамнары йөртә, аның «Тапшырылмаган хатлар» әсәре нәфис фильм итеп төшерел-

де, әсәрләре мәктәп дәреслекләренә кертелгән. Пенза өлкәсенең Татар Пәндәлгесе авылында туып-үскән Шамил Усмановның исемен Казан һәм Чаллы шәһәрләре урамнары йөртә, ул революцион әсәрләре белән билгеле, татар радиосына нигез салган кеше, шулай ук репрессия корбаны.

Күргәнебезчә, XIX–XX гасырларда да Пенза төбәге милләтебезне, Казанны зур талантлар биреп, баетып торган. Моңа өстәп, шушы төбәктән чыккан дистәләгән дин әһелен, мөфтиләрне дә санарга була. Шулай ук «Татар халык иҗаты» томлыкларына кергән йөзләгән бәет һәм борынгы җырларның да нәкъ менә шушы мишәр якларыннан язып алынганлыгын әйтеп үтәргә кирәк, аларга тиңнәр юк!

Ләкин XX гасырның икенче яртысыннан Пенза төбәге милләтебезгә татар язучылары үстереп бирүдән туктады, моның аянычлы сәбәбе – бердә татар мәктәпләренең, татарча укытуның юкка чыгуында иде. Бары тик үзгәртеп кору елларыннан соң гына мәктәпләргә әкренләп татар теле кайта башлады, төбәк тарихы белән кызыксыну артты, бу темага шактый гына китаплар басылып чыкты. Әйтик, Кадыйр Акъегетнең 2001 һәм 2010 елларда Казанда басылып чыккан «Пенза татарлары» һәм «Алты авыл» китаплары, Р.Т.Марданов һәм Н.Б.Китаеваның 2006 елда Казанда дөнья күргән «Средняя Елюзань» документаль китабы, Н.А.Гильдеевның «Татары Пензенского края» (Москва, 2008) һәм И.М.Ишкинның «Кутеевщина» (Пенза, 2008) китаплары, З.А.Әбүзәровның «Алеево» (Москва, 2009) китабы, «Пенза татарлары» энциклопедиясе, шулай ук Ирек Биккининның һәм Фәүзия Бәйрәмованың төбәк тарихына караган дистәләгән фәнни-популяр язмалары халыкка күп яңа мәгълүмат бирде.

«Татарская энциклопедия Пензенской области» (Пенза, 2017) китабына аерым тукталасым килә, чөнки бу хезмәт бик югары дәрәҗәдә башкарылган һәм анда искиткеч бай мәгълүмат тупланган. Дөресен әйткәндә, мондый энциклопедияләрне фәнни институтлар яза, андый гаять җаваплы эш милли башкалаларда эшләнә. Ә Пенза – Казан да түгел, Мәскәү дә түгел, анда татар тарихчылары да юк, архивлар да бөтен Россия буенча сибелгән, шуңа карамастан, төбәкнең татар энциклопедиясе язылган. Икенче яктан караганда, мондый төпле фәнни хезмәтнең нәкъ менә борынгы мишәр-татар төбәгендә тууы гаҗәп түгел, чөнки Төрки һәм Хәзәр каһанлыкларының лаеклы дәвамчылары, заманында үз мөстәкыйль дәүләтләрен тоткан, Алтын Урданың төньяк башкаласы булып торган яклар бит ул! Затлы морза-дворяннар Ватаны, Бигиевтай олуг галимнәр һәм Такташтай зур шагыйрьнең туган туфрагы бит бу төбәк!

Мондый зур хезмәтнең артында Пенза өлкәсенең татар милли-мәдәни мөхтәрияте тора, энциклопедияне оештыручылар да, дөньяга чыгаручылар да шушы мишәр-татар егетләре. Бигрәк тә татар автономиясе оеш-

масының рәисе Бәкер Акҗегетовны аерып күрсәтергә кирәк, чөнки идея авторы да, аны тормышка ашыручы да ул үзе һәм аның янындагы фикердәшләре. Төбәкнең зур эшмәкәрләре бу проектны тормышка ашыруда акчалата ярдәм итсәләр, җирле тарихчылар һәм краевед-публицистлар энциклопедияне үзләренең мәкаләләре белән тәэмин иттеләр. Ә бу мәгълүмат дәрьясын бер эзгә салучы, авторлар белән даими эшләп, иң кирәкле язмаларны гына сайлап алучы һәм аларны энциклопедия дәрәҗәсенә китерүче – хезмәтнең баш мөхәррире Фатыйх Зюзин. Мәкалә авторлары арасында төбәк тарихын даими өйрәнүче Геннадий Белорыбкин, Ирек Биккинин, Кадыйр Акъегетов, Ибраһим Гуркин, Фатыйх Зюзин, Фәүзия Бәйрәмова һәм башкалар бар. Минем үземнең «Наровчат – северная столица Золотой Орды», язмасы, шулай ук Михаил Худяков, Габдрәшит Ибраһимов турында һәм матбугатта дөнья күргән башка хезмәтләрем файдаланылган, шушы төбәкнең тарихын өйрәнүче буларак, үземә аерым мәкалә дә багышланган. Әмма шунысын да әйтергә кирәк, Пенза энциклопедиясен төзегәндә авторларның бу төбәк турында татарча язмалары читтә калган, хезмәт үзе дә хәзергә бары тик рус телендә генә.

«Пенза татарларының энциклопедиясе» зур форматта, 600 битле китап, анда 1200 фәнни мәкалә урын алган, алар барысы да архив чыганакларына нигезләнгән, башка чыганаклар да төгәл күрсәтелгән. Бигрәк тә узган гасырлардагы ревизия документлары, җир бүлү, морзалык һәм дворянлык белән бәйле тарихи белешмәләр, нәсел шәҗәрәләре мул файдаланылган, аларның күбесе китапның артында йөз битлек аерып кушымта итеп урнаштырылган. Биредә шулай ук узган гасырларда Пенза губернасындагы татар авыллары һәм мәчетләр исемлеге, көчләп чукындырулар белән бәйле документлар да урын алган. Шунысын да әйтергә кирәк, бу хезмәт Пенза төбәге белән генә чикләнмәгән, бөтен татар тарихы буенча тулы мәгълүмат бирергә тырышкан, анда дәүләтчелек тарихы да, милләт тормышы да ачык чагылыш тапкан. Бу хезмәттә шулай ук янәшә яшәгән җирле халыклар – мукшы һәм эрзя-әрҗәннәр, борынгы бортас һәм болгарлар, тарихи хәзәр һәм һуннар, славян халыклары, татар һәм урыс патшалары турында да күп мәгълүмат бирелгән.

Пенза энциклопедиясендә Татарстанда яшәүче кайбер милләттәшләребезгә дә аерым сәхифәләр багышланган. Әйтик, күренекле әдәбият галиме Хатыйп ага Миңнегулов узган гасырның алтмышынчы елларында өлкәнең Кутеевка (Качкару) авылы урта мәктәбендә укыткан булган, аның турында бай мәгълүмат бирелгән. Академик Мирза Мәхмүтов үзе, язучы Диас Вәлиевнең әнисе шушы якларда туган булган, алар турында да аерым сәхифәләр бирелгән. Шулай ук аталы-уллы Гадел һәм Рөстәм Кутуйларга багышланган аерым мәкаләләр дә бай эчтәле-

кле, күп мәгълүмат бирә. Чаллыда яшәүче милләттәшебез Билал Канеев Пенза өлкәсенең Кикин авылында туган, үзе дә Чаллы энциклопедиясен төзүче-краевед, бик күп фәнни-популяр язмалар авторы. Туган якларында да аны зурлап, Пенза энциклопедиясенең түренә урнаштырганнар, ул моңа лаек та!

Бүгенгесе көндә дә Пенза өлкәсендә тарихи һәм милли юнәлештә эзләнүләр дәвам итә. Шушы арада «Безнең рухи мирас» дип аталган җыентык дөнья күрергә тиеш, анда төбәктә туып-үскән язучылар һәм галимнәрнең әсәрләре урын алган, мин ул китапка кереш сүз яздым. Бу китап изге максаттан – милләткә үз тарихын, төбәктән чыккан талант ияләрен күрсәтеп бирү өчен әзерләнде. Заманында ханнар һәм морзалар яшәгән, шагыйрьләр һәм галимнәр туып-үскән, милләткә зур әдәби һәм фәнни мирас биргән Пенза төбәге әле киләчәктә дә талант ияләре белән сөендерер, дип уйлыйм. Чөнки биредә иманлы, мәгърифәтле, тырыш һәм булдыклы халык яши. Котыптан килгән гыйлем нуры, әби-бабаларыннан калган рухи мирас, тарихи хәтер бүген дә аларны мөселман-татар итеп тота, милләт мәйданында үз урыннарын табарга ярдәм итә. Бу китап олылар өчен дә, мәктәп укучылары өчен дә бик кирәкле әсбаб булачак, алар туган төбәкләреннән кемнәр чыкканын белеп горурланырлар, үзләре дә шушы мәгърифәт юлын дәвам итәрләр, дип өметләнеп калам.

НОВАЯ КНИГА
РАХИМЗЯНОВ Б. Р. МОСКОВСКАЯ РУСЬ И ТАТАРСКИЕ ХАНСТВА В XV–XVI ВВ. – КАЗАНЬ: ТАТАР. КН. ИЗД-ВО, 2018. – 239 С. ISBN 978-5-298-03583-5

Аннотация: *В книге рассматриваются политические отношения между Москвой и татарскими государствами, образовавшимися после распада Золотой Орды (Большой Ордой и ее преемником Астраханским ханством, Крымским, Казанским, Сибирским, Касимовским ханствами, Ногайской Ордой), в XV–XVI вв. Автор задается следующими вопросами: «своей» или «чужой» была Москва в системе наследников Улуса Джучи? Как менялся ее статус в татарском мире в течение изучаемого периода? Насколько обоснованны прежние суждения о взаимоотношениях обитателей Московской Руси и татарской Степи в позднезолотоордынский период? Прав ли был Лев Гумилев, утверждавший, что Русь и Великую Степь объединял партнерский союз, или же предпочтительна концепция российской имперской и советской исторической науки о постоянной борьбе между русскими и татарами? Профессиональный историк, Булат Рахимзянов отвечает на эти вопросы в своей книге на материале аутентичных источников и с широким привлечением исследовательской литературы. Данное исследование «масштабно, въедливо, беспристрастно, взвешенно и объективно» – такова оценка Д. А. Мустафина, известного казанского историка.*

Содержание книги:

ВВЕДЕНИЕ

ГЛАВА 1. Первые татары в Московском княжестве: от нежданных гостей к постоянным владельцам.

ГЛАВА 2. Куда исчезла Золотая Орда? «Престольное владение» и Крымское ханство в контактах с Москвой.

ГЛАВА 3. Касимов, Казань, Астрахань и Сибирь во внешней политике Москвы.

ГЛАВА 4. Касимовское ханство и другие юрты как «мост» между Москвой и татарскими государствами.

ГЛАВА 5. Московская Русь и татарский мир: соперничество и взаимодействие в позднезолотоордынский период.

ПОДВОДЯ ИТОГИ

СПИСОК СОКРАЩЕНИЙ

ПРИЛОЖЕНИЯ

Приложение 1. Хронология основных событий.

Приложение 2. Персоналии.
Приложение 3. Выдержки из документов.
СВЕДЕНИЯ ОБ АВТОРЕ
SUMMARY

Сведения об авторе. Булат Раимович Рахимзянов (1976 г.р.) – историк (Казанский государственный университет, 1998), кандидат исторических наук (Казанский государственный университет, 2001), автор двух научных монографий: «Касимовское ханство (1445–1552 гг.). Очерки истории» (Казань, 2009) и «Москва и татарский мир: сотрудничество и противостояние в эпоху перемен, XV–XVI вв.» (Санкт-Петербург, 2016) и одной научно-популярной книги, о которой идет речь: «Московская Русь и татарские ханства в XV–XVI вв.» (Казань, 2018).

Непродолжительное время работал в рекламном бизнесе (2001–2002). С 2003 по 2006 гг. работал ассистентом кафедры Отечественной истории до XX в. исторического факультета Казанского государственного университета. В 2006/2007 академическом году проводил научное исследование в Гарвардском Университете (США, г. Кембридж), а также в Санкт-Петербургском государственном университете. В мае 2011 г. работал в библиотеках Парижа (Франция), в мае 2012 г. – Майнца и Берлина (Германия). С 2008 г. – старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани Академии Наук Республики Татарстан.

Колумнист интернет-газеты «Реальное время».

Участник многих научных и образовательных мероприятий, в их числе – международные научные конференции, Летние школы, докторские семинары. Выступал с докладами в Гарвардском университете, Санкт-Петербургском государственном университете, Высшей школе социальных наук (EHESS, Париж), университете Иоганна Гуттенберга в Майнце, Высшей школе экономики (Москва), Уральском федеральном университете, Венском университете.

Лауреат премии Республики Татарстан для государственной поддержки молодых ученых по направлению «История, язык и литература» (2004). Финалист программы Фулбрайт по обмену учеными (2006). Стипендиат Фонда Карнеги в области социальных и гуманитарных наук (2007). Победитель в номинации «Лучший молодой ученый 2009 г.», учрежденной Академией Наук Республики Татарстан. Грантополучатель Международной ассоциации гуманитариев (2007–2008), Фонда Герды Хенкель (2010–2012), Франко-российского центра гуманитарных и общественных наук в Москве (2011), Российского фонда фундаментальных исследований (2016), Германского исторического института в Москве (2016).

Редакция журнала «Туган җир/Родной край»

О НОВОЙ КНИГЕ Р.Ф. МУХАМЕТДИНОВА «ТЮРКИ В ИСТОРИИ МИРОВОЙ ЦИВИЛИЗАЦИИ». КАЗАНЬ: «ГРУМАНТ», 2018 – 156 С.

В книге на основе лингвистических материалов изучается древнейший период тюркской истории. Показан механизм возникновения языка как такового. В книге исследуются закономерности развития тюркского языка в древности и влияния не только его лексики, но и элементов его грамматики на развитие других языков.

Автором впервые представлена оригинальная лингвистическая таблица, которая играет такую же роль в языкознании, как таблица Менделеева в химии. Он также в своих исследованиях опирается на свою Солнечно-дождевую теорию. Эти материалы представляют собой новые методы, которые открывают дальнейшие горизонты в сфере этимологии и языкознания вообще.

Данные изыскания позволили автору сделать также определенные обобщения относительно древнейшей истории и происхождения тюрков.

Сведения об авторе: Мухаметдинов Рафаэль Фардиевич (канд. исторических наук) родился 4 мая 1947 г. в г. Березовский Свердловской области. В 1974 г. окончил Турецкое отделение (филологию) Восточного факультета Ленинградского (С-Петербургского) университета.

До 1981 г. работал в индустрии туризма в Ленинграде. С 1981 г. работал научным сотрудником в системе АН Татарстана, с 1996 г. по 2013 гг. – в Отделе истории общественной мысли и исламоведения Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

Он является автором нескольких монографий по истории татарской общественной мысли и истории формирования общетюркской идеологии (тюркизма) XX в.

Одновременно его всегда интересовала древняя история тюрков и их культурные контакты с другими народами. Он более 20 лет собирал лингвистические материалы разных языков по этой теме и данная книга стала плодом такой работы. По данной теме были опубликованы большое число статей в периодической печати на русском и татарском языках, имеются также публикации в турецких журналах.

Татар рухы

Татарский дух

ГАЯЗ ИСХАКИ: РЕВОЛЮЦИОНЕР, ПИСАТЕЛЬ И ТАТАРСКИЙ ФУТУРОЛОГ

Р.В. Айсин

Гаяза Исхаки, особенно татарский интеллектуал, знает по его известным произведениям «Зулейха» и «Исчезновение через двести лет». Но он был не только и не столько литератором и публицистом, сколько публичным политиком, одним из организаторов татарского национального движения в годы революционного лихолетья. В текущем году мы отмечаем 140-летие со дня его рождения. Это был человек своей эпохи, а такие личности – цельные, монолитные, деятельные, пассионарные – востребованы и сегодня. В советское время имя и произведения Исхаки были запрещены, но с конца 1980-х гг. его духовное и политическое наследие вновь предстало перед татарским обществом во всем своем величии.

Как и любой человек, занимающийся творением истории, Исхаки не смог избежать политических ошибок. По-другому и не бывает. Политика – это часто череда ошибок, нащупываний вариантов реализации собственной цели, ситуативные и тактические союзы, просчеты и лишения. Трагизм политики для простого обывателя в том, что он не выдерживает силового напряжения возложенной ответственности. Короче говоря, быть в авангарде исторических процессов – удел немногих избранных. Их мы и называем элитой.

Принадлежал ли Гаяз Исхаки, чье имя в Казани носит улица, параллельная другой, названной в честь иного видного татарского деятеля и соратника Мао Цзэдуна, Бурхана Шахиди, к элите татарского народа? Думаю, что сомнений здесь быть не может. Не просто принадлежал, а был в когорте первых. К слову сказать, Шахиди знал татарский, русский, китайский, уйгурский, немецкий, арабский, персидский, турецкий языки. Это помогло ему занять лидирующие позиции в китайской государственной системе и не затеряться в хитросплетениях тогдашней международной ситуации, когда Шахиди пришлось быть на острие многих значимых событий. Увы, некоторые наши деятели, автоматом причисляющие себя

к национальной элите, находят сотни причин не учить родной язык, хотя язык выступает не просто средством коммуникации, а является еще инструментом мировоззрения, мышления, особой парадигмы миропонимания.

Китайцы говорят: не дай бог никому жить в эпоху перемен. Но именно «эпоха перемен» выносит наверх из донных слоев народной массы ее лидеров, способствующих развитию общества, цивилизации. Без движения все превращается в застой. Поэтому Первая русская и Октябрьская революция выдвинули на передний край борьбы за национальные права тех людей, которые сегодня служат для нас маяком и образцом для подражания. В их числе был и Исхаки, чья звезда загорелась после революции 1905 г., когда он стал известен не только как литератор и публицист, но и как организатор, идеолог национально-освободительного движения. Без сомнения, он был и остается значительной фигурой в истории татарской общественной мысли. Ряд его идей до сих пор не потерял своей живости и актуальности.

Такие знаковые фигуры татарского мира, как Рашит Ибрагимов, Галимджан Баруди, Ризаетдин Фахрутдинов, Юсуф Акчура, Гаяз Исхаки, Садри Максуди, подготовили почву для духовного и политического возрождения татарской нации на рубеже веков. Но в 1918 г. приход большевиков и новая политическая реальность приостановили поступательное движение татар к своей свободе. На место народовластия, о котором говорил и сам Владимир Ленин, пришла диктатура, чугунным ядром придавившая ростки нарождающейся свободы и равноправия народов. Следствием этого стал раскол в татарском национальном движении. Ряд борцов за национальное освобождение народа были уничтожены физически или изгнаны красной «элитой».

К большому сожалению, сторонники Иосифа Сталина, одержавшие верх над ленинцами, стали руководствоваться методологическими наработками царского режима: шовинизм, искоренение культурной и этнической инаковости, идеологическое единоначалие. Большевики умело разобрались со своими оппонентами, в том числе и с лидерами национально-освободительных движений, бывших в числе шагающих вместе с революционным движением. Проект национального государства Штат Идел-Урал, в организации которого Исхаки наряду со своими другом Максуди принимал деятельное участие, был разгромлен. Мечты татар на собственный государственный проект были разбиты. Исхаки, будучи политическим вожаком, продолжил борьбу за сохранение государственности татар. После поражения в Поволжье, он пытался перенести ставку Милли идарэ (Национального Управления) в город Петропавловск и от-

туда вести политическую борьбу. Но она была обречена. В 1920 г. Г. Исхаки покинул пределы Родины навсегда.

Но и за пределами страны он не оставляет дела всей своей жизни – ведет активную политическую и общественную деятельность, много и плодотворно пишет, организует татарское национальное движение зарубежья.

Столетие назад татарская литература испытала огромное идейное и художественное влияние творчества Гаяза ага. «Наше все» Тукай, тонкий и возвышенный Дэрдменд, Карими, Амирхан, Камал, Кулахметов, Гафури, Камал, Файзи, Тинчурин и другие несли в себе творческую печать Исхаки, они не чурались заимствовать его художественные подходы.

Образ Гаяза Исхаки, не вполне понятный и противоречивый для человека советской эпохи, в действительности титанический и отчасти трагический. Он титан духа. Ведь Исхаки смог сплести воедино в своей личности два начала: борца-политика и теоретика-интеллектуала. Это уникальное сочетание всегда рождает на свет великого человека-мыслителя и борца, пассионария ума и тела.

Часто вспоминают его повесть «Исчезновение через двести лет», рассуждения о судьбах татарской нации. Можно сказать, что данная повесть является программным произведением Исхаки. По его мнению, через 200 лет – а произведение было написано в начале XX в. – татары могут просто сойти на нет как нация. Но причины, по которым он делает такой вывод, определенным образом отличаются от проблем татар сегодняшнего дня: нежелание интегрироваться в мировую цивилизационную систему, невозможность получения европейского образования, недостаточная открытость миру. Естественно, Исхаки переживал о нравственном положении молодого поколения. Эти и многие другие процессы, идущие в татарском обществе, сильно волновали его.

Сегодня же мы наблюдаем немного другую картину. Татарская нация открыта миру, кто-то получает хорошее образование в Европе и США, татарский бизнес и правящие круги прекрасно вписаны в мировой порядок, но «инкыйраз» (с татарского «вымирание», «счезновение» — прим. ред.) не отступает, напротив, он ускоряет свою поступь. Стало быть, это процесс двусторонний. Хотя, возможно, мысль Исхаки была в том, что представители национальной элиты (настоящей, а не самозваной) должны стать частью передового человечества и, сохраняя традиции, вести народ вперед, чтобы не плестись в конце этнической колонны.

Только вот возникает проблема. После революции национальная элита была или истреблена, или выдавлена из страны. А у прорвавшихся наверх люмпенов не было полноты понимания, видения, отсутствовал цен-

тральный элемент – горящее сердце и чувство этнического достоинства, поэтому можно было давать им пять, шесть образований, но что толку, если ориентация у них не на фундаментальные ценности, а на сверкающие ложным глянцем материальные побрякушки и эгоцентризм.

Может, оттого его юбилей и прошел незаметно, скромно, даже вяло. Гаяз Исхаки – неудобный для некоторых мыслитель и политический деятель. Он выступал против царского гнета и политического притеснения народов, за социальную справедливость и равноправие. Исхаки был революционером и бунтарем.

Жалуют ли таких людей сегодня? Оставим ответ на этот вопрос читателю, пусть он сам его сформулирует.

МИЛЛИЛЕКНЕ НИЧЕК САКЛАРГА?

Авырткан җирдән кул китми, диләр. Июль ахырында Казанга, Бөтендөнья Татар конгрессының чираттан тыш корылтаена җыелган милләттәшләребезгә, табигый, урыс булмаган халыкларның милли телләрен мәктәптә укытуны ихтыярыйга калдырсалар, нишләрбез, татар мохитен ничек саклап калырга, дигән сорауларны бирми кала алмадык. Бу уңайдан безгә «Мәскәү татарлары штабы» рәисе Рөстәм Җамалиевның фикер-тәкъдимнәре төпле, кызыклы тоелды.

– Сез – эшкуар, төзелеш индустриясендә җиң сызганып эшләүче кеше. Ничек иҗтимагый, милли эшләр белән кызыксынып киттегез?

– Түбән Кама шәһәрендә яшәгәндә миңа күренекле галимебез, милләтпәрвәр шәхесебез Азат Зыятдинов белән тыгыз аралашу насыйп булды. Шуңа күрә 1997 елны, Мәскәүгә эшкә күчкәч, иҗимагый-милли мохиткә кереп китүем табигый. Озак еллар республикабызны җитәкләгән Фикрәт Табиев әтиемне үз иткәнгә, бергәләшеп Минзәлә якларына балыкка йөрергә яратканга, аның улларын, үзен дә шактый яхшы беләм. Шуңа күрә башкалага килүгә аның белән күрешергә ашыктым. Фикрәт

аганың хәтере искиткеч яхшы иде. Ык буенда аралашкан, гәпләшкән балыкчыларның, умартачыларның исем-фамилияләрен дә онытмавына исем китте. Ул вакытта Мәскәүдә шактый зур иҗтимагый көчкә ия булган «Уналты» дигән клуб эшли иде. Аны 1990 елны Татарстаннан килгән партия, Совет органнарында эшләгән якташларыбыз оештыра. Җитәкчесе, аңлашыладыр инде, Фикрәт Табиев, аның урынбасарлары – үз вакытында Татарстанда җаваплы вазифаларда эшләгән Валерий Кузьмин, Анатолий Козлов.

– Ни өчен «Уналты», унҗиде яки унсигез түгел?

– Моның мәгънәсе бик тирән: бер сулыш алу вакытында йөрәк уналты тапкыр тибә икән. Мине дә клубка әгъза итеп кабул иттеләр, яшьләр белән эшләүне тапшырдылар. Яшь буынны тәрбияләү проблемалары хакында без аның белән күп сөйләштек. Дөрес, милли якка әллә ни кагылмый, һәрхәлдә бу җәһәттә эшләп бетермәвен таный иде Фикрәт ага. Шулай да Татарстаннан килгән белгечләрнең тырышлыгы, үҗәтлеге белән аерылып торуын искәртми калмый иде. Егерме ел республикабызга җитәкчелек иткәнгә, татарстанлыларның фидакарьлеген, максатчанлыгын яхшы белде, югары бәяләде ул. Аларның Мәскәүгә килгәч, үзләрен күрсәтә, зур дәрәҗәләргә ирешә алмауларына эче пошуын да яшермәде.

Аныңча, Мәскәүне «яулап алу» өчен бик тырыш булырга, эшкә барысыннан да алдарак килергә, барысыннан да күбрәк эшләргә кирәк. Без дә үз тарафыбыздан ярдәм итми, кирәкле җирдә кирәкле сүзне әйтми калмабыз, дип әйткәне әле дә колак төбендә яңгырап тора. Дөрес, ул миллилеккә басым ясамады, татарстанлылар, дип әйтергә яратты. Гадәттә безнең клубка 20-30 кеше килә, бик төпле шәхесләр җыела иде. Алар күпләребезгә эшкә урнашырга, Мәскәү мохитенә ияләшергә булышты, ярдәмләшеп яшәргә кирәклеген сеңдерде.

Инде үземә килгәндә, шәхес булып формалашуымда Азат Зыятдиновның йогынтысы аеруча зур булды. Туган телебезнең кадерен, искикеч зур байлык икәнен, бу байлыкны югалту куркынычы барлыгын мин болай да яхшы аңлыйм, әмма бу вәзгыятьтә нишләп булганын чамалый, күз алдына китерә алмый идем. Бәлкем кайчагында урамнарга, мәйданнарга чыгып та үз сүзеңне әйтергә кирәктер. Әмма миңа Азат абыйның карашы якынрак. Ул беренче чиратта законлы чаралар белән көрәшүне, сәяси ихтыяр күрсәтүне, зыялылыкны алга сөрде. Татарлар сәяси милләт булырга, төрле дәрәҗәдәге законнар чыгару органнарына сайланырга, юристлар булып эш йөртергә, милли мәнфәгатьләрне шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куярга тиеш; хакимиятләрдә никадәр күбрәк татар булса, милли мәнфәгатьләрне хәл итү шулкадәр җиңелрәк булачак, дип исәпләде аксакалыбыз.

Офицерлар, табиблар...

– Яшьләр белән эшләүдән тыш, аерым һөнәр ияләрен туплый башлау да яхшы нәтиҗә биргән дип беләбез.

– Инде хәзер кем тәкъдим иткәнен хәтерләмим: клуб утырышларның берсендә берәвебез, хәрбиләрне, табибларны аерым җыеп карасак, отышлырак булмасмы, дип тәкъдим итте. «Китай-городта» офицерларны, көч структураларында эшләүче якташларыбызны җыюдан башладык. Бу очрашуларны оештыруга Татарстан Эчке эшләр министрының элеккеге урынбасары Федотов алынды. Шул рәвешле аны офицерлар җыелышын оештыруга җаваплы кеше итеп куйдык. Даими Казаннан килеп йөрүче классташым Ринат Кадерметов табибларны һәм табиблыкка укучы студентларны туплауга кереште. Шулай итеп, 1998 елдан башлап без табибларны, офицерларны аерым-аерым җыябыз. Бигрәк тә офицерлар өчен бу бик файдалы булып чыкты. Күптән түгел генә оешкан яшь сәнәгатьчеләр, ягъни промышленниклар клубы утырышлары да бик кызыклы үтә хәзер.

Аерым һөнәр ияләрен туплау белән бергә, туган телебезнең саклнышын кайгыртучы, татар дип җан атып йөрүче милләттәшләребез дә бар бит әле. «Мәскәү татарлары штабы» нәкъ менә шундый милләтпәрвәрләребезне туплау өчен оештырылды да. Мәскәү кебек зур шәһәрдә, мегаполиста, туган телне саклау күпкә катлаулырак икән. Казан белән чагыштырганда монда милли мохит бик чикләнгән. Ил башкаласында татарча аралашуны ничек тәэмин итәргә соң? Туган телгә мәхәббәт булганда, милләттәшләребезне татар теленең башка бер телдән дә ким булмавына, үзенчәлегенә ышандырганда, үзенчәлеген, матурлыгын, сыгылмалылыгын күрсәткәндә генә моңа ирешергә мөмкин. Татар теленә ихтыяҗ булырга, бу зарурлык балага ана сөте белән сеңдерелергә тиеш. Бәлкем кайберәүләрне туйдырып та бетерәмендер: яшьләр белән очрашу вакытларында мин, сез татар булып тугансыз икән, туган телегезне белергә тиеш, дип йөзәр мәртәбә кабатлыйм. Мин яшь буынга 2–3 мең еллык зур, шанлы тарихыбыз, егетләребез, кызларыбыз җилкәсенә салынган зур җаваплылык, татарлыкның алар кулында чакта өзелмәскә тиешлеге турында сөйлим. Татар гына түгел, мөселман да булырга тиешлегебезне, мәчеткә йөрергә кирәклеген дә тәкърарлыйм. Мәскәүдә бу эшчәнлекне мин егерме ел дәвам итәм инде. Безнең штабка яшьләр бик теләп килә: гадәттә мең, мең ярым кеше йөри.

– Урыс булмаган халыкларның милли телләрен мәктәпләрдә укытуны ихтыярыйга калдыру ихтималы килеп чыккач, сер түгел, күпләр аптырашта калды...

– Казанда тел мәсьәләсендә кризис килеп чыккач, безне күпләр, шул хәтле кешегез була торып, нигә урамнарга чыкмыйсыз, бу хәлләргә про-

тест белдереп, нигә авызыгызны «тегеп куймыйсыз», дип дәгъва белдерде. Их, авызны «тегеп куеп» кына проблемаларны хәл итеп булса икән... Авызымны тегеп куйганчы, яшьләребезгә йөз дә беренче тапкыр ерак гасырларга сузылган дәүләтчелегебез булганын, Россия дәүләтен коруга татарның урыслар белән бердәй өлеш кертүен, Алтын Урда кебек олуг тарихыбызны искә төшерәчәкмен, горур булырга чакырачакмын, яшьләрне татар концертларына, спектакльләренә алып барачакмын, милли мәдәниятебезнең, халык иҗатының гүзәллеген күрсәтә торган сабантуйларга дәшәчәкмен, дип җавап бирдем аларга.

Үрнәк алырлык каһарман шәхесләребез күп безнең. Яшьләребезне менә шулар үрнәгендә тәрбияләргә, милли асылыбызны саклауның зарурлыгына ышандырырга кирәк. «Син Кашпировскиймы әллә? Тиеш, кирәк дип мең мәртәбә кабатласаң да, бүгенге глобальләштерү заманында аларны ышандыру, миллилекне, татарлыкны саклау – гаять зур проблема!», – дип әйтәләр миңа. Зур байлар, депутатлар, җитәкче кадрлар исемлегенә эләксәгез, билгеле, милли мәнфәгатьләрне хәл итүгә ныграк булыша алачаксыз, дип тәкърарлап торам мин кызларыбызга, егетләребезгә.

Әлеге телләр кризисы килеп чыккач, штаб үткәргән тел сәясәтенең актуальлеге күренде. Бу вәзгыятькә кадәр Мәскәү шәһәрендә дә, өлкәдә дә татар мәгарифе мәсьәләләре белән ныклап шөгыльләнүче бер милли-мәдәни мөхтәрият тә, милли-мәдәни оешма да юк иде. Иң әүвәл без активистларыбызны ике меңгә җиткердек. Хәзер безнең һәр югары уку йортында активистларыбыз бар. Соңгы вакытта милли-мәдәни мөхтәриятләребезнең һәм иҗтимагый оешмаларыбызның утырышларын бергә уздыра башладык. Тел кризисыннан соң без, татарлар, фәкать татарларга гына өйләнергә, үз милләттәшләребезгә генә кияүгә чыгарга тиеш, дип ачыктан-ачык сөйли башладык. Безнең төп проблемабыз – башка милләтләр арасында эреп югалу. Татар балалары күбрәк тә туа. Әмма безнекеләр кайсы милләт баласы белән тормыш корса да, аларның балалары урыска әйләнә, өйдә, гаиләдә урыс теле хөкем итә. Милләтара проблемалар балаларга исем кушудан башланып зиратта ничек күмүгә хәтле дәвам итәчәк: яшьләребезгә без менә шуны аңлатырга тырышабыз.

И туган тел

– Шулай да оешмагызны ни өчен «штаб» дип атадыгыз?

– Штаб ул – оештырып, туплап, я көч биреп торучы урын. Телебезнең, гаиләләребезнең иминлеген кайгыртучы, милли мәсьәләләргә битараф булганнарны уятучы, активларны туплап торучы икәне кычкырып торсын дидек. Тиз арада кулланышка кереп китте бу атама. Зыятдиновның – туган телебезне саклыйк дигән васыятен, Табиевның, тырышлыгың, белемең белән Мәскәүдә лаеклы, дәрәҗәле урын яуларга мөмкин, дигән нәсихәтен

шигарь итеп алдык. Татар табиблары, татар икътисадчылары, татар офицерлары! Мондый кадрлар белән сирәк милләтләр генә мактана, горурлана ала! Безнең тәҗрибә беренче чиратта яңа гына Мәскәүгә килеп урнашкан яшьләр өчен кирәк. Нигә Мәскәү шәһәре Думасында татарлар юк? Нишләп башкалада татар судьялары бик аз? Шушы егерме елда безнең аша бик күп табиблар, милиционерлар эшкә урнашты, хезмәт баскычыннан күтәрелде.

Тел кризисы килеп чыккач, без бу хәлнең сәбәпләренә төшенер, нәрсә эшләргә соң дигән сорауга җавап табар өчен яшьләребез катнашында «түгәрәк өстәл» янында сөйләшүләр оештыра башладык. Беренче «түгәрәк өстәл»гә Казаннан журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиевне чакырдык. Бернинди дә төшенкелеккә бирелмәскә кирәк, бу хәлдән чыгу юлларын эзлибез, дип ул безне тынычландырды. Аннан политолог Руслан Айсинны, Илшат Сәетовны, Нәзифә Кәримованы, Ринат Мөхәммәдиевны һәм башка күренекле шәхесләребезне чакырдык. Җәмгысе ун «түгәрәк өстәл» уздырдык. Әлеге сөйләшүләрдә Мәскәүдәге һәр югары уку йортыннан активистлар катнашты. Башкаладагы күп кенә милли оешмалар татарлар нишләр, нинди карарга килер икән дип безгә карап тора. Безгә көчле Россия кирәк, диләр. Килешәм. Әмма республикалары, өлкәләре көчле булмаса, федераль дәүләт ничек көчле булсын?!

Билгеле, тел мәсьәләсендә арттырып җибәрүләр федераль дәүләтебезнең асылына туры килми. Конституциябездә, һәр милләтнең үз ана телен сакларга, үстерергә хокукы бар, дип язылган. Әгәр сәяси милләткә әйләнәбез, үз хокукларыбызны яклап хәрәкәт итәбез икән, туган телебез, милләтебез юкка чыкмаячак. РФ Дәүләт Думасы мәгариф турындагы законга нинди үзгәрешләр кертер, безнең дәгъваларны, мөрәҗәгатьләрне исәпкә алырлармы – күрербез.

Телебезгә һөҗүм итүләренә җавап итеп, без бүген татарча күбрәк аралашабыз, аулак өйләр уздырабыз. Хәзер штабыбызда гаилә институты оештырдык. Һөнәрләргә өйрәтсәләр дә, гаилә корырга, бер-береңә ничек җайлашырга, санлашырга кирәклеген бер җирдә дә өйрәтмиләр бит. Бу юнәлештә вәгазь сөйләсеннәр, нәсихәт бирсеннәр өчен хәзер имамнарны ифтар мәҗлесләренә генә түгел, үзебез үткәрә торган барча чараларга даими рәвештә чакырабыз. Безгә калса, мондый сәяси вәзгыятьтә төрки халыкларны туплау аерым бер әһәмияткә ия. Шуңа күрә хәзер төрки халыкларның уртак ифтарларын уздыра башладык. Үзебезгә барча төрки халыкларның милли җәмгыятьләре башлыкларын чакырдык. Беренчедән, төрки кардәшләребезне бер-берсе белән таныштырдык. Икенчедән, багланышларны ныгыту өчен хәзер футбол командасы оештырырга, уртак концерт-кичәләр оештырырга булдык. Мондый зур шәһәрдә югалып калмас өчен, без – төрки халык вәкилләре бергә бердәм булырга

тиешбез. Бәлкем Казанда бу аңлашылып та бетмәс. Әйтик, Мәскәүдә, алты мең кешегә исәпләнгән Кремльнең Концертлар сараенда концертка кеше җыю өчен генә дә төрки халыкларга бергә булырга кирәк.

Штаб башлангычы белән күптән түгел төрки халыкларның тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән Морат Аджига багышланган кичә оештырдык. Башкорт яшьләре белән ифтар оештыру да кызыклы гына чара булды. Без татар студентларының башкорт студентлары белән аралашуын, дуслашуын телибез. Ике кардәш халык вәкилләренең дуслык күпере дип атаган уртак концерты шулай ук матур башлангыч булды, бу бәйләнешләр киләчәктә дәвам итәр дип өметләнәм. Мәдәниятләребез уртак, телләребез бик якын бит. Табигый, яшьләр бер-берсенә тартылмый калмый. Мәскәү яшьләренең күпчелеге – нижгарлылар. Бераз кырым татарлары да бар. Штабыбызның советы бар. Совет ай саен гына түгел, кирәк дип тапканда атна саен да җыела.

Беренче намаз

– Соңгы елларда Мәскәү шәһәре һәм Чуашстан мөфтие, Россия мөселманнарының рухани җыены рәисе Әлбир хәзрәт Кырганов белән актив хезмәттәшлек итәсез дип беләбез.

– Менә алты ел инде Әлбир хәзрәт Кыргановны чакырып, аның мәчетенә барып та «беренче намаз» мәрасиме уздырабыз. Быел алты ифтар мәҗлесе уздырдык һәм ифтар алдыннан шундый чара оештырдык. Дингә җәлеп итү белән беррәттән мөселман-татар гаиләсе булдыруны максат итеп куйдык без. Яшьләребез катнаш гаилә корырга уйлый икән, булачак ирең яки хатының динебезне кабул итәрме, телебезне өйрәнерме, дип кызыксынабыз. Шөкер, соңгы вакытта штабка йөргән яшьләребез үзара гаилә кора башлады. Ел да кимендә алты-сигез татар гаиләсе корыла. Бәлкем, бу бик аз тоелыр. Киләчәктә күбәер, иншалла. Соңгы вакытта, бигрәк тә җәй айларында, яшьләребез бергәләп табигатькә, сәхрәгә чыга башлады. Танышу, бер-береңне якыннан күрү, аралашу өчен бик яхшы форсат бу. Татар гаиләсе кору, җитди мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен кем нинди кызыклы тәкъдим кертә, бездә барысы да кабул ителә. Җитди мөнәсәбәтләр, гаилә тормышы, билгеле, никахтан башка була алмый.

Гади генә бер нәрсә турында әйтим әле. Бигрәк тә футбол буенча дөнья чемпионаты вакытында күп кенә яшьләребез, үрмәкчедән күрмәкче дигәндәй, тәннәренә һәртөрле сурәтләр, бизәкләр төшерә башлады. «Соңыннан аларны бетерү кыен булачак. Мөселманнарга мондый эш тыела. Үз тәнеңә әллә нинди сурәтләр төшерү һич ярамый», – дип аңлатырга тырышабыз. Татар кызына бигрәк тә килешми мондый гамәлләр. Яулык бәйләгән кызның кияүгә чыгу ихтималы зуррак та, югыйсә. Ни кызганыч, яшь кызларыбызның бүген шактые гаилә коруны, балалар үстерүне уйламыйча, эшен кайгырта, хезмәт баскычлары буенча тизрәк

күтәрелергә тели. Татарлар күп туарга, яшь аналар сәламәт булырга, балалар кечкенәдән туган телебезнең ләззәтен, матурлыгын тоеп, сеңдереп үсәргә тиеш. Әлбәттә, урыс телен дә, инглиз телен дә үзләштерми булмый. Әмма аңа кадәр бала туган телен сеңдерергә тиеш.

Хәзер без Мәскәүдә татар балалар бакчалары, ясленәре булдыруны кайгырта башладык. Якшәмбе мәктәпләрендә генә түгел, гаиләләргә укытучылар чакыртып та татар теле һәм әдәбиятыннан дәресләр бирергә мөмкин дигән фикергә килдек. Татар укытучылары тел, әдәбияттан гына дәресләр бирмичә, татар тарихын да аңлатып, балаларда милли үзаң да тәрбияләргә тиештер шәт. Билгеле, Мәскәүдә татар мәктәпләре дә булырга, бала татарча фикер йөртсен өчен башлангыч сыйныфларда булса да татарча белем алырга, татар спектакльләре күреп үсәргә тиеш. Сугышка хәтле Мәскәүдә татар театры эшләгән, татарча газеталар да нәшер ителгән бит. Шунсыз Мәскәүнең татарча иҗат итә торган үз татар зыялылары үсмәячәк. Хәзер эшкуарларыбызны шул эшкә җәлеп итмәкче булабыз.

– Хәзер Казанда җәен генә түгел, кыш айларында да тел өйрәнү лагерьлары эшли башлады. Мәскәүдәге татар балаларын аларга җибәрмисезме соң?

– Безнең андый элемтәбез юк. Мәскәүдәге иҗтимагый, милли оешма җитәкчеләренең Казандагы бу эшкә җаваплы хезмәткәрләр белән әллә ни дуслыгы юк. Моны, билгеле, беренче чиратта мәскәүлеләр кайгыртырга, активлык күрсәтергә тиеш.

– Мәскәүдә татар компонентлы бер мәктәп бар-барын. Билгеле, ул гына аз. Татар якшәмбе мәктәпләре эшлиме соң?

– Әлбәттә, Мәскәү өчен бер мәктәп кенә аз. Якшәмбе мәктәпләре бар. Әмма якшәмбе мәктәпләре челтәре шактый зәгыйфь хәлдә әле. Берничә урында тел өйрәнү түгәрәкләре эшләп килә. Татар укытучылары, татар нәнкәләрен әзерләү максатчан эш булырга, югары дәрәҗәдә хәл ителергә тиеш. Татар эшкуарлары арасында да бу эшнең зарурлыгын аңлату җитми әле. Без соңгы вакытта Сабантуйларны да үзгәчәрәк оештыра башладык. Иң мөһиме: анда килгән балалар, яшүсмерләр, егетләр, кызлар тамашачы булып кына утырырга түгел, ярышларда үзе катнашырга тиеш. Бу максатта аерым балалар мәйданчыклары булдыру бик отышлы икән. Кыскасы, милли чараларны оештырганда, монысы мөһимрәкме, тегесеме, дип тормыйча, күбрәк кеше җәлеп итәргә тырышырга кирәк. Бәлкем бүген кечкенә бер эштә үзен күрсәткән кеше иртәгә яңа яклары белән ачылып китәр, алыштыргысыз ярдәмчегә әйләнер. Әнә Гөлнара, Марат, Фәридә кебек яшьләребезне әле күптән генә бик азлар белә иде. Хәзер алар үзләре күпләрне тартып, җәлеп итеп тора.

Әңгәмәдәш – Рәшит Минһаҗ

Юбилярлар турында сүз

Слово о юбилярах

АКТИВИСТ ВЕТЕРАНСКОГО И КРАЕВЕДЧЕСКОГО ДВИЖЕНИЯ

(к 85-летию Н.И. Сайдашева)

18 июля 2018 г. исполнилось 85 лет со дня рождения активиста ветеранского и краеведческого движения из г. Лениногорска Наиля Идрисовича Сайдашева.

Впервые с этим удивительным человеком я познакомился в городе Казани совершенно случайно, когда летом 1997 г. в ходе археологических раскопок Кабанского городища в Приволжском районе г. Казани (на территории НПО «Нива Татарстана» в Архирейской даче) ко мне подошел моложаватый ветеран и сказал, что он интересуется историей нашего народа и поблагодарил меня за новые находки и уникальное открытие. Тогда я ему с удовольствием подарил свою небольшую, недавно выпущенную в Ашхабаде, книгу по археологии Средней Азии. К сожалению, из-за плотного графика исследований, я не уделил этой встрече особого внимания, не запомнил имени ветерана и не надеялся на новую встречу с ним.

Прошло почти 17 лет и 1 апреля 2014 г. в городе Лениногорске мы совместно с администрацией и Управлением образования Лениногорского района РТ проводили Круглый стол «Изучение и сохранение объектов историко-культурного наследия Лениногорского района и Юго-Восточного Татарстана». После завершения конференции ко мне подошел ветеран в медалях на груди и представился: «Наиль Идрисович Сайдашев» и показал мою книгу по археологии Средней Азии с моим автографом и напомнил о нашей встрече в Казани в 1997 г..

С тех пор с ним мы стали встречаться чаще – то в Лениногорске, то в Казани, то в районах РТ или в городах РФ. Я с удовольствием приглашал талантливого ветерана и его коллег для участия на различных мероприятиях в Казани и районах Татарстана, а он, в свою очередь, не забывал меня и приглашал на мероприятия ветеранов и краеведов в Лениногорском районе и других регионах РТ и РФ.

* * *

По судьбе Наиля Идрисовича Сайдашева в какой-то мере можно проследить и историю Лениногорского городского и районного Совета вете-

ранов, которым руководит М.Ш.Исхаков. Его надежным тылом и заместителем является Наиль Идрисович.

Н.И.Сайдашев родился в Уфе в 1933г.. После службы в Советской Армии, окончив Октябрьский нефтяной техникум РБ, начал трудовую деятельность оператором по исследованию скважин, затем мастером на нефтепромысле №2 НПУ «Лениногорскнефть» и с 1964г. проработал 25 лет техническим инспектором труда ЦК профсоюза рабочих нефтяной и газовой промышленности. Закончил он в 1975г. Высшую школу профсоюзного движения. С тех пор у Н.И.Сайдашева сохранился профсоюзный закал: постоянное стремление помочь тем, кому нужна поддержка.

Многие знают Н.И.Сайдашева как журналиста и писателя. Свою литературную деятельность он начал в 1974г. в городской газете с заметки «Как не надо торговать». Затем обучался в школе общественных корреспондентов при редакции «Заветы Ильича». После окончания школы рабкоров свои знания он стал применять в жизни. Он активно сотрудничает с отраслевыми изданиями газет, журналов «За нефть», «Нефтяник Татарстана», «Охрана труда и социальное страхование», «Советская Татария» и «Труд». Основная тема – проблемы охраны труда в нефтяной промышленности, В журнале «Охрана труда и социальное страхование» открыл новую рубрику «Поучительные истории», в газете «Заветы Ильича – «Записки судебного заседателя».

В 90-е гг. по случаю юбилеев НГДУ «Лениногорскнефть» ветераны выпустили прекрасные душевные книги – воспоминания. С тех пор они считаются самыми лучшими работами. С большим энтузиазмом и любовью к товарищам по работе Наиль Идрисович написал о них некоторые главы в выпусках сборников: «Запах пороха и нефти», «Там, где растут ромашки», «Ромашкинские зори». В 1995г. авторский коллектив сборника «Там, где растут ромашки», был удостоен звания «Лауреат премии имени Шамиля Бикчурина». А потом Наиль Идрисович к 50-летию Бугульминского авиапредприятия самостоятельно выпустил книгу «Жизнь в полётах». Биографии лётчиков у него получились живыми и привлекательными.

Он приобрёл большой опыт работы и знания по соблюдению трудового законодательства в нефтяной промышленности, расследованию аварий и несчастных случаев, приёмке строящихся объектов, а также стал обладать хорошими техническими знаниями. За создание новой рубрики «Поучительные истории» в журнале «Охрана труда и социальное страхование», был награждён Почётной грамотой ВЦСПС и нагрудным знаком «За активную работу в профсоюзах».

После выхода на заслуженный отдых, Н.И.Сайдашев продолжил сотрудничество с газетами и журналами, подключился к ветеранскому

движению. Сначала принимал участие в работе совета ветеранов НГДУ «Лениногорскнефть», поскольку он там проработал 36 лет, затем был избран членом президиума Лениногорского горрайсовета ветеранов войны и труда. И там принимает активное участие в общественной работе вот уже почти 20 лет. Он возглавил комиссию по спорту и организовал группу здоровья «Самоздрав». Проводил на стадионе спортивные соревнования среди пенсионеров по шашкам, шахматам, бильярду, возобновил в городе соревнования городошников, проводит спортивные праздники для ветеранов на стадионе «Юность», так называемый «малый сабантуй» перед праздником Сабантуй.

Неоднократно выезжал в сёла и там проводил соревнования по шашкам и шахматам среди ветеранов сельских поселений. Так, были проведены соревнования в рабочем поселке Шугурово, в деревнях Сарабикулово и Старый Кувак.

Кроме того, он избран председателем совета ветеранов Лениногорского цеха ООО «НКТ-сервис» Управляющей Компании «ТМС-групп». Цеховая шахматная команда ООО «НКТ-сервис» неоднократно занимала призовые места среди других цехов УК. В связи с этим, я с удовольствием вспоминаю победные партии и первые места по шахматам среди ветеранов, которые одержал Н.И. Сайдашев в ходе поездки на теплоходе по Волге из Казани в Москву и обратно, организованной при поддержке президента РТ Р.Н. Минниханова с 27 мая по 9 июня 2017 г..

Свою активность и доброжелательность к коллегам-ветеранам из Татарстана и других городов Поволжья Н.И. Сайдашев проявил в ходе этого путешествия, тем самым показывая пример молодому поколению ветеранов-участникам боевых действий в Афганистане и других локальных конфликтах. Отметим также, что Н.И. Сайдашев возглавлял культурный центр и организовал поездки хора «Сүнмәс ялкын» в Зеленодольск, Альметьевск, Азнакаево и дом престарелых г.Лениногорска. Интересным было выступление со своей программой «Каз өмәсе» на ТНВ.

По рекомендации Лениногорского Горрайсовета ветеранов (пенсионеров), Наиль Идрисович был выдвинут на общественную работу помощником Уполномоченного по правам человека по Лениногорскому муниципальному району и городу Лениногорск. В декабре 2010 г. он был назначен на эту работу приказом Уполномоченного по правам человека по Республике Татарстан С.Х. Сабурской.

Он с честью оправдал оказанное доверие и за год общественной деятельности его труд был отмечен на республиканском уровне. Наиль Идрисович награждён Благодарственным письмом Председателя Госсовета РТ Фарида Мухаметшина, серебряным круглым знаком «Казанский

Кремль» и денежной премией. Он проработал помощником Уполномоченного по правам человека по Лениногорскому муниципальному району и городу Лениногорск до 2014 г..

Работая общественным помощником Уполномоченного по правам человека Республики Татарстан по Лениногорскому муниципальному району, он оказывал бескорыстную как юридическую, так и моральную помощь ветеранам, пожилым, бездомным и инвалидам, В частности, он оказал содействие в получении гражданства РФ проживающему в с. Каркали И. А. Зямилову, прибывшему на постоянное местожительство из Узбекистана. Также Наиль Идрисович постоянно ходатайствует перед «УК ТМС-групп» об оказании материальной помощи нуждающимся пенсионерам, ветеранам, являясь председателем совета ветеранов «НКТ-Сервис». Так, в 2013 г. помощь оказана Ф.З. Мусину, С.Н. Клеменко, Н.С. Орешину, Р.М. Султановой, В.А. Хватковой и другим. Он оказывает материальную помощь совету ветеранов ЦРБ, обществу инвалидов (ВОИ), приобретает (за свой счёт) подарки и призы для поощрения участников конкурсов, соревнований. Дому престарелых г. Лениногорска подарил полное издание «Большой советской энциклопедии» (в 30 томах), оказывал посильную материальную помощь при строительстве памятников в сёлах Керлигач и Зай-Каратай, мечетей Кул-Шариф (в Казани), в селе Юлтимирово и в г. Лениногорске. Организует распределение экологически чистого мёда по сниженным ценам инвалидам и пожилым людям.

Продолжает и свою литературную работу – вот недавно предложил читателям новую книгу «Клянчеево – родина моих предков». Это большой кропотливый труд по сбору материала древа рода Сайдашевых. «Да какой сильной и могущей была бы наша страна, если бы все мы как он, знали, любили и почитали свой род! Слова Родина и род имеют один корень. Знаете, мне представляется, что эти кони на обложке книги олицетворяют наш Горрайсовет ветеранов, который тоже, несмотря на трудности, препятствия скачет только вперёд!», – пишет Н.И. Сайдашев.

В честь 30-летия Лениногорского совета ветеранов Сайдашеву Наилю Идрисовичу наряду с другими ветеранами присвоено звание «Почётный ветеран города».

Неоднократно Наиль Идрисович принимал участие на форумах «Трудовая доблесть России». В частности, 1–3 июня 2018 г. он побывал в городе-герое Новороссийске. Главный лейтмотив Всероссийского форума «Патриотизм и наставничество – основа силы России» (под руководством А.Г. Лёвина – председателя Центрального правления ВОО «Трудовая доблесть России», Героя Социалистического труда). Там он организовал за свой счёт поездку делегации из Татарстана на Крымский мост. На той

стороне в Керчи сфотографировались на память, пообедали и вернулись в Новороссийск.

20 ноября 2015 г. Н. И. Сайдашев принял активное участие в работе Всероссийской научно-практической, историко-краеведческой конференции «Человек и природа в Лениногорском районе и Юго-Восточном Татарстане. Село Сарабикулово и Шугурово-Шешминский регион: проблемы истории и культуры», прошедшей на базе Сарабикуловской школы Лениногорского района РТ. После этого мероприятия Наиль Идрисович приехал в Лениногорск с идеей о создании краеведческого клуба. По его инициативе в 2016 г. был создан и начал успешно действовать при Лениногорском городском и районном Совете ветеранов историко-краеведческий клуб «Краевед» при активном участии ветеранов краеведов. В дальнейшем, Н. И. Сайдашев и его коллеги ветераны-краеведы активно участвовали в ряде историко-краеведческих форумов: с. Сарабикулово (9 декабря 2017 г.), с. Черемшан (20 октября 2017 г.), с. Шугурово (20 апреля 2018 г.), г. Азнакаево (17 мая 2018 г.), г. Казани (23 мая 2018 г.) и др.

Активное участие принимали лениногорские ветераны-краеведы, в том числе М. Ш. Исхаков и Н. И. Сайдашев, в праздновании I и II Межрегиональных Сабантуев на р. Ик с участием представителей прииксках районов Восточного Татарстана, Западного Башкортстана и Оренбургской обл. в с. Тюменяк Туймазинского района РБ (2017 г.) и г. Азнакаево РТ (2018 г.).

3–5 апреля с. г. в Казани прошел II Всероссийский форум татарских краеведов, в работе которого приняли участие 6 делегатов из Лениногорского района РТ, в том числе Н. И. Сайдашев. В ходе пленарного заседания Наилю Идрисовичу была вручена «Благодарность Президента РТ» Р. Н. Минниханова за активный вклад в деле изучения истории татарских сел и участие историко-краеведческом движении.

В июле 2018 г. решением Исполкома Всемирного конгресса татар Н. И. Сайдашев награжден медалью ВКТ «За заслуги перед татарской нацией».

Свое 85-летие Наиль Идрисович Сайдашев встретил в кругу друзей и близких с полным оптимизмом и новыми планами.

Мы, друзья и коллеги, поздравляем нашего ветерана-краеведа, журналиста и писателя Наиля Идрисовича Сайдашева, с юбилеем, желаем ему дальнейших успехов, крепкого здоровья и долгих лет жизни!

По поручению коллег и друзей –
председатель Общества татарских краеведов РТ, первый заместитель
Председателя Совета Всетатарского Общества краеведов,
заслуженный деятель науки РТ, академик АВИН РФ А. А. Бурханов.

ХУШЛАШУ

НЕКРОЛОГИ

ПАМЯТИ НЕУТОМИМОГО КРАЕВЕДА

8 апреля 2018 г. в райцентре село Базарные Матаки Алькеевского муниципального района РТ скоропостижно ушел из жизни известный краевед, журналист, директор Историко-краеведческого музея имени С.М. Лисенкова Алькеевского района РТ, один из патриотов татарского народа, отличный друг, Юсуф Загидуллович Зарипов (1947–2018).

* * *

Ю.З. Зарипов родился 24 ноября 1947 г. в деревне Аппаково Алькеевского района РТ. Учился в начальной школе д. Аппаково, затем среднее образование получил в соседней Юхмачинской школе. Еще подростком он пробовал писать стихи. Посылал свои заметки и материалы в районную газету «Путь коммунизма». Юноша мечтал стать журналистом, но жизненный опыт он в начале набирал в родном селе. Красота родного края, культуры и традиции татарского народа позволили обогатить душу будущего сельского журналиста. За годы работы в редакции районной газеты, из-под пера Юсуфа Загидулловича вышло много интересных и содержательных книг о трудолюбии алькеевцев.

В 2000 г. Юсуфу Загидулловичу глава Алькеевкского района РТ Ф.М. Давлетшин предложил заняться созданием районного краеведческого музея.

Тогда журналист полностью с головой ушел в новую, интересную, к тому же близкую ему по духу, деятельность. Его стараниями в 2008 г. в районном центре был создан уникальный музей с весьма богатыми фондами и экспозициями, где хранятся ценные археологические, этнографические, историко-культурные и научно-технические экспонаты. Ныне этот музей известен не только в Татарстане, но и в РФ.

Основной комплекс музея расположен в здании, построенном в 1814 г. купцом 1 гильдии Сергеем Михайловичем Висенковым. Позже к этому зданию была сделана дополнительная пристройка, что расширило экспозиционные залы. Ю.З. Зарипов отыскал правнука купца – Анатолия Михеева (гражданина США), главу Российского представительства аэрокосмической компании «Аэроджет». Благодаря ему были

установлены связи с советскими и российскими летчиками-космонавтами, в фонды Алькеевского музея поступили экспонаты по истории космонавтики и создан уникальный (единственный в Татарстане) «Зал космонавтики».

Отмечу также, что «Закамский отряд Золотоордынской комплексной историко-археологической экспедиции» АН РТ ТГГИ под моим руководством в 2005 г. проводил комплексное рекогносцировочные исследования в Алькеевском районе и археологические раскопки на городище Иске Нухрат. В работе экспедиции принимали участие студенты 1 курса исторического отделения ТГГИ. Ю. З. Зарипов, как директор музея и представитель администрации, оказывал большую помощь в проведении историко-археологических работ. Итоги этих исследований были обобщены в ходе проведения в Базарных Матаках в 2010 г. Региональной научно-практической конференции «Проблемы истории и культуры «Алькеевского Закамья» и изданной монографии «Очерки истории Алькеевского региона. Древность, средневековье и новое время» (Казань, 2010 – 148 с.). Тогда в рамках культурной программы конференции Ю. З. Зарипов организовал для гостей – космонавтов и профессора Э. С. Кульпина-Губайдуллина из Москвы экскурсию к историческим объектам Болгарского заповедника. Все выявленные археологические находки после детальной научной обработки были переданы в районный музей и стали базовой основой создания отдела археологии.

Ежегодно Музей им. С. М. Лисенкова посещают местные жители и гости из российских регионов и зарубежных стран. Они с удовольствием знакомятся с экспозициями музея и узнают много нового интересного по истории Алькеевского района.

Очень большой мечтой Ю. З. Зарипова было желание провести юбилей Базарных Матаков, основанный на археологических материалах. Он неоднократно предлагал и планировал в декабре 2018 г. провести Всероссийскую научно-практическую конференцию по истории региона в целях определения возраста райцентра.

Нужно добавить, что Юсуф Загидуллович, как патриот района, внес свой вклад в разработку символов Алькеевского района РТ: герба и флага, предложив свои идеи и став соавтором.

Ю. З. Зарипов был человеком активной жизненной позиции, имеющим собственный взгляд на мир. Результаты его деятельности были оценены – Ю. З. Зарипов удостоился звания «Заслуженный работник культуры Республики Татарстан», был награжден медалями и грамотами, благодарственными письмами, в том числе медалями Эдуарда Циолковского и Теодора фон Кармена.

Я многократно встречал Юсуф-ага в ходе поездок в Алькеевский район, в частности, 2 марта 2018 г. в ходе Всероссийского форума татарских предпринимателей, а также в Казани – последняя наша встреча состоялась в ходе II Всероссийского форума татарских краеведов в столице республики 3–5 апреля 2018 г..

Юсуф Загидуллович был, с одной стороны, мечтательным романтиком, с другой – мудрым и обстоятельным человеком, всегда открытым людям, а также другом, надежным и верным супругом, заботливым отцом.

Светлая память об этом добром Человеке, краеведе, журналисте и музееведе надолго сохранится в сердцах у его близких и родных, коллегах и друзьях, конечно его земляках – алькеевцев.

От имени всех татарских краеведов и ученых-историков
Почетный гражданин Алькеевского района РТ,
заслуженный деятель науки РТ
Альберт Бурханов.

Авторлар турында

Об авторах

Авторлар буенча белешмә

Айсин Руслан Валерьевич, политолог.

Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызы, тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы, тарих фәннәре кандидаты, профессор, Татарстан Республикасы «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» рәисе, Гомумтатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте Советы рәисенең беренче урынбасары.

Бугарчёв Алексей Игоревич, ТФА А.Х.Халиков исемендәге Археология институтының кече фәнни хезмәткәре.

Габбасова Кадрия Әнвәр кызы, тарих фәннәре кандидаты, Казан шәһәре Киров районы 15 номерлы татар гимназиясының тәрбия эшләре буенча директор урынбасары.

Галимов Фиркәт Гариф улы, Татарстанның атказанган врачы, ССРның сәламәтлек саклау отличнигы, А.Н.Бурумов исемендәге журналистика премиясе лауреаты, хезмәт ветераны.

Гариф Нурулла Гыймадетдин улы, тарих фәннәре кандидаты, педагогия хезмәте ветераны.

Дәминова Флүрә Каюм кызы, Татарстан Республикасы милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре.

Закирова Илсөяр Гамил кызы, филология фәннәре докторы, ТФАның Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре, гыйльми совет әгъзасы.

Исхаков Дамир Мәүләви улы, тарих фәннәре докторы, РТФА академигы, БТК Милли Шура әгъзасы, журнал мөхәррире.

Йосыпова (Хәлилова) Ләйсән Әлфир кызы, ТФА Ш.Мәрҗәни ис.Тарих институтының тарих фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алырга теләүче.

Кутумова Равилә Сибгатулла кызы, Тубыл шәһәренең урта гомум белем бирүче 15 номерлы мәктәбе каршындагы Төмән өлкәсенең милли мәктәпләре музее мөдире, Татарстан Республикасы журналистлар берлеге әгъзасы, хезмәт ветераны.

Минһаҗев Рәшит Рәкыйп улы, «Ватаным Татарстан» газетасының бүлек мөдире.

Нәҗметдинов Зыятдин хәзрәт Мөхәррәм улы, Киров өлкәсе Нократ Аланы районы Иске Пенәгәр авылы имам-хатыйбы.

Нотфуллина Рамилә, Теләче районы, Олы Нырсы авылы мәктәбе укучысы.

Салиев Равил Зөфәр улы, төбәк тарихын өйрәнүче, Россия Федерациясенең Гомуми белем бирү буенча мактаулы хезмәткәр.

Сафиуллина Елена Шәүкәт кызы, Томск өлкәсе Татар мәдәният үзәгенең мәгълүмати һәм халыкара элемтәләр буенча баш белгече.

Степанов Олег Витальевич, нумизмат-тикшерүче, төбәк тарихын өйрәнүче, Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы Гомумтатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте идарәсе әгъзасы.

Таҗиев Дамир Нәзир улы, Россия Журналистлар берлеге әгъзасы, Рафаил Төхфәтуллин исемендәге бүләк иясе, Әлмәт төбәгенең җәмәгать эшлеклесе, туган як тарихын өйрәнүче. «ТаграС-ХимСервис» җаваплылыгы чикләнгән оешма (ООО) хезмәткәре.

Тычинских Зәйтүнә Әптрәшит кызы, тарих фәннәре кандидаты, РФА УрБның Тубыл комплекслы фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре.

Фәтхиев Роберт Ихсан улы, Башкортстан Республикасы һәм Россия Федерациясе журналистлар берлеге әгъзасы, «Илһам чишмәсе» төбәкара шагыйрьләр фестивале Гран-при иясе, әдәбият номинациясендә «Нить Ариадны» халыкара Мәскәү фестивале лауреаты.

Харисов Фәнит Фахраз улы, педагогика фәннәре кандидаты, Татарстан республикасының атказанган укытучысы, Россия Федерациясенең гомуми белем бирүнең мактаулы хезмәткәре, «15 татар гимназиясе» МББУ директоры.

Хисамов Олег Ришат улы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фән эшләре буенча директор урынбасары.

Хисмәтуллин Сәет Зәир улы, Тубыл шәһәренең урта гомум белем бирүче 15 номерлы мәктәп директоры, Мәгариф өлкәсендә мактаулы хезмәткәр.

Хәйруллина Алсу Данил кызы, тарих фәннәре кандидаты, «Музей үзәге +» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять методисты.

Шәйхиева Гөлназ Фирдинат кызы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Мәгълүмати хезмәт һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә идарәсе җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Яушев Рәис Равил улы, төбәк тарихын өйрәнүче, эшмәкәр.

Яхин Фәрит Зәки улы, филология фәннәре докторы, профессор, ТФА Г.Ибраһимов исем. ТӘСИ бүлеге мөдире.

Сведения об авторах

Айсин Руслан Валерьевич, политолог.

Байрамова Фаузия Аухадиевна, кандидат исторических наук, писательница, общественный деятель.

Бугарчёв Алексей Игоревич, младший научный сотрудник Института археологии им. А. Х. Халикова АН РТ.

Бурханов Альберт Ахметжанович, кандидат исторических наук, профессор, заслуженный деятель науки Республики Татарстан, первый заместитель председателя Совета Всетатарского общества краеведов, председатель Региональной общественной организации «Общество татарских краеведов» Республики Татарстан.

Габбасова Кадрия Анваровна, кандидат филологических наук, заместитель директора по воспитательной работе МБОУ «Татарская гимназия № 15» г. Казани.

Галимов Фиркат Гарифович, заслуженный врач РТ, Отличник здравоохранения СССР, Лауреат журналистской премии имени А. Н. Бурумова, ветеран труда.

Гариф Нурулла Гыймадетдинович, кандидат исторических наук, ветеран педагогического труда.

Даминова Флюра Каюмовна, старший научный сотрудник Национального музея РТ, заслуженный работник культуры.

Закирова Илсеяр Гамиловна, доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (ИЯЛИ АН РТ), член ученого совета ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

Исхаков Дамир Мавлявеевич, доктор исторических наук, Академик РАЕН, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, редактор журнала.

Кутумова Равиля Сибгатулловна, заведующая музеем национальной школы Тюменской области при СОШ № 15 г. Тобольска, член Союза журналистов Республики Татарстан, ветеран труда.

Мингазов Рашит Ракипович, редактор отдела газеты «Ватаным Татарстан».

Назметдинов Зиятдин хазрет Мухаррамович, Имам-хатыб деревни Старый Пинигерь Вятскополянского района Кировской области.

Нотфуллина Рамиля, учащаяся школы д.Большие Нырсы Тюлячинского района.

Салиев Равиль Зуфарович, краевед, Почётный работник общего образования РФ.

Сафиуллина Елена Шаукатовна, Главный специалист по информационным и международным связям ОГАУК «Центр татарской культуры» Томской области.

Степанов Олег Витальевич, исследователь-нумизмат, краевед, член Совета Всетатарского общества краеведов Всемирного конгресса татар.

Тазиев Дамир Назирович, краевед, член Союза журналистов РФ, лауреат премии имени Рафаила Тухватуллина, общественный деятель Альметьевска, сотрудник ООО «ТаграС-ХимСервис».

Тычинских Зайтуна Абтрашитовна, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Тобольской комплексной научной станции УрО РАН.

Фатхиев Роберт Ихсанович, член Союза журналистов РБ и РФ, Обладатель Гран При межрегионального фестиваля поэтов «Родники вдохновения», Лауреат международного московского фестиваля «Нить Ариадны» в номинации литература.

Харисов Фанит Фахразович, кандидат педагогических наук, заслуженный учитель РТ, почетный работник общего образования РФ, директор МБОУ «Татарская гимназия № 15».

Хайруллина Алсу Даниловна, кандидат исторических наук, методист ООО «Музейный центр+».

Хисамов Олег Ришатович, кандидат филологических наук, заместитель директора по научной работе ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

Хисматуллин Саит Заирович, директор МБОУ СОШ № 15, почетный работник образования.

Шайхиева Гулназ Фирдинатовна, руководитель Управления информационной службы и связям СМИ Всемирного конгресса татар.

Юсупова (Халилова) Ляйсан Алфировна, г. Казань, Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, соискатель ученой степени кандидата исторических наук.

Яушев Раис Равилевич, краевед, бизнесмен.

Яхин Фарит Закиевич, доктор филологических наук, профессор, заведующий отделом ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова АН РТ.

Туган җир

Төбәк тарихы буенча журнал

Родной край

Краеведческий журнал
3’2018

Подписано в печать 21.09.2018 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 19,5 Тираж 1000 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов

Участники конференции в Тобольске.

Из находок Урматского поселения

№

МЕТРИЧЕСКАЯ КНИГА

ВЯТСКОЙ ГУБЕРНІИ

Малмыжскаго уѣзда

деревни

въ мечети

на 1888 г.

Изъ Оренбургскаго Магометанскаго Духовнаго Собранія.

К материалу З. М. Назметдинова.
История сел, судьба татарского
народа в метриках



У надгробного камня в Курганской области

Куртамыш, Курганская область.

Искер-жыен.

Колхозники села Аккуль.

К материалу О.Р. Хисамова и И.Г. Закировой. Татарские села Новосибирской области

В музее МАОУ СОШ № 15 г.Тобольска